Әзһәр Мөхәммәдиев

БОРЫНГЫ ХАЗАР ҺӘМ БОЛГАР-ТАТАР АКЧАЛАРЫ

ӘЗҺӘР МӨХӘММӘДИЕВ

БОРЫНГЫ ХАЗАР ҺӘМ БОЛГАР-ТАТАР АКЧАЛАРЫ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1986

ББК 63.3(2Р-Тат)
М98

Мөхәммәдиев Ә. Г.

М98 Борынгы хазар һәм болгар татар акчалары.— **Казан: Тат. кит. нәшр., 1986—176 бит, рәс. белән.**

Китап хазарларда һәм болгар-татарларда акча әйләнешенең аерым чорларын конкрет тикшерүгә багышланган. Бу мәсьәләне яктыртканда автор Татарстан Дәүләт музеенда, СССР Дәүләт тарих музеенда һәм күп кенә башка коллекцияләрдә тупланган нумизматик материалга, язма истәлекләргә таяна һәм борынгы хазар, болгар-татар тарихына карата мөһим нәтиҗәләр ясый.

Китап киң катлау укучыларга адреслана.

М $\frac{0503000000-303}{М132(03)-86}$ 279—86 ББК

Азгар Гатауллович Мухамадиев

ДРЕВНЕХАЗАРСКИЕ И БУЛГАРО-ТАТАРСКИЕ МОНЕТЫ

(на татарском языке)

Рецензенты *С. Х. Әминев.* Редакторы *А. К. Тимергалин.* Тышлык художнигы *Л. М. Усманова.* Художество редакторы *Г. Е. Трифонов.* Техник редакторы *Ә. С. Трофимова.* Корректорлары *И. М. Ханипова, М. Р. Хакимова.*

ИБ № 4191

Наборга бирелде 26.06.86. Басарга кул куелды 11.11.86. ПФ 09192. Формат 84×108 1/32. Китап-журнал кагазе № 2. Гарнитура школьная. Печать высокая. Учетно-изд. табагы 9,2+рәс. 0,75. Якынча басма табагы 9,2+рәс. 0,8. Усл. кр. отт. 10,3. Заказ Т-367. Тираж 3000. Бәясе 35 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

© Татарстан китап нәшрияты, 1986.

Фронтовик этием
Гата Мөхәммәдиевнең якты истәлегенә

КЕРЕШ

«Бул син хәтта бер падишаһ һәм хакиме бар җиһанның,
Һич тырышма — бер көнгә дә озайтылмас гомер юлың»,— дип, Сәгъди дөрес әйтә...
Дөнья рәхәтләре миңа кояш нурларында кипкән чык кына, узган гомерләрем хыял-төш кебек...
Билемне башка берәү билбаулар чак җитте, Усама әйтмешли, ашкын гомеремнең чигенә ирешеп, әҗәл көтәм. Чөнки тәкъдир тукмакларын кире тибәрергә инде картайдым, ана карынынңан пәйда булган нарасыйдай хәлсез һәм көчсез мин.
Аһ, оглаңнар кабере өстендә койган күз яшьләрем вә сыкрауларым, кайгы-сагыш, хәсрәтләрем...

Буыннан-буынга күчә килгән хәзинә чүлмәге тышындагы язудан

Идел буенда һәм Көнчыгыш Европаның кайбер башка төбәкләрендә җир астыннан бик күп көмеш болгар-татар акчалары табыла. Әлбәттә, борынгылар мондый хәзинәләрне үзләре өчен саклау максаты белән күмгәннәр. Ләкин еш кына ул байлыклар гасырлар буена җир куенында ятып калганнар һәм безнең көннәрдә, үзләренең «яңа хуҗаларын» табып, галимнәр кулына күчкәннәр. Табылган хәзинәләргә карап фикер йөрткәндә, сугылган акчаларның төрлелеге һәм саны буенча Идел буендагы акча сугу сарайлары белән ярышырлык дәүләтләр урта гасырларда сирәк булган.

Хазар һәм болгар дирһәмнәре — табылган акчаларның иң борынгылары. Алар «Ард әл-Хазар»да (гарәпчә «Хазар җире» дигән сүз) һәм Болгар шәһәрендә сугылган.

Хазар иле Көнчыгыш Европада беренче феодаль дәүләтләрдән санала. Анда йөзләгән шәһәр булуы мәгълүм. Хазарлар төзү эшендә кирпеч куллана башлаганнар һәм, ихтимал, «кирпеч» сүзе үзе дә безгә хазарлардан мирас булып калгандыр.

Иделнең түбән агымында урнашкан Итил шәһәре Хазар иленең башкаласы булган дип уйлыйлар. Бу шәһәр VIII гасырда ук үзенең акча сугу сарае булуы белән билгеле.

Хазар тарихын өйрәнүнең бик зур әһәмияте бар, чөнки Кавказ, борынгы Кырым һәм Идел буе төрки халыкларының тел охшашлыгын болгар тарихына таянып кына аңлатып булмый. Бу халыкларның гомумлеге хазар чорларына ук (VII—X гасырларга) барып тоташа.

Идел буенда товар-акча мөнәсәбәтләре Төрки каганлыгы чорыннан, ягъни VI гасырдан ук башланган дип әйтергә тулы нигез бар. Ләкин үз акчаларын сугу эше биредә VIII гасырда юлга салынып, IX—X гасырларда дәвам итә, фәкать XI—XII гасырларда көмеш кытлыгы (кризисы) дип аталган чорда гына тукталып тора да XII гасыр азакларында кабат торгызыла.

Акча сугу эше чәчәк аткан елларда хазар һәм болгар-татар тәңкәләре күркәм итеп, ул заман өчен югары техника нигезендә сугылган, алардагы язуларның матур һәм дөрес булуына игътибар ителгән. Кайбер акчаларга, бигрәк тә бакырларына, осталар тарафыннан эшләнгән төрле кош һәм җанвар сурәтләре төшергәннәр.

Шул рәвешле, хазар һәм болгар-татар акча-үлчәү системасы күп гасырлык үсеш юлы үткән. Бер юлга салынган акча сугу эшен монголларның басып керүе дә туктата алмый. Шәһәрләр тиздән торгызыла һәм Болгар йортында акча сугу сарае кабат эшкә керешә. Шулай да илнең экономик үсешенә зур зыян килә, элек, монголларга кадәрге чорда, көмеш һәм бакыр билгеле бер нисбәттә алмашынып йөргән булсалар, хәзер монометалл (бер металл) системасы урнаша һәм бу хәл товар-акча мөнәсәбәтләренең үсешенә тискәре йогынты ясый. Шәһәрләрдә ваклап һәм азлап сатуалу эшләре өчен бик кирәкле бакыр акчалар XIII гасыр азакларында гына чыгарыла башлый.

Идел буенда акча әйләнеше XIV гасырның беренче чирегенә генә, ягъни монголлар басып кереп йөз ел үткәч кенә чәчәк ата. Табылган хәзинәләрнең күбесендәге (алар арасында 20 мең данә, хәтта күбрәк тә акча булганнары бар) болгар-татар акчаларының XIV гасырда сугылган булуы очраклы хәл түгел.

Бездә беренче «нумизматлар» гарәпчәне сукалаучы гади кешеләр булган. Мәсәлән, 1710 елда Петр I доктор Д. Г. Мессершмидтны Себергә сирәк әйберләр эз-

ләргә җибәргән. Докторның көндәлегендә борынгы акчаны аек акыл белән һәм хәтта, әйтергә мөмкин, фәнни нигездә билгеләүче бер татар кешесе телгә алына. «...ул акчаның бер ягында «лә илаһе ила аллаһе, Мөхәммәд рәсүл аллаһе» дип язылган, ә бу гарәпчә «алла бардыр, бердер, Мөхәммәт аның пәйгамбәредер» дигән сүз дип аңлатты, икенче яктагы язуны исә ул аңлатып бирә алмады, ләкин анда ханның һәм бу акча сугылган шәһәрнең исемнәре булыр дип уйлый»[1].

Күп еллар буена тупланган барлык нумизматик материал XIX гасыр башларында, Казан университеты профессоры Х. М. Френ (1782—1851) хезмәтләрендә телгә килде. Х. М. Френны Казан университетында лекцияләр уку өчен 1807 елда Германиядән чакыртып китерәләр. Идел буенда табылган шәрык акчаларының күпсанлы коллекцияләре аңа тирән фәнни тикшеренү эше өчен мул материал бирә. Аның болгар-татар акчаларына багышланган беренче хезмәтләре 1816—1817 елларда нәшер ителә. Анда ул тәңкәләрнең 400 дән артык төрен тасвир итә һәм Көнчыгыш нумизматикасына нигез сала.

XIX гасырда Х. М. Френ, П. С. Савельев, А. Ф. Лихачев, А. К. Марков, В. Г. Тизенгаузен, В. В. Григорьев һ. б. кебек ориенталистлар тырышлыгы белән болгар-татар акчаларын өйрәнү һәм классификацияләү буенча зур эш башкарылган.

Узган гасыр тарихчылары язма чыганаклардан билгеле булмаган ханнарның исемнәрен, аерым династия вәкилләренең тәхеттә утыру вакытын ачыкладылар, байтак кына яңа географик мәгълүматлар алдылар (шәһәр исемнәре). XIX гасыр ориенталистларының тикшеренүләреннән башка, болгар-татар нумизматикасының алга таба үсешен күз алдына да китереп булмый. Ләкин шулай да нумизматик материалга метрологик анализ ясау белән бәйле күп кенә мәсьәләләр хәл ителмичә калды. Мәсәлән, теге яки бу чорга караган акчаларның авырлык нормасы ачык түгел иде. Хәлбуки К. Маркс моның гаять зур әһәмияте турында: «...Һәртөрле металл алмашы вакытында авырлык үлчәве башта бәя масштабы булып та хезмәт итә»,— дигән иде[2].

---

[1] В. В. Радлов. Сибирские древности, I том, 1 нче чыгарылыш, СПБ. 1888.

[2] К. Маркс. К критике политической экономии. Әсәрләр, 2 нче басма, М., 1959, 13 том, 55 бит.

Бу гасырның 30 нчы елларында болгар-татар акчалары турында А. Васильев, Г. Гобәйдуллин, А. А. Кротков, Р. Г. Фасмер кебек нумизматлар да матбугатта аерым мәкалә һәм хәбәрләр белән чыгыш ясадылар.

Соңгы вакытларда бу өлкәдә С. А. Янина, Г. А. Федоров-Давыдов һ. б. күп эш башкардылар, С. А. Янина, XIX гасыр нумизматлары Х. М. Френ, П. С. Савельев, А. Ф. Лихачев традицияләрен дәвам иттереп, күп кенә яңалыклар тәкъдим итте, ә Г. А. Федоров-Давыдов болгар-татар акчаларының метрологиясе һәм топографиясе буенча тикшеренүләре белән танылды.

Борынгы экономистлар, акча эшенә актив катнашып, дәүләт күләмендә акча-авырлык реформалары үткәргәннәр. Идел буенда XII—XV гасырларда шундый берничә реформа булуы мәгълүм. Ләкин аларның кайсы географик төбәкләрдә һәм ничек итеп үткәрелүе билгеле түгел. Безнең кулда моңа кагылышлы бер генә язма документ та юк. Акча реформаларын тасвир иткән хөкүмәт карарлары, әлбәттә, булган, тик алар безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Табылган акчалар үзләре һәм аларның бәя масштабы булып хезмәт иткән авырлыгы әлеге реформаларның үткәрелгәнлеген раслаучы күпсанлы дәлилләр булып хезмәт итәләр.

Бу китап хазарларда һәм болгар-татарларда акча әйләнешенең аерым чорларын конкрет тикшерүгә багышланган. Акча материалын өйрәнгәндә болгар-татар нумизматикасының хәл ителми калган кайбер мәсьәләләренә ачыклык кертелде. Мәсәлән, XIII гасыр акчаларының барысын да жучидлар чыгармаганлыгы ачыкланды һәм шуңа күрә монголларга кадәрге чор акчаларына махсус бүлек багышлана.

Хезмәттә төрле чорларга караган бакыр акчаларга да метрологик анализ үткәрелде. Автор, бакыр тәңкәләрнең авырлыгы закончалы тәртиптә үзгәрүгә таянып, көмеш акчаның курсы тирбәлү һәрвакыт бакыр акчаларның авырлыгы үзгәрүгә туры килә, дигән нәтиҗә ясады.

Идел буендагы акча әйләнеше һәм акча системалары рус теленә тәрҗемә ителгән язма чыганакларда аз яктыртыла. Бу мәсьәләләр буенча күпчелек мәгълүматны автор гарәп һәм фарсы сәяхәтчеләре һәм тарихчылары калдырган язмалардан алды. Әлбәттә, алар акча системасының, бигрәк тә урындагы акча

терминологиясенең нечкәлекләренә тирән керә алмаганнар. XIII—XV гасырларда Идел буендагы акча исәбе һәм акча терминологиясе борынгы татар язма истәлекләрендә шактый тулырак чагыла, ә алар башка телләргә тәрҗемә ителмәгән һәм шуңа күрә нумизматик әдәбиятта беркайчан да файдаланылмаган. XIII—XIV гасырларга караган борынгы татар әдәби истәлекләренең кайберләре безнең бу хезмәттә шул чорларның акча-үлчәү системаларын яктырту өчен эшкә җигелде.

Автор Батый һәм Беркә, шулай ук XIII гасырның 90 нчы елларында хакимлек иткән ханнар чыгарган акчаларның авырлык нормасындагы үзенчәлекләрне тапты. Бу үзенчәлекләр, нигездә, акча хәзинәләрен метрологик яктан тикшергәндә ачыклана һәм теге яки бу реформаның кайда үткәрелүен, бу вакытта нинди авырлык системасы файдаланылуын билгеләү өчен зарури шарт булып тора.

Шуны да әйтергә кирәк, акчаларның теоретик авырлыгын хәзинәләр буенча практик билгеләү кайбер специфик кыенлыкларга очрый (сүз алтын һәм көмеш акчалар авырлыгы турында бара). Акчаның хөкүмәт карары белән билгеләнгән авырлыгын ачыклау методикасы да юк әле. Шуңа күрә акча сугудагы авырлык нормасын билгеләгәндә үз методикаңны төзеп, акчаларның конкрет авырлыгыннан тыш, аларның авырлыгына йогынты ясый торган төрле факторларны исәпкә алырга, акча әйләнешендәге төрле чорларның авырлык диаграммасына саграк карарга туры килә. XIV гасырның беренче яртысына караган акча хәзинәсен генә алыйк. Мондый хәзинәләрдә гадәттә өч хан: Тукта (1291—1312), Үзбәк (1312—1342) һәм Җанибәк (1342—1357) чыгарган акчалар очрый. Диаграммалар буенча аларның авырлыгы төрлечә: Җанибәк тәңкәләре иң авыры, аннан соң Үзбәк хан акчалары китә, ә Тукта хан акчалары иң җиңеле булып исәпләнә. Билгеле булганча, XIV гасыр башында акча-авырлык реформасы үткәрелгән. Акчаларның закон белән каралган реформадан соңгы авырлыгын ничек билгеләргә соң? Тукта хан тәңкәләренә карапмы, әллә Үзбәк яки Җанибәк ханнар чыгарган акчалар нигезендәме? Әллә гомуми диаграммага таяныргамы? Тукта акчалары буенча моны эшләп булмый, чөнки алар 1310—1311 елларда сугылган һәм хәзинәне күмгән вакытта, ягъни Җанибәк тәхеткә менгән

вакытка кадәр инде 30 елдан артык әйләнештә йөреп, кулдан-кулга күчкәннәр һәм, димәк, ашалып җиңеләйгәннәр. Әлеге өч хан тәңкәләрен бергә кушып та уртак (уртача) авырлык нормасын чыгарып булмый, чөнки аерым чорларда сугылган акчаларның авырлыгын төгәл белергә кирәк. Үзбәк хан акчалары Җанибәк акчаларына караганда җиңелрәк. Ә моның исә тәңкәләрнең кулда озаграк йөрүе аркасында булуы да ихтимал. Ләкин Үзбәк ханның соңгы елларында сугылган акчаларны Җанибәк тәхеткә менгән елларда сугылган акчалар белән (ягъни кулда бер вакытта йөргән акчалар белән) чагыштыру Үзбәк хан тәңкәләренең чыннан да җиңелрәк икәнлеген күрсәтә. Димәк, Үзбәк акчалары реформадан соңгы акча сугу нормасын бирә дип фараз итәргә була. Әгәр Үзбәк хан тәңкәләренең билгеле бер авырлыктагы кадак (фунт) исәбеннән сугылуын һәм бу кадакның Хәрәзмдә дә, Азакта да һәм, ихтимал, бөтен Кыпчак олысында кулланылуын игътибарга алсак, безнең әлеге фаразыбыз тулысынча раслана.

Җанибәк акчалары авыррак итеп сугылган, һәм аларга карап без аның чорында акча сугуның авырлык нормасын билгели алабыз.

XV гасырның беренче яртысына караган кайбер акчалар, мәсәлән, элекке ханнар чыгарган акчалардан җиңелрәк. Моның сәбәбен кулда озак йөрүдән генә түгел, бәлки дәүләт тарафыннан тәңкәләрне бозып сугудан, ягъни чыгарыла торган акчаларның авырлыгын яшерен киметүдән эзләргә кирәк. Димәк, һәр чорның акча әйләнешенә үзенчәлекләр хас, һәм акча сугу нормаларын билгеләгән чакта боларны исәпкә алырга туры килә.

Хазар һәм болгар-татар акчаларында авырлык нормасы куллануда һәм тәңкәләрнең тышкы күренешендә билгеле бер традицияләр бар. Акча сугу осталары өчен ниндидер кагыйдәләр җыелмасы булган, алар безгә кадәр килеп җитмәгәннәр генә дип уйларга кирәк.

VIII—XIV гасырларда Идел буенда акча сугуда кабул ителгән авырлык нормаларын күздән кичергәч, бу норма беркайчан да ирекле һәм якынча гына булмаган дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Теге яки бу чор акчасы сугылган мыскал исәбе шәрык метрологиясендә яки Идел буе акча тарихында яхшы билгеле булган. Мәсәлән, XIII—XIV гасырларда берничә тапкыр акча-авырлык реформасы үткәрелә. Реформалардан

соң акчаларны 4,26 г лы; 4,464 г лы; 4,68 г лы һәм 4,095 г лы мыскал исәбеннән сукканнар. Идел буенда аларның иң борынгысы — IV гасырдан билгеле булган 4,26 г лы сасанидлар драхмасы.

Беренче карашка, әлеге төрле авырлык системалары арасында туры бәйләнеш юк кебек. Ләкин без аларның һәркайсы үзенең элгәре булган стандарттан көнчыгыш илләрендә кабул ителгән кагыйдә буенча килеп чыкканлыгын ачыклый алдык. Мыскалларның нигезен шул система мыскалының 1/24 өлешенә тигез булган кират яки алдагы система дирһәменең 1/16 авырлыгы тәшкил итә. Әйтик, 4,26 г лы мыскалның авырлык дирһәме $\frac{4,26 \cdot 7}{10} = 2,982$ г, ә 1/16 дирһәм 4,464 г лы мыскалның нигезе булган 0,186 лы киратны бирә (2,982:16=0,186 г; 0,186·24=4,464 г). 4,464 г лы мыскалның авырлык дирһәме 3,125 г тәшкил итә ($\frac{4,464 \cdot 7}{10} = 3,125$ г), ә 1/16 дирһәм 0,195 г лы киратны — 4,68 г лы мыскал системасының нигезен бирә (3,125:16=0,195 г; 0,195·24=4,68 г).

XIII һәм XIV гасырларда 4,68 г лы мыскалга нигезләнгән акча-үлчәү системасына реформа үткәрелгәч, яңа акчалар һәрвакыт 4,095 г лы мыскал исәбеннән сугылган. Ул беркадәр үзенчәлекле һәм 10:7 кагыйдәсенә туры килми ($\frac{4,68 \cdot 7}{8} = 4,095$). 4,68 һәм 4,095 г лы мыскалларның үзара кануни (ягъни шәригать буенча) бәйләнмәве бу үлчәү берәмлекләренең исламга кадәрге бәйләнеше турында сөйли шикелле.

Хәзинәләрне метрологик тикшерү болгар-татар акчаларының авырлыгы шактый төгәл булуын күрсәтә (өч таңкәнең авырлыгы уртача бер мыскал көмеш тәшкил итә). Шуңа күрә акча сугудагы авырлык нормаларын билгеләгән чакта аларның кыршылуы исәпкә алынмады һәм төрле чыгарылыш акчаларының авырлык нормасына өстәмә кертелмәде, чөнки мондый өстәмәләр шактый ук чамалы.

Бу хезмәттә автор чингизидлар чорына караган акча-авырлык системасын тикшергәндә Хәрәзм һәм Кырым акча системаларына кагылмый, чөнки алар махсус тикшерүне сорыйлар.

Китапта төрле чигенешләр һәм тарихи экскурслар ясарга туры килде, чөнки болгар-татар нумизматика-

сының кайбер мәсьәләләре бүгенгә кадәр бәхәсле булып кала.

Китапта акча хәзинәләрен һәм борынгы татар язма чыганакларын өйрәнү нигезендә хазар һәм болгар-татар акча терминологиясенең һәм акча-үлчәү берәмлекләренең килеп чыгышы, аларның үсеше тикшерелә.

XIX гасырда кабул ителгән «болгар», «жучид» яки «татар» акчалары дигән терминнар капма-каршылыклы. Мәсәлән, «болгар акчасы» дигәндә Болгар йортында монголларга кадәрге чорда сугылган дирһәм күздә тотылган. «Жучид» яки «татар» акчалары исә шунда ук, ләкин чингизидлар исеменнән сугылган. Әгәр монголлар ябырылыр алдыннан акча Багдад хәлифе Насретдин (Насир лид-дин) исеменнән сугылган булса, чингизидларның беренче акчалары Монголиядәге ерак Каракорымда тәхеттә утырган Мункә каан исеменнән чыгарылган, ләкин һәр ике очракта да алар Идел буе халкының алыш-бирешен тәэмин итү өчен Болгар йортында сугылганнар һәм фактта болгар акчасы булып калганнар. Моннан тыш, Мункә Жучиның түгел, бәлки Тулуй ханның улы, димәк, аның исеменнән сугылган акчалар жучидлар акчасы исәбенә керә дә алмый.

Монголлар гаять зур Кыпчак дәүләтенең үзәге итеп Идел буен сайлыйлар, ләкин өр-яңа акча-үлчәү системасы төземиләр. Чингизидлар исеменнән беренче акчалар нәкъ менә Болгар, ягъни Урта Идел буенда, утрак тормышлы халык яшәгән һәм товар-акча мөнәсәбәтләре алга киткән җирдә сугылган да. Бу акчалар эчтәлекләре белән дә, авырлык нормасы ягыннан да монгол йогынтысыннан азат һәм аларда болгар акча сугу традицияләреннән тайпылыш-мазар күзәтелми. Шуңа күрә Идел буенда акча әйләнешендәге бу ике чорны династик аермаларга карап кына каракаршы кую дөрес булмас иде.

Монголлар һәм Алтын Урда турында сүз чыккач, бер уңайдан Идел буе тарихының кайбер мәсьәләләренә дә кагылып үтәсе килә. Революциягә кадәрге кайбер татар тарихчылары Чыңгыз һәм Батый ханнарга мәдхия җырлау белән мавыкканнар. Бу исә, беренчедән, рус буржуаз тарихчыларының йогынтысыннан, икенчедән, Идел буе тарихының күп кенә мәсьәләләре өйрәнелмәгән булудан да килә. Хәзерге вакытта монгол басып алучыларының Көнчыгыш Европа

үсешен тоткарлавы бәхәссез. Идел буе халыкларының рәхим-шәфкатьне белмәгән дошманга каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшкәнлеге дә ачык билгеле.

Идел буе халыкларының монголларга каршы көрәшенә дөрес бәя бирү өчен, монгол яулары басып алганга кадәр Болгар дәүләтенең экономик куәтен, бай традицияләрен һәм потенциаль үсеш мөмкинлекләрен исәпкә алырга кирәк. Аерым тарихчылар, билгеле бер концепцияне алга сөреп (имештер, болгарлар сан ягыннан аз булган, алар юкка чыкканнар да, татарлар килгән), Болгар, Биләр һәм Суар шәһәрләрен кечерәк кенә түгәрәк белән әйләндереп алалар да, Идел буе Болгар иленең чикләрен «билгеләдек» дип дәгъва итәләр. Идел бассейнында Уралдан алып Донга кадәр булган җирләр хазарлардан болгарларга мирас булып кала дигән тарихчылар (мәсәлән, академик В. Бартольд) хаклы. Монголлар басып алганга кадәр Идел буенда 160 тан артык болгар шәһәре булганлыгын да, 1223 елда Калка елгасы буендагы сугышта җиңгәч, илләренә кайтып баручы монгол гаскәренең Болгар йортына басып керүен һәм шунда тар-мар ителүен дә онытмаска кирәк. Ә ул заманнарда монгол явына каршы торырлык дәүләтне гомумән табуы да кыен.

Хәтта бүгенге тарихи әдәбиятта да Алтын Урда бөтен Идел буена җәелгән булган дигән ялгыш фикер очраштыра. Алтын Урда исә һәрвакыт күчмә урда булып калган. Ул Төньяк Кавказ — Түбән Идел (хәзерге Волгоград тирәләре) — Җаек (хәзерге Урал елгасы) буйларында күченеп йөри. Дөрес, Урта Азиянең төньягында һәм Кара диңгезнең төньяк яр буйларында да шундый ук урдалар булган. Анда хәтта акча да сукканнар. Ләкин акчаларына караганда, үзәк урда аерым исем белән: «Урду эл-Могаззам» дип йөртелгән (гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә — бөек, кыйммәтле, ягъни алтын яки зур урда). Рус елъязмалары аны Алтын яки Зур Урда дип атаганнар да. Ләкин бу терминның дәүләт исеме буларак XVI—XVII гасырларда гына кулланыла башлавын әйтеп китәргә кирәк. Үз чорында ул биредә нигездә кыпчаклар яшәгәнгә «Кыпчак олысы» дип аталган.

Алтын Урданың үзендә дә үзгәрешләр булып торган. XIII гасырның 50 нче елларында, Кыпчак олысы әле оешып кына килгән вакытларда ук, анда политик һәм идеологик көрәш кискенләшкән була. Монгол-

ларның мәҗүси рәхимсезлегенә болгарларның мөселман фанатизмы каршы куела. Батый кинәт кенә үлеп киткәч, бөек монгол кааныиың фәрманына карамастан, урындагы дини һәм дөньяви феодаллар яшьли үк мөселманлыкка күчкән Беркәгә (1257—1266) хан тәхетен тәкъдим итәләр. Батыйның улы Сартакны агулап үтерәләр, аның урынына каан билгеләгән Улакчы (Сартакның улы) да шул ук язмышка дучар була. Батыйның өлкән хатыны Беркәгә каршы көрәш башлый, ләкин ул да, хөкемгә тартылып, җәзалап үтерелә. Шуннан соң каан җибәргән гаскәрләр тар-мар ителә һәм Идел буенда шәрыкка хас традицион мөселман политикасы җиңеп чыга.

Нәтиҗәдә Көнчыгыш Европада, шул исәптән Идел буенда һәм Хәрәзмдә Урда ханнарына бәйлелек хазарларга һәм болгарларга хас вассаллык төсен ала. Әйтик, Кытайда һәм Иранда бөтен идарә каан нәселеннән булган монгол феодаллары кулында тупланa һәм алар, билгеле бер монгол йортларына хуҗа булган хәлдә, баш күтәрүчеләргә каршы гаскәр куя алганнар. Идел буенда исә җирле югары катлау үз урынын һәм көчен саклап кала. Монда монгол законы яса урынына традицион ислам нормалары — үлем җәзасын тыя торган шәригать гамәлдә була. Әйтик, уйнашлык өчен таш атып җәзалау казый хөкем итә алган иң зур җәза исәпләнә, ләкин гадәттә эш моңа тикле барып җитми, чөнки юрисдикция шөбһә калдырмаслык дәлилләр таләп итә. Талау һәм урлашкан өчен кул кисү җәзасы икенче урында тора.

Алтын, яки Зур Урда монгол империясеннән тәмам аерыла һәм ясакны инде үз файдасына җыя башлый. 1260 елда монгол империясенең башкаласы Каракорымнан Кытайдагы Кайпинга күчерелә һәм Чыңгыз хан династиясе Юань дигән исемне ала.

Димәк, кайбер тарихчыларның, Идел буенда монголларга каршы көрәшне исәпкә алмыйча, Хорәзмдә, Идел буенда яки Русьта монгол баскаклары (ягъни Юань династиясе баскаклары) «утырган» диюе һәм моны «монгол» яки «монгол-татар золымы» дип атаулары белән килешеп булмый. Бу — Урда золымы булган. Иң яңа тарихи әдәбиятта монгол яуларында аерым бер татар кабиләләре катнашмаганлыгын, моның урта гасырлар һәм XIX гасыр тарихчыларының уйдырмасы гына икәнлеген ышандырырлык итеп исбатладылар («та-та» — татар сүзе кытайча фәкать «күч-

мә кеше» дигәнне генә белдерә). Билгеле булганча, XV гасырда Хәрәзм, Кырым, Әстерхан (тәңкәләрдә «Хаҗитархан» дип сугылган), Казан (тәңкәләрдә «Болгар» дип сугылган) һәм Мәскәү Урдага ясак түләүдән туктыйлар. 1480 елда Алтын яки Зур Урда Мәскәү князе Иван III кә каршы яу чаба, ләкин уңышка ирешә алмый, ә Иван III нең союздашы булган Кырым ханы Мәңге Гәрәй Урданы тар-мар итә, аның ханы — барлык олысларның хакиме саналган Әхмәт үтерелә.

Идел буеның VII гасырдан алып XII гасырга кадәр тарихы, XIII гасырдагы политик һәм идеологик көрәшләр, аннары бу төбәкнең XIII—XV гасырлардагы тарихы күпсанлы металл акчаларда бик ачык чагыла. Ягъни акча түгәрәк бер металл кисәге генә түгел, бәлки тарихчыга гаять кирәкле һәм ышанычлы чыганак та ул.

Әйтергә кирәк, кайчагында тарихчылар төрле кабиләләр һәм халыклар арасындагы бәрелешләргә тиешледән зуррак әһәмият бирәләр. Әлбәттә, урта гасырларда яшәгән авторлар, үз күзлекләреннән карап, иң мөһим вакыйгалар — сугышлар турында күп язганнар, сәүдәгә һәм товар алмашуга игътибар итмәгәннәр диярлек. Ә бит сәүдә эшләре беркайчан да өзелеп тормаган, сәүдәгәрләр, үз тормышларын куркыныч астына куеп, ерак-ерак сәяхәтләргә чыгып киткәннәр. Мәсәлән, X—XI гасырларда Киев Русенда әйләнештә йөргән акчалар көнчыгышта, шул исәптән Болгарда сугылган булган. Мондый акчалар потлап күмелгән хәзинәләр билгеле һәм бу акчалар рус җирләренә бары тик Идел буе — хазар һәм болгар җирләре аша гына үтеп кергән. Әлбәттә, хазар һәм болгар сәүдәгәрләре Русь шәһәрләренә барган кебек үк, рус кешеләре дә Идел буена килеп сәүдә иткәннәр. Шуңа күрә борынгы акчалар Көнчыгыш Европада яшәгән төрле кабилә һәм халыклар арасында экономик мөнәсәбәтләр урнашуның шаһитлары буларак кызыклы. Ә мондый мөнәсәбәтләр халыклар арсында тигезлек һәм тынычлык сакланганда гына оеша, яши һәм тәрәккый итә.

Бу хезмәт Татарстан Дәүләт музеенда, СССР Дәүләт тарих музеенда һәм күп кенә башка коллекцияләрдә тупланган материалларга нигезләнеп язылды.

Беренче булек

VIII—XIV ГАСЫРЛАРДА ИДЕЛ БУЕНДА АКЧА СУГУ ҮЗӘКЛӘРЕ

Көмеш көнгә куелса,
алтын аягы белән килер.

Борынгы мәкаль

Идел буенда акча әйләнешен тикшерә башлаганга кадәр, акча сугу сарайлары урнашкан шәһәрләр турында берничә сүз әйтеп китәргә кирәк. Урта гасырларда шәһәр акча сугыла торган экономик, политик һәм культура үзәге генә түгел, бәлки иҗтимагый процессларның иң мөһим күрсәткечләреннән берсе исәпләнә торган интенсив акча әйләнеше үзәге дә булган.

Урта гасырларда Идел буе Көнчыгыш Европада алга киткән игенчелек өлкәсе, эре экономик һәм культура үзәге булган. VIII гасырда ук инде Идел буе Көнчыгыш Европада беренче феодаль дәүләтнең — Хазар каганлыгының мөһим состав өлешенә әйләнә. Каганлык таркалгач, Идел буенда төп рольне Болгар дәүләте уйный башлый.

Хазарларның Түбән Иделдәге башкаласы Итил һәм Кама тамагындагы Болгар шәһәре үзләренең урнашуы ягыннан Борынгы Русьның Киев һәм Новгород шәһәрләрен хәтерләтәләр. Хазар теленнән сакланып калган сүзләр Итил белән Болгарның охшашлыгы тышкы яктан гына булмавын күрсәтә. Мәсәлән, Истаһри (X гасыр) сүзләренә караганда, «болгар һәм хазар телләре икесе бер». Кызганычка каршы, без хазарлар турында бик аз беләбез, ә Итил шәһәренең хәрабәләре дә мәгълүм түгел. Археологларга бу шәһәрлек билгесез, күрәсең аны Идел сулары күмеп, юып бетергәндер. Ләкин шәһәр төзү, акча сугу һәм

акча әйләнеше традицияләре югалмый. Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып төзелештә кирпеч кулланган хазарлар кебек үк, болгарлар да кирпечтән пулатлар, мунчалар, мәчетләр һ. б. салганнар. Акча әйләнеше дә иң элек хазар шәһәрләрендә башлана.

Монголларга кадәрге чорда Камадан (Чулман) алып Каспий диңгезенә кадәр бөтен Идел буенда Идел болгарларының ныклы дәүләте экономик үсешкә нигезләнгән бердәнбер реаль көчкә ия була. XII гасыр азакларында болгар шәһәрләре экономик яктан аеруча көчәяләр. Алар үзара гына түгел, Русь белән дә, гарәп илләре, Азәрбайҗан, Хәрәзм һ. б. илләр белән дә сәүдә итәләр.

Идел буе шәһәрләрендә товар-акча мөнәсәбәтләре нык үскән була. Археология мәгълүматларына караганда, 160 тан артык шундый шәһәр һәм 876 авыл билгеле. Алар арасында Болгар, Суар һәм Биләр кебек эре шәһәрләр дә булган. Мәсәлән, Биләр шәһәренең мәйданы 7 квадрат километр тәшкил иткән. Урта гасырларда мондый зур шәһәрләр әллә ни күп булмаган. Болгар тарихчысы Ибн Ногман шәһәр исемен «беләр», ягъни галим кеше сүзенә бәйләп аңлата. Исеменә карап фикер йөрткәндә, XII гасыр урталарында Биләр шәһәренең башкала булуы да ихтимал. Ләкин акча сугыла башлаган чорда (X гасыр) һәм XII гасыр азакларына инде Болгар шәһәре башкала булган. Акча Суар шәһәрендә дә сугылган.

XII гасырда, монгол явына кадәр, Болгар дәүләтенең башкаласы Шәһре Болгарда гына акча сугу сарае эшләгән.

Монголлар Хәрәзмне, Болгарны, Кырымны һәм кыпчак далаларын буйсындырганнан соң, Идел буе, хазарлар чорындагы кебек үк, нигездә төрки телдә сөйләшүче кабиләләр яшәгән һәм зур экономик мөмкинлекләргә ия булган бу олы дәүләтнең үзәгенә әйләнә.

Батый хан дәүләтенең үзәге итеп ни өчен Идел буен сайлаган соң? Бу сорауга җавап бирү өчен түбәндәге мөһим фактны исәпкә алырга кирәк. Идел буе Алтын Урдага күчмә тормышта яшәү өчен кулай бөтен шартларга ия булу өстенә, монда күпсанлы бай шәһәрләр дә булган. Яу чабу уңышлы чыкканда да күбесенчә аерым феодаллар баеган, ә хан казнасына өлеш аз тигән. Утрак тормышлы төбәкләрдән һәм шәһәрләрдән җыелган ясак исә даими табыш чыга-

нагы булып хезмәт иткән. Газан ханның, күчмә феодалларга мөрәҗәгать итеп, түбәндәге сүзләрне әйтүе мәгълүм: «Әгәр дә файда аларның һәммәсен талауда гына булса, бу эштә берәү дә миннән көчлерәк түгел. Әйдәгез, бергәләп талыйк. Ләкин әгәр дә киләчәктә тагарга[1] һәм икмәккә өметләнеп, миңа ялынып килсәгез, мин сезне кызганмам. Үзегез уйлап карагыз: игенче халыкны рәнҗетәсез икән, аның үгезләрен һәм чәчүлек орлыкларын тартып аласыз икән, игеннәрен таптатасыз икән, киләчәктә нишләмәк буласыз соң?»

Шәһәрләр ханны һәм Алтын Урданы ук-җәя һәм корал ясау осталары, көмешчеләр белән тәэмин итү өстенә, инде әйтеп үтелгәнчә, ясак түләп, акча белән дә тәэмин иткәннәр. Газан ханның ясак җыюны тәртипкә салуы турында фарсы тарихчысы Рәшид әддин: «Барлык өлкәләрдән җыелган ясак акча сугу сараендагы сумалардан ышанычлырак булып китте»,— дип яза.

Батый хан тәхеттә вакытта чингизидларның Көнчыгыш Европада беренче акчалары Шәһре Болгарда, ягъни халык шактый тыгыз утырган Урта Идел буенда сугыла. Биредә, күпсанлы болгар һәм хазар шәһәрләрендә акча эквивалентына ихтыяҗ сизелә, сату эше киң җәелгән һәм гадәти акча әйләнеше монголларга кадәр күп элек җайга салынган була. Бу җәһәттән, Калка янындагы сугыштан (1223 ел) соң Идел буена бәреп кергәч, монгол гаскәренең нәкъ менә биредә тар-мар ителүе дә зур әһәмияткә ия булганлыгын әйтеп китәргә кирәк. Җитештерү көчләре генә түгел, һөнәр, сәүдә һәм культура үзәкләре булган шәһәр-авыллар сакланып калган, чөнки Чыңгыз ханның тактикасы аның варислары кулланган тактикадан үзгә: ул коточкыч кансызлыгы белән асрылып торган, яшен-картын аямыйча, басып кергән илне буш сахрага әйләндергән. Мәсәлән, Хәрәзм монголларга кадәр экономик яктан шәрык илләре белән бертигез дәрәҗәдә булса да, анда мөстәкыйль акча сугу эше бары тик XIII гасырның соңгы чирегенә генә карый. Хәрәзм шәһәре (Үргәнч) монголларның беренче явы вакытында көл-күмергә әйләндерелә, ә борынгы Сәмарканд бөтенләй торгызылмый, соңыннан ул икенче урында төзелә.

Монгол яулары төбәкнең экономик хәленә бик

[1] Тагар — фураж

авыр йогынты ясаган. Иске шәһәрләрнең торгызылуы һәм яңаларының чәчәк атуы, тулаем алганда, XIV гасырга гына карый. XIII гасыр, ягъни монгол яулары чоры Идел буе тормышында аеруча катлаулы булган. Безгә билгеле булган барлык шәһәрлекләрдә дә XIII гасырга караган культуралы катлам бик аз процент тәшкил итә. Бу гасыр тулысы белән шәһәрләрне һәм илне аякка бастыруга китә.

Идел буенда монголларга кадәрге хазар-болгар шәһәрләре белән XIII—XIV гасырлардагы шәһәр арасында кискен бер аерма юк. Монгол яуларыннан соң, Русь илендәге кебек үк, күпсанлы болгар шәһәрләре: Шәһре Болгар, Биләр, Суар, Кашан, Казан, Юкәтау, Кермән һ. б. шәһәрләр торгызыла. Мөстәкыйль культура элемтәләрен саклаган бу шәһәрләр XIV гасыр ахырына — Идел буе шәһәрләрен Аксак Тимер гаскәре җимергәнгә кадәр яшәп киләләр. Хәтта Түбән Иделдә XIII гасырның икенче яртысында Сарай әл-Мәхруса да буш җирдә төзелми. Вильгельм де Рубрук сүзләренә караганда, биредә: «Этил диңгезгә койган җирдә» нindидер шәһәрчекләр булган. Бу төбәктә эре һөнәрчелек үзәге экономик зарурлык аркасында барлыкка килгән. Борынгы чорда ук монда Көнчыгыш Европада иң зур шәһәрләрнең берсе — Хазар каганлыгының башкаласы Итил торган. Ул җимерелгәч [1], монгол яуларына кадәр икенче бер хазар шәһәре — эре сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге Саксин яшәп килә. Көнчыгыш Европада беренче тапкыр төзелештә хазарлар үзенчәлекле (дүрт ягы да бер озынлыктагы) квадрат кирпеч (борынгы төрки телдә «кәрпич») куллана башлыйлар һәм Идел буенда шәһәр төзелешләрендә ул XIV гасыр азагына кадәр файдаланыла.

XIII гасыр шәһәр төзелешендә һәм Идел буе шәһәрләрен торгызуда Көнбатыш йогынтысы сизелми. Көнбатыш илләрендә әсир ителгән осталар Үзәк Монголиягә җибәрелә, ләкин бу анда шәһәрләр төзелешенә һәм шәһәр культурасы үсүгә китерми. XIII гасырда Монголиядә билгеле булган Каракорым, Саорин һәм Тосху шәһәрләре борынгы нигездә үсеп киләләр. Бу исә монгол ханнары Идел буенда шәһәрләр төзегәннәр дигән фикернең нигезе юклыгы турында сөйли. Мондый фикер борынгы Русь дәүләтен норманнар ни-

[1] Кайбер галимнәр Итил шәһәре Каспий диңгезе астында калган булырга мөмкин дип уйлыйлар.

гезләве турындагы теорияне хәтерләтә. Билгеле булганча, борынгы Русь дәүләте норманнар килеп утыру нәтиҗәсендә түгел, бәлки көнчыгыш славяннарда феодаль мөнәсәбәтләрнең мең еллар буена үсүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Идел буенда монгол ханнарына кадәр үк, хазар һәм болгар чорларында, йөзләгән шәһәрләр барлыкка килә һәм алар монгол яуларыннан соң да үз урыннарында калалар, аларның үсеше ханнар эшчәнлеге белән түгел, бәлки халык массаларының иҗади хезмәте белән аңлатыла.

XIII—XIV гасырларда Идел буеның, хәер монголлар басып алган Кытай, Иран һәм Урта Азиянең дә тарихы күрсәткәнчә, монгол ханнарының эшчәнлеге нигездә сәүдә эшен һәм ясак салу һәм аны җыю системасын яхшырак оештыруга юнәлтелгән була. Рәшид әд-дин: монгол ханнары «берәр җирнең чәчәк атуын теләп, базар яки шәһәр төзеткәндә һәм аңа халык күчереп утыртканда, яисә сугару арыгы үткәргәндә, моңа исәпсез-хисапсыз сумалар тотыла һәм мәҗбүри эшкә башка өлкәләрдән бик күп игенчеләр куып китерелә, ләкин моның аркасында әллә никадәр өлкәләр тагы да ныграк бөлә»,— дип яза.

VIII гасырдан башлап, Идел буе шәһәр культурасының үсешенә Шәрык, атап әйткәндә Мисыр белән Иран йогынтысы зур була. Табигый, Идел буе культурасының нигезе җирле халыкныкы булып кала, аның кайбер үзенчәлекләре исә төбәкнең күп милләтле булуыннан килә, чөнки хазар чорларыннан ук биредә башка халыкларның идеологиясен, телен һәм культурасын тану, аларга тигез карау хөкем сөрә.

XIII—XIV гасырларда Идел буенда шәһәр культурасы үсешенә провинциядәге Хәрәзмнең йогынты ясавы турындагы фикер дә тәнкыйтькә каршы тора алмый. Хәрәзм шаһларының башкаласы Үргәнч монголларның беренче явы вакытында 1221 елда ук тулысынча җимертелә. Алдарак әйтеп киткәнебезчә, тулы кыйммәтле металл акча чыгару Хәрәзмгә кадәр күп элек Болгар акча сугу сараенда башлана. Спектраль анализ күрсәткәнчә, Идел буе шәһәрләрендәге крәч кашин[1] Хәрәзмнекеләргә түгел, бәлки XII—XIII гасырдагы Кавказ аръягында һәм Урта Азиянең көньягында эшләнгән савытларга якын, бизәк мотив-

[1] Кашин — крәч яхшы ябышсын өчен кызыл балчыктан түгел, ә эре бөртекле ак балчыктан эшләнгән савыт.

ларында монголларга кадәрге һәм монгол чорындагы Иран, Мисыр һәм Кавказ аръягында эшләнгән савытларга охшашлык күренә. Ә бит Иран да, Мисырны инде әйтәсе дә юк, болгар һәм кыпчак хакимнәренә буйсынмаган, димәк аларны шәһәр төзү осталары белән тәэмин итәргә тиеш тә булмаган. Мөселман шәрыгенә хас булганча, мондый культура йогынтысы һәр ике якка да файда китергән. Мәсәлән, тикшеренүчеләр Идел буе классик әдәбиятының Урта Азия төрки әдәбияты үсешенә генә түгел, бәлки Кече Азиядә төрек әдәбияты үсешенә дә йогынты ясавын билгеләп үтәләр. XIV гасырда ук инде күп кенә татар шагыйрьләренең әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителә. Бу юлларның авторына, 1975 елда Идел буе археологик экспедициясе составында, Сарай әл-Мәхрусада XIV гасыр уртасына караган зур кирпеч остаханәне казырга туры килде. Анда яраксызга чыгарылган архитектура детальләре (терракота, майолика һ. б.), савыт-саба, шушында эшләнгән буяулы крәч савытлар табылды. Мондый бизәкле керамика археологик әдәбиятта «тимуридлар керамикасы» дип йөртелә. Ул бу исемен XIV гасыр азагында һәм XV гасырда Урта Азиядә таралган керамикадан алган. Фактлар исә Идел буеның Урта Азия культурасына йогынты ясавы турында сөйли.

Хазар-болгар һәм болгар-татар шәһәр культурасы элементларының чордан-чорга эзлекле күчә баруы акча әйләнешендә һәм акча сугу эшендә аеруча ачык чагыла. Акча сугу эше Итил шәһәрендә туып, Шәһре Болгарда да барлыкка килә. Акчасыз чорда (XI—XII гасырлар) Идел буенда акча сугу тукталып тора. Акча әйләнеше, киңәю белән бергә, XII гасыр азагында һәм XIV гасырда Түбән Иделдә дә башлана. XIV гасыр азагында Түбән Идел үзәкләре җимерелгәч, XV гасырда акча сугу һәм акча әйләнешенең төп үзәге яңадан Урта Идел буена күчә.

Сакланып калган металл акчаларга караганда, акча сугу эше 30 дан артык хазар һәм болгар-татар шәһәрләрендә һәм хан станының акча сугу сарайларында алып барылган. Көнчыгыш Европаның эре шәһәрләреннән Итил, Болгар, Сарай әл-Мәхруса һәм Сарай әл-Җәдид акчаның авырлык нормалары һәм тышкы күренеше билгеләнә торган төп үзәкләр булып саналган.

Тәңкәләрдә Гөлстан яки Сарай дип билгеләнгән

акча сугу сарайларының урыны бүгенгә кадәр ачыкланмаган. Хәлбуки, аларны ачыклау Идел буеның политик һәм экономик тарихын өйрәнү өчен шактый әһәмияткә ия. Болгар-татар нумизматикасының бүгенге торышы, соңгы елларда алынган яңа мәгълүматлар Идел буендагы акча сугу үзәкләренең урынын ышанычлырак итеп билгеләргә мөмкинлек бирә.

1. АРД ӘЛ-ХАЗАР (ХАЗАР ҖИРЕ)

«Ард әл-Хазар» дип билгеләнгән акчалар каган станында һәм хазар каганлыгының административ үзәге булган Итилдә сугылган дип уйлыйлар. Хазарларда Византиянең алтын тәңкәләренә охшатып сугылган иң беренче акчалар VII гасырга карый, ләкин ислам җиңеп чыкканнан соң гарәп куфи дирһәмнәренә охшатып суга башлыйлар (762—763 елларга карый). Ард әл-Хазарда акча сугу эше IX гасыр башында аеруча интенсив алып барыла.

Билгеле булганча, 737 елда Идел буйларында гарәпләрдән җиңелгәч, каган ислам динен кабул итә, шуннан соң бу төбәктә ислам дине рәсми тарала башлый. Әл-Истаһри, Итил шәһәрен тасвир итеп, түбәндәгеләрне яза: «Аларның базарлары һәм мунчалары бар, ә хазарлардан көнчыгыш яктагы бистәдә күпчелек сәүдәгәрләр мөселманнар...» Болгар шәһәрендә 923 елда булып киткән Ибн-Фадлан да Итилдә мөселманнар булуын телгә ала. Бу мөселманнар үзидарә хокукына ия булганнар, һәм аларның башында патша яраны — мөселман кешесе торган.

Ард әл-Хазарда соңгы акчалар 837—838 елларда сугылган һәм, ихтимал, акча сугуның тукталуы хазар каганының халыкка ят яһүд динен көчләве, шуның аркасында хазар илендә үзара сугыш кузгалуы белән бәйледер. Мәсәлән, болгар тарихчысы Ибн Ногман болгарлар белән хазарлар арасында дини сәбәпләргә бәйле бәрелешләр булуын хәбәр итә. Моннан соң куфи акчалары Болгарда сугыла. Итил шәһәренең кайда урнашканлыгы хәзергә кадәр анык түгел.

2. БОЛГАР, БОЛГАР ӘЛ-МӘХРУСА

Болгарда акча сугыла башлау Идел буенда феодаль мөнәсәбәтләрнең тагы да үсүе белән бәйләнгән. Монда башта акча куфи дирһәмнәренә охшатып сугыла һәм датасы билгеләнгән беренче акчалар 903—

908 елларга карый. Алар болгар ханы Җәгъфәр бин Габдулла исеменнән чыгарылганнар.

Болгар шәһәрендә баштагы чор акчаларын сугу 986—987 елларда туктала, бу исә Көнчыгыш илләрендә көмеш шахталарының ярлылануы аркасында туган көмеш кытлыгы (кризисы) белән бәйле.

Металл акчасыз чордан соң, Болгарда яңадан эшкә керешкән акча сугу сарае XII гасыр азагында монголларның икенче явы вакытында җимертелә.

Акча сугу сарае XIII гасырның 50 нче елларында торгызыла һәм эшли башлый. Беренче чингизид акчалары Мункә каан исеменнән сугылган.

XIII гасыр ахырларына кадәр Болгар шәһәре Кыпчак илендә акча сугыла торган төп үзәк булып кала. 1310—1311 елларда Тукта хан акча реформасы үткәргәннән соң, акча сугу эше Сарай әл-Мәхрусага күчерелә һәм Шәһре Болгарда акча сугу өзелеп тора. Үзбәк хан (1312—1342) вакытында исә Болгар акча сугу сарае яңадан эшли башлый һәм аеруча интенсив эшли. Бу чор акчаларында «әл-Мәхруса» дигән эпитет күренә башлый, ягъни акча сугу урыны «Болгар әл-Мәхруса» дип күрсәтелә. Соңгы Болгар акчалары XIV гасырның 30 нчы елларына карый. Үзбәк хан үлгәч, Болгардагы акча сугу сараеның эшчәнлеге көтмәгәндә генә һәм бөтенлэйгә туктала.

XIV гасыр азагында Болгар йорты экономик төшенкелек кичерә. Тарихчылар, кайбер татар чыганакларына таянып, моны Аксак Тимер яуларына бәйләп аңлаталар. Бу мәсьәләгә багышланган әдәбият бик бай. Тарихчыларның берләре Шәһре Болгар XIII гасыр азагында ук Мәңге Тимер тарафыннан җимертелгән дип саный (бу хан 1282 елда үлгән). Башкалары, мәсәлән Г. Н. Әхмеров, шәһәрне Булаттимер җимергән булуы мөмкин дип исәпли. М. Г. Сәфәргалиев исә, Аксак Тимер гаскәрләренең Болгар җирләренең үзәгенә килеп чыгуына таянып, Болгар шәһәренең аның икенче явы вакытында, 1395 елда җимертелгән һәм туздырылган булуы мөмкин дип уйлый. М. Г. Усманов Болгарның Булаттимер тарафыннан тар-мар ителүе турындагы версияне хаклы рәвештә тәнкыйтьли һәм Болгарны, ихтимал, Аксак Тимер җимерткән булыр дигән версияне яңа мәгълүматлар белән ныгыта [1].

[1] Усманов М. А., Татарские исторические источники XVII—XVIII вв., Казань, 1972, 117—118 битләр.

Тарихчыларның фикер сөрешендә бер бик мөһим мәсьәлә ачык кала. Болгар шәһәрен чыннан да Аксак Тимер җимерткән булсын, ди. Ләкин ул нилектән торгызылмый? Хәтта аяусыз монгол яуларыннан соң да Болгар шәһәре торгызылган һәм 150 елдан артык яшәгән бит. Бу шәһәрнең язмышы Урта һәм Түбән Идел буендагы Сарай әл-Җәдид, Хаҗитархан, Барчин, Үкәк, Самар, Биләр, Суар кебек шәһәрләр язмышына охшаган, күрәсең. Аксак Тимер тарафыннан җимертелгән яки җимертелмәгән булуларына карамастан, алар да XIV гасыр азагында төшенкелеккә дучар булганнар.

Шәһәрләрнең һәм шәһәр культурасының кризисы шактый иртәрәк — XIV гасырның 70 нче елларында ук башлана һәм политик-экономик характерда була. Шәһәрлекләрдән җыелган нумизматик материалга караганда, акча әйләнешенең кимүе һәм, димәк, бу шәһәрләрдә сәүдә-промышленность эшчәнлегенең дә сүлпәнләнүе 70—80 нче елларга карый. Бу факт шәһәрлекләрдә 70 нче елларга караган акчаларның табылмавы һәм Туктамыш тәңкәләренең аз гына процент тәшкил итүе буенча тәгаенләнә. XIV гасырның 60—70 нче елларындагы канлы бәрелешләр шәһәрләрнең экономик үсешен тоткарлыйлар. Бу бәрелешләрдә күчмә кабиләләр һәм күчмә феодаллар үзләрен ышанычлырак сизә. Иделнең уң ягындагы барлык көнбатыш олысларны яулап алган төмән башы [1] Мамай мисалында моны бик ачык күрергә мөмкин.

Аксак Тимернең Идел буендагы бик күп шәһәрләрне җимерүе һәм аларда яшәгән халыкны аяусыз кыруы җитештерү көчләрен юк итүгә, шәһәр үзәкләре эшчәнлегенең кысрыклануына китергән һәм бөтен Идел буенда диярлек күчмә элементларның көчәюенә булышлык иткән. Мәсәлән, Мамай Идел буендагы эре шәһәрләрдән булган Сарайны һәм Болгарны яулап ала алмаган, ә XV гасыр башында инде Идегәй Алтын Урданың кодрәтле хуҗасына әйләнә һәм жучидлар династиясенең үзе теләгән кешесен хан итеп куя ала.

XV гасыр башына Болгар җирләренең үзәгендә — Идел, Агыйдел һәм Чулман (Кама) буйларында күчмә кабиләләр өстенлек итә башлыйлар. Күчмә кабиләләр белән бәрелешүләр тышкы дошман белән көрәшү төсен

---

[1] Төмән — ун мең кешелек гаскәр.

алмый, югыйсә мондый көрәш шәһәрләргә, шул исәптән Болгарга да, мөстәкыйльлек алу һәм аякка басу өчен мөмкинлек биргән булыр иде. Бу кабиләләр этник яктан, әйтик, Болгарның үз халкыннан аз аерылган һәм аларның башында утрак тормыш үзәкләрендә хакимлек итүче шул ук жучидлар торган.

Акчаларга карап фикер йөрткәндә, XIV гасыр азагыннан алып акча сугу үзәге Кыпчак иленең иң читендә, Идел белән Чулман арасында, күчмә кабиләләр һөҗүм итә алмаслык җирдә урнашкан Казан шәһәренә күчә.

3. СУАР

Борынгы чорда Идел буенда эре шәһәр үзәкләренең берсе Суар шәһәре булган. Суарда Талип бин Әхмәт исеменнән 948—952 елларда сугылган акчалар билгеле.

Тарихи әдәбиятта Суар шәһәренең кайда урнашкан булуы бәхәсле мәсьәлә исәпләнә иде. Кайбер тарихчылар ул хәзерге Ульяновскидан берничә километр түбәндәрәк урнашкан Сембер шәһәрлеге урынында булган дип уйладылар. Башка төрле фаразлар да бар, ләкин Әхмеров Болгардан шактый якындагы бер шәһәрлекне җирле халыкның хәзергә кадәр Суар дип йөртүен ачыклады.

Борынгы Суар җирендә казу эшләре үткәрелде һәм анда кирпечтән салынган бай сарай калдыклары табылды.

Суарның тәмам таркалуы һәм бушап калуы исә бу җирләргә XIV гасыр азагында Аксак Тимернең басып керүе һәм, аның котыртуы буенча, шәһәрләрнең күчмә кабиләләр тарафыннан туздырылуы белән бәйле.

4. САРАЙ, САРАЙ ӘЛ-МӘХРУСА

Чыгарылу урыны «Сарай» дип билгеләнгән иң беренче акча һиҗри 681 елга карый (1282/1283).

Бу шәһәр моңа кадәр шактый элек нигезләнгән дип әйтергә кирәк. В. Рубрук 1254 елны Сарай шәһәрендә була һәм аны «Батый төзегән» яңа шәһәр дип атый. Шәһәрнең монголларга кадәр үк барлыкка килгән булуы да ихтимал, ләкин шәһәрлекнең культуралы катламы урыны-урыны белән 2—3 метрга җитсә дә, монгол явына кадәрге чорга карый торган катлам әлегә кадәр табылмады.

«Сарай» сүзенең ике мәгънәсе бар, берсе — өйдән башка теләсә нинди каралты-кура, икенчесе — пулат. Беренче мәгънәсе киң таралган һәм рус теленә дә кергән. Шуңа күрә Түбән Идел буенда Сарайларның күп булуына (Иске Сарай, Яңа Сарай, Сарайчык, Аксарай) карап, моны пулатлар төзетүче феодаллар һәм ханнар эшчәнлеге нәтиҗәсе дип уйлау нигезле түгел.

XIII гасырның 70 нче еллары башында ук инде Сарай Идел буендагы ике эре шәһәр үзәгенең берсе исәпләнгән.

Анда православие митрополиясе булуы да шәһәрнең зурлыгы турында сөйли. 1261 елны «Киев һәм бөтен Русь иле» митрополиты Кирил Сарай шәһәренә епископ итеп Митрофанны билгели.

Идел буенда акча сугу ирекле була, ягъни үзендә көмеш металлы булган һәркем тәңкәләр ясата алган. XIII гасырның 80 нче елларында акча сугу шактый киңәя, бу исә Сарай феодалларының куәте һәм йогынтысы үсә баруы турында сөйли. Тикшеренүчеләр Сарайда сугылган иң әүвәлге тәңкәләрнең үзенчәлекләренә игътибар итеп, акчадагы язуның Хәрәзмдә Туда Мәңге хан (1282—1287) хакимлек иткән вакытта чыгарыла башлаган аноним акчалар язуына тәңгәллеген күрсәтәләр. Бу фикернең дөреслеген раслап, шулай ук әлеге үзенчәлекләрнең монголларга кадәрге Урта Азия акчаларында аналоглары булуын күрсәтү белән бергә, мондый матур итеп язылган «чәчәкле куфи»га хас барлык үзенчәлекләрнең дә элегрәк Мәңге Тимер (1266—1282) заманындагы Болгар акчаларында очравын әйтергә кирәк. Бу исә һич тә очраклы хәл түгел. Мәңге Тимер акчаларында беренче тапкыр монголның каан дәрәҗәсенә тиң «солтан» титулы күренә башлый. Мөстәкыйль хөкемдар буларак, аның акчалары Батый яисә Беркә хан заманындагы акчаларга караганда күркәмрәк итеп сугылганнар. Әлбәттә, соңрак «чәчәкле куфи» Хәрәзм акчаларында киңрәк тарала, Сарай тәңкәләрендә исә Идел буена хас язу стиле — нәсех өстенлек итә.

Беренче Сарай тәңкәләренең кайберләре, Мәңге Тимер чорына караган Болгар акчаларындагы кебек үк, сугылу урынын күрсәткән өлгене саклый: «Бу дирһәм Сарай шәһәрендә сугылды».

Әүвәлге Сарай акчаларының авырлыгы Болгар акчаларыннан беркадәр аерыла. Алар авыррак һәм уртача 2,25—2,30 грамм итеп сугылганнар, ләкин Беркә

хан керткән акча-авырлык системасы чикләреннән чыкмыйлар. Бик ихтимал, тәңкәләр 2,34 грамм, ягъни 3 дәник (0,78·3=2,34) авырлык нормасы буенча сугылгандыр, ә Болгар акчалары 2 дәник (0,78·2=1,56) авырлыкта булган.

XIII гасырның соңгы чиреге Кыпчак иленең зурзур аймакларына җәелгән үзара сугышларда үтә. Нәкъ менә шушы чорда Сарайда, Биләр һәм Хәрәзм кебек провинциаль шәһәрләрдә акча сугу эше кабат җайга салына. Эчке сугышлар тәхеткә Тукта хан (1291—1312) менү белән тәмамлана. Шул вакыттан алып провинциаль үзәкләрдәге акча сугу сарайлары үз акчаларында тәхеттәге ханның исемен күрсәтә башлыйлар.

Сарай алпавытлары, Болгарныкылардан аермалы буларак, тәхеткә менгән яңа ханны шундук таныйлар. Тукта хан тәхеткә утыру белән үк Сарай акчаларында аның исеме күрсәтелә. Беренче тапкыр акчаларда хан исеме уйгыр шрифты белән языла. Күрәсең, биредә монголлар яклы феодалларның йогынтысы көчле булган. Ихтимал, Тукта хан үзе шундый ук политиканы үткәрергә тырышкандыр. Һәрхәлдә Болгарда династияара бәрелешләр вакытында аноним акча сугу Тукта хан тәхет башына менгәч тә беркадәр вакыт дәвам итә һәм бу яңа ханга каршы юнәлтелгән булган дип уйларга кирәк. Һиҗри 692 елгы (1292/1293), ягъни фактта Тукта хакимлек иткән вакытта сугылган аноним Болгар акчалары мәгълүм. Мондый дуамал эшләре өчен Болгар феодаллары җәзасын алганнар булса кирәк. 1310—1311 елларда Тукта хан үткәргән акча-авырлык реформасыннан соң, Болгардагы акча сугу сарае ябылган. Төп акча сугу үзәге Сарайга күчә, ә реформадан соң аның акчаларында «әл-Мәхруса» (ягъни «имин», «иминлеге тәэмин ителгән») эпитеты күренә.

Үзбәк хан (1312—1342) вакытында Сарай феодалларының хокуклары чикләнә төшкән дип уйларга кирәк, чөнки бу чорда Сарай әл-Мәхрусада сугылган акчалар әллә ни күп түгел. Болгар феодаллары үзләренең хокукларын кире кайтарып алуга ирешкәннәр. Бу чорда Болгарда акча шактый күп сугыла һәм аларда да «әл-Мәхруса» эпитеты күренә башлый.

Ләкин «Сарай әл-Мәхруса» дип күрсәтелгән акчалар, сирәк булса да, XIV гасыр буена чыгарылып килә.

Түбән Идел буендагы шәһәр үзәкләрен Аксак Тимер җимергәннән соң, ике Сарайның берсендә генә акча сугу эше сакланып кала. «Сарай» дип күрсәтелгән соңгы акчалар Олы Мөхәммәт (1421—1445) исеменнән сугылганнар.

5. САРАЙ, САРАЙ ӘЛ-ҖӘДИД

XIV гасырда Идел буенда акча сугу үзәкләреннән тагы бер әһәмиятле үзәк Сарай яки Сарай әл-Җәдид булган. Көнчыгыш авторлары (мәсәлән, әл-Гомәри) аны Беркә хан исеме белән бәйлиләр һәм, күрәсең, бу очраклы хәл түгелдер. Инде Батый заманнарында ук Беркәгә Тимер Капка (Дербентның төркичә исеме) төбәгеннән «Итил аръягына көнчыгышка», ягъни булачак шәһәр тирәсенә күчәргә әмер бирелгән була. Гәрчә Патша шәһәрлегендә (Сарай әл-Җәдидтә) XIII гасырга караган катлам табылмаса да, XIII гасырда монда кечерәк шәһәрчек торган булырга мөмкин. Шунда ук хәлиф Насыр лид-дин (1180—1225) акчасы табыла. Насыр лид-дин акчаларының бер өлеше Мункә хан заманында кабат сугылганын искә алсак, алар XIII гасырның 50 нче елларында да әйләнештә йөргәннәр әле. XIV гасырда сугылу урыны «Сарай» дип күрсәтелгән беренче акчалар Үзбәк хан (1312—1342) чорында күренә. Көмеш тәңкәләрдә «әл-Җәдид» — «яңа» эпитеты Җанибәк (1342—1357) ханлык иткән елларда гына күренә башлый.

Без XIV гасырда сугылу урыны «Сарай» дип күрсәтелгән акчаларны Яңа Сарайныкы дип уйлау ягында торабыз. Дөрес, гасыр башында бу шәһәр әле кечкенә булган, күрәсең. Ләкин Үзбәк хан идарә иткән елларда акчаны Үкәк яки Мукшы шәһәре кебек уртача зурлыктагы күп кенә шәһәрләрдә сукканнар, ә XIV гасырның 60 нчы елларында акча сугу эше хәтта бернинди шәһәре дә булмаган төрле урдаларда да җайга салынган. Үзбәк хан заманына караган хәзинәдәге тәңкәләрнең процент нисбәте XIV гасырда акча сугу үзәкләре Сарай һәм Сарай әл-Мәхрусаның берберсеннән шактый ерак урнашкан булуын күрсәтә (ул вакытта XIII гасыр акчалары әйләнештә йөрми инде). Мәсәлән, 1965 елда табылган Болгар хәзинәсендә иң күбесе — Болгарда сугылган акчалар (139), Сарай акчалары икенче урында (44) һәм Сарай әл-Мәхруса тәңкәләре соңгы урында (6). Әгәр дә Сарай һәм Сарай әл-Мәхруса бер үк акча сугу үзәге булсалар, алар чы-

гарган тәңкәләр Урта Идел буе базарларына һәрхәлдә бер нисбәттәрәк эләгергә тиешләр иде. Факт исә Урта Идел хәзинәләренең составы ераграк урнашкан Сарай әл-Мәхруса акчаларының бирегә Сарай акчаларына караганда сирәгрәк эләгүен күрсәтә.

Сарай әл-Җәдид әле Үзбәк хан идарә итә башлаган елларда кечкенә шәһәр булган һәм анда сугылган акчалар нигездә Болгар һәм Сарай әл-Мәхруса төбәкләренә — акча әйләнеше көчле булган урыннарга киткән. Моңа Г. А. Федоров-Давыдов игътибар итә һәм Патша шәһәрлегендә Үзбәк хан тәңкәләренең аз очравы акча әйләнеше чагыштырмача сүлпән булудан килә һәм моны Үзбәк хан чорына караган катламга аларның азрак эләгүе белән аңлатырга мөмкин дип саный.

Үзбәк хан хакимлек иткән чорның ахырына Сарай әл-Җәдид зур башкалага әверелә. Әгәр Сарай әл-Мәхрусаны Болгардан өстен күргән Тукта ханның эшчәнлегендә Батыйга хас кайбер тенденцияләрне күреп булса, Идел буенда ислам идеологиясен ныгыткан һәм башкаласын Сарай әл-Җәдидкә күчергән, шулай ук Болгар феодалларын яклаган Үзбәк ханда мөселманнар арасында зур хөрмәт казанган Беркә хан политикасының дәвамын күрергә мөмкин.

XIV гасыр буена Сарай әл-Җәдид дәүләтнең башкаласы һәм эре акча сугу үзәге булып кала.

1395 елда Аксак Тимер Сарай әл-Җәдидне җимерә. Сарай әл-Җәдидтә сугылган соңгы акчалар XV гасырның беренче чирегенә — Дәүләтбирде заманына карыйлар һәм алар, бик ихтимал, аның урдасында, Сарай әл-Җәдид тирәсендә сугылгандыр.

6. БИЛӘР

XIII гасырда күмелгән хәзинәләрдә Биләр шәһәрендә сугылган аноним тәңкәләр очраштыра. Алардагы язуның үзенчәлеге һәм ачыклыгы аны «Биләр» сүзеннән башка сүз белән бутарга урын калдырмый. Мондый тәңкәләрнең алгы ягында Сиккәтүн Биләр, ягъни «Биләрдә сугылган акча» дип язылган. Арткы якта дүрткел яки алты почмаклы кыса эчендә «тамга-и гали» бар. Акчалар датасыз, ләкин XIII гасырның 60—80 нче елларына хас булган авырлык нормасы буенча сугылганнар. Бу акчалар чуалышлар булган чорда сугылганлыктан, хронологик чикләрне тарайтырга да була. Хәрәзм яки Сарайның аноним ак-

чалары кебек үк, Биләр тәңкәләре дә XIII гасырның 80 нче елларында сугылган, күрәсең.

Биләрнең үз акчасын сугуы аның да, Болгар, Суар яки Идел буеның башка шәһәрләре кебек үк, монгол явыннан соң торгызылганлыгы турында сөйли. Биләрдә шулай ук һиҗри 690—692 (1291—1293) елларда сугылган аноним акчалар билгеле.

Шушы аноним акчалардан башка, Биләрдә сугылган тәңкәләр фәнгә мәгълүм түгел. XIII—XIV гасырларда, мөһим сәүдә юлларыннан читтә яткан Биләр, соңрак та яшәп килүенә карамастан, үзенең әһәмиятен югалта, күрәсең. XIV гасырда Аксак Тимер явы турында язганда Йезди Биләрне дә телгә ала.

7. ҮКӘК

Тукта хан (1291—1312) исеменнән сугылган Үкәк акчалары билгеле, алар арасында уйгырча язылган бакыр тәңкәләр дә бар. Борынгы төрки телдән тәрҗемә иткәндә «Үкәк» — «ныгытма», «манара» дигән сүз. Уртача зурлыктагы бу шәһәр Болгардан көньяктарак Иделнең уң як ярында урнашкан булган. 1262 елны итальян сәяхәтчеләре бертуган Пололар Болгардан соң Үкәк шәһәренә төшкәннәр. Уңайлы сәүдә юлында урнашкан шәһәрнең чәчәк ату чоры XIV гасырга туры килә. Үзбәк хан вакытында биредә Генуя сәүдәгәрләренең бер терәк пункты булган.

Үкәк шәһәрлегендә табылган тәңкәләр Үкәктә акча әйләнеше XIII гасырда башланып, Үзбәк хан заманында көчәйгәнлеген күрсәтәләр.

Һәвәскәр нумизматлар арасында Үкәктә XIII гасырда сугылган уйгырча язулы бакыр акчалар зур кызыксыну уята. Ләкин аларда әллә ни мәгълүмат юк. Алгы якларына «Солтан Насретдин» дип, ә арткы якларына «Сарб Үкәк», ягъни «Үкәктә сугылды» дип язылган. Насретдин исә Тукта ханның мөселманча исеме.

Югарыда күрсәтелгән акчалар аз чыгарылган. Үкәк шәһәрлегендәге акчаларның төп массасы Сарай әл-Җәдидтә яки Гөлстанда сугылган.

Үкәктә соңгы тәңкәләрне XV гасырда сукканнар.

8. ХАҖИТАРХАН (ӘСТЕРХАН)

Идел буеның кайбер башка шәһәрләре кебек үк, Хаҗитархан шәһәре дә XIV гасырда чәчәк ату чорын кичерә. Мөһим сәүдә юлында — Иделнең тамагында

урнашкан бу шәһәр урта гасыр сәүдәсендә әһәмиятле урын тоткан.

Хаҗитарханның беренче акчалары Хаҗичиркәс исеменнән XIV гасырның икенче яртысында сугылган. Туктамышка (1379—1395) кадәр тархан биләмәсенең үзәге булган Хаҗитархан тирәләрен 1379 елда Бирдебәк үлгәннән соң башланган чуалыш елларында Хаҗичиркәс кулга төшерә. Хаҗичиркәснең үз исеменнән акча сугуына карап фикер йөрткәндә, аның хаким династия нәселеннән булуы һәм шактый иммунитет хокукыннан файдалануы күренә, чөнки ул Түбән Иделдә көчле бәрелешләр булган болганчык елларда да дәгъвалардан читтә кала. Исеменә караганда, ул күптәннән шәһәр хуҗасы булган хаҗиләр нәселеннән. Идел буйларында Үзбәк хан чорында ук булып киткән Ибн Батута Хаҗитархан шәһәре үз исемен «төрки хаҗи исеменнән алган» дип яза.

Туктамыш хан тәхеттә утырган елларда Хаҗитарханда акча аның исеменнән сугыла.

1395 елда Хаҗитархан да Аксак Тимер тарафыннан җимерелә. Соңыннан шәһәрне торгызалар. «Цитрахань шәһәре хәзер бөтенләй җимерек диярлек,— дип яза Йософат Барбаро.— Элек исә ул үзенең зурлыгы һәм байлыгы белән дан тота иде. Аксак Тимер җимергәнче Танага тәм-том һәм ефәк Цитрахань аркылы китерелә һәм анда инде алты яки җиде Венеция галерасында Италиягә ташыла иде».

XV—XVI гасырларда Хаҗитархан ханлык башкаласы була. Анда Әхмәт хан (ихтимал, Кече Мөхәммәтнең улыдыр) исеменнән һиҗри 862 елда (1457/1458) сугылган акчалар билгеле.

9. МУКШЫ

Мукшы шәһәренең беренче тәңкәләре Үзбәк хан хакимлек итә башлаган елларга карый. Шәһәр үзе нигездә акчалар һәм рус язма чыганаклары буенча Наручат (Наровчат) исеме белән билгеле. Мукшыда акча әйләнешенең көчәюе Үзбәк хан чорына туры килә һәм XIV гасырның 60 нчы елларына кадәр дәвам итә.

Бирeдә бакыр пуллар бик күп сугылган. Алар, югалып, шәһәр территориясендә ятып калганнар. Наручат шәһәренең нумизматик материаллары буенча (ә анда Мукшы акчалары зур процент тәшкил итә), нумизмат А. А. Коротков Наручатны XIV гасырдагы Мукшы шәһәре белән тәңгәлләштерә.

10. САРАЙЧЫК

Сарайчыкта акча XIV гасырның уртасындагы һәм икенче яртысындагы чуалышлар вакытында сугылган. Сарайчыкта һиҗри 761 елда (1359/1360) сугылган Хызыр тәңкәләре билгеле. Ләкин сәүдәгәрләр һәм сәяхәтчеләр (Пеголотти, Ибн Батута) Сарайчык шәһәрен моңа кадәр дә телгә алалар. Пеголотти сүзләренә караганда, Сарайдан Сарайчыкка кадәр «8 көнлек су юлы, анда коры җирдән дә барырга була, ләкин товар ташу арзанрак булганлыктан, гадәттә су юлы белән йөриләр».

Сарайчыкның хәрәбәләре Җаек (Урал) елгасының көнбатыш ярында, Гурьев шәһәреннән 48 километр ераклыкта урнашкан. Шәһәрлек археологик яктан өйрәнелмәгән диярлек.

Сарайчыкта соңгы акчалар Туктамыш ханлык иткән чорда сугылган. Кече Әтрәстә табылган шундый тәңкәләр хәзинәсендә һиҗри буенча 782 ел (1380/1381) белән билгеләнгән акчалар 4 данә очрады.

11. БАРЧИН

Бу шәһәрнең исеме акчаларда б. р. ч. н рәвешендә язылган. Андый бакыр акчалар чагыштырмача сирәк һәм аларның күпчелеге Волгоградтан югарырак урнашкан Водянск шәһәрлегендә табылган. Урта гасырларда яшәгән гарәп авторлары бу шәһәрне Белҗәмин дип, ә Аксак Тимер тарихчылары Бәлчимкин дип атыйлар. Шәһәр Идел белән Дон елгасы бер-берсенә якын ук килгән җирдә урнашкан булган. Хәтта XVI гасырда да инглиз сәяхәтчеләре Антоний Дженкинсон һәм X. Берроу, бу урынны телгә алып: «...узган заманнарда монда татарлар үзләренең көймәләрен Иделдән Танаиска сөйрәп китергәннәр...» — дип язалар.

Барчинда бакыр акчалар Җанибәк солтанлык иткән (1342—1357) чорда чыгарыла. Монда сугылган башка тәңкәләр мәгълүм түгел. Археология мәгълүматларына караганда, биредә хазар культурасының йогынтысы зур булган, һәм бу яктан Барчин Идел буендагы башка шәһәрлекләрдән аерылып тора.

12. ГӨЛСТАН, ГӨЛСТАН ӘЛ-МӘХРУСА, ГӨЛСТАН ӘЛ-ҖӘДИД

Җанибәк тәхеткә утыргач (1342—1357), инде әйтеп кителгәнчә, Болгарда сугылган акчалар кинәт юкка чыга, аның каравы тәңкәләрдә Сарай әл-Җәдид

белән бергә, элек билгеле булмаган яңа акча сугу үзәге — Гөлстан пәйда була. Сан ягыннан аның тәңкәләре, ихтимал, башкалада сугылган акчалардан гына калыша торгандыр.

Гөлстанның исеме гарәп, фарсы һәм рус язма чыганаклары буенча билгесез, ягъни бу исем нигездә акчаларда гына сакланган һәм бу хакта бик күп бәхәсләр булды. Х. М. Френ, Гөлстан, ихтимал, Сарай тирәсендә булгандыр, дип фараз итә. Икенче бер ориенталист, В. В. Григорьев, акчаларда исеме очрый торган Гөлстан — ханның пулаты гына һәм ул Сарай шәһәрендә булган, дип исәпли. Н. Веселовский, Гөлстанның урынын конкретлаштырып, ул Колобов курганы янында Яңа Сарайдан җиде чакрым чамасы ераклыкта торган, дип саный. В. К. Трутовский, кайбер тәңкәләрдә «Гөлстан» сүзе алдында «шәһәр» сүзе дә булуына таянып, аның белән бәхәскә керә һәм, бу аерым бер шәһәр булган дип санап, аны Сарай әл-Мәхруса белән тәңгәлләштерә. Бу мәсьәләгә кагылган икенче мәкаләсендә ул элеге гипотезасыннан баш тартса да, Гөлстанның мөстәкыйль шәһәр булуы турындагы фикереннән кайтмый.

Хәзерге нумизматик әдәбиятта бу мәсьәлә белән махсус шөгыльләнгән кеше күренми һәм Гөлстан — Яңа Сарайның бистәсе, дигән фикер бәхәссез кабул ителә. Ләкин XIV гасырның 70 нче елларында сугылган акчалар шуны күрсәтә: ханнар әледән-әле алмашынган бу елларда аларның кайберләре акчаны бер генә шәһәрдә яки, тәхеттә озаграк утырган булсалар, берничә шәһәрдә, әйтик Сарай әл-Җәдидтә яки Гөлстанда гына яисә икесендә дә сугып өлгергәннәр. Гөлстан Сарай әл-Җәдидтән шактый ерак урнашкан булырга тиеш, өстәвенә Гөлстаннар ким дигәндә икәү — Гөлстан әл-Мәхруса һәм Гөлстан әл-Җәдид дигән акча сугу үзәкләре булган.

Гөлстан әл-Җәдидтә һиҗри 789 елда нindидер Бирдебәк хан исеменнән сугылган акчалар билгеле. Димәк, алар Сарайда яки аның бистәсендә сугылган дип уйлау мөмкин түгел, чөнки анда бу вакытта Туктамыш ханлык иткән һәм аның исеменнән шул ук еллар белән билгеләнгән акчалар сугылган.

Хәзерге заман нумизматикасы теге яки бу шәһәрлектән җыелган тәңкәләр комплексын өйрәнеп, акча сугу үзәгенең кайда булганлыгы турындагы бәхәсле мәсьәләләрне ышанычлырак хәл итәргә мөмкинлек

бирә. Инде Ф. В. Баллод ук Патша шәһәрлегендә табылган ике йөздән артык тәңкәләрнең 195 е (86% ы) — Яңа Сарайда, фәкать 3 данәсе генә Иске Сарайда сугылган булуына игътибар итә.

Болгар шәһәрлегендәге көмеш һәм бакыр акчаларны өйрәнү күрсәткәнчә, «Гөлстан» дип күрсәтелгән тәңкәләрнең төп массасы нәкъ менә шушында табылган. Билгеле булганча, көмеш акчалардан аермалы буларак, бакыр пуллар үзләре сугылган шәһәрдән читкә чыкмаганнар диярлек. Болгар шәһәрлегендә Хызыр ханның Җ. Г. Мөхәммәтшин тапкан 28 бакыр пулыннан 18 е Гөлстанда сугылган.

Кече Әтрәс хәзинәсендә табылган тәңкәләр билгеле бер авырлык нормасына туры китереп киселгәннәр һәм Урта Идел буенда әйләнештә йөргәннәр һәм шунда тупланганнар. Менә шул акчалар комплексында бик күбесе Гөлстанныкылар. Мисал өчен, Сарай әл-Җәдид яки Гөлстанда Мөрид хан исеменнән сугылган тәңкәләр моңарчы данәләп кенә санарлык булса, Кече Әтрәс хәзинәсендә аның Гөлстанда сугылган 348 тәңкәсе очрый. Ә Сарай әл-Җәдидтә аның исеменнән сугылган акчалар бу хәзинәдә бөтенләй юк. Шул ук хәзинәдәге нибары 6 данә Газизшәех тәңкәсе Сарай әл-Җәдидтә сугылган, ә Гөлстанда, Гөлстан әл-Мәхрусада һәм Гөлстан әл-Җәдидтә сугылганнары 95 данә. Болгар йортында тәхеттә утыруы язма чыганаклардан мәгълүм булган Булаттимер акчалары фәкать Гөлстанда гына сугылганнар.

Бу яктан алганда, Идел буеның төрле шәһәрлекләрендә табылган акчалар комплексында Гөлстанда сугылганнарын чагыштыру бик гыйбрәтле. В. Ф. Баллод Патша шәһәрлегендә (Сарай әл-Җәдидтә) тапкан акчалар арасында 195 Сарай тәңкәсе һәм нибары 25 данә Гөлстан тәңкәсе булган. Статистик мәгълүматлар күрсәткәнчә, Селитра шәһәрлегендә (Сарай әл-Мәхруса) табылган акчалар арасында Гөлстанда сугылганнары фәкать 7 генә (ә Сарайда сугылганнары — 210), Наручат (Мукшы) шәһәрлегендә — 5 данә (Мукшы тәңкәләре 227). Югарыда әйтеп үтелгән Патша шәһәрлегендә 1959—1962 елларда казып табылган 1035 данә металл акча арасында Гөлстанда сугылган тәңкәләр фәкать 98 данә, ә Сарай әл-Җәдидтә сугылганнары 673 данә тәшкил итә.

Болгар шәһәрлегендә табылган 1697 данәлек тәңкәләр коллекциясендә исә Гөлстанда сугылганнары

279 данә, ягъни Патша, Селитра һәм Наручат шәһәрләрендә табылганнардан 2,5 тапкыр артык.

Шулай итеп, фактлар Гөлстанда сугылган тәңкәләргә бөтенләй башка күзлектән карарга мөмкинлек бирә. Металл акча материалының сугылган шәһәрләренә карап закончалы нисбәттә таралышы, серле Гөлстанның кайдадыр Болгар йорты чикләрендә, бәлки әле шәһре Болгарның үзендә булуы турында сөйли, чөнки бу чорда «Болгар» исеме белән сугылган тәңкәләр билгеле түгел.

«Гөлстан» — гөлбакча дигән сүз. Билгеле булганча, XIII гасырда ук инде Болгарда хан резиденциясе була һәм 1261 елда бертуган Пололар шунда булып китәләр. Җанибәк тәхеткә менгәч, акчаның Гөлстанда, ихтимал, ханның акча сугу сараенда гына чыгарыла башлавы Үзбәк хан заманында зур политик йогынтыдан файдаланган Болгар алпавытларының интересларын шактый кысрыклаган дип уйларга кирәк.

Икенче бүлек

ИДЕЛ БУЕНДА ҺӘМ УРАЛ ЯКЛАРЫНДА ХАЗАРЛАРГА КАДӘР АКЧА ӘЙЛӘНЕШЕ

Көймәгә утырып чыккан өчен көймәче фил сөяге сорады... Ә ул нәрсә миндә юк иде, ләкин мин Мөхәммәт ибн Салибта андый сөяк барлыгын, һәм аңа, үз чиратында, өс киеме кирәклеген белдем. Миндә аныcы да булмагач, бу мәгълүмат миңа әллә ни ярдәм итмәде, тик мин Мөхәммәт ибн Гаарибта кием бар икәнен һәм аңа тимерчыбык кирәклеген белештем. Ә моныcы, бәхеткә каршы, миндә бар иде. Шул рәвешле мин Мөхәммәт ибн Гаарибка кирәк кадәр тимерчыбык бирдем, аның бәрабәренә ул Мөхәммәт ибн Салибка кием бирде, тегесе, үз чиратында, шуңа алмашка идарәче Сай ибн Габибка кирәгенчә фил сөяге бирде, шуннан соң мин, ниһаять, көймә ала алдым.

***Камерон,** сәяхәтче*

Идел буе һәм Урал ягы тарихында бик кызыклы мәсьәләләрнең берсе — акча әйләнешенең бик иртә барлыкка килүе. Билгеле бер авырлыкта итеп коелган бронза сомнары — Идел һәм Урал буйларында ясалган беренче акчалар бу ~~төбәкнең~~ борынгы тарихы

белән, феодаль мөнәсәбәтләр барлыкка килү һәм үсү белән бәйләнгән.

VII гасырда Көнчыгыш Европада беренче феодаль дәүләт, куәтле хазар каганлыгы оеша һәм ул көч ала барган саен Идел буе һәм Урал ягы кабиләләре арасындагы һәм алар белән башка илләр арасындагы сәүдә элемтәләре ныгый.

Хезмәт бүленеше чагыштырмача түбән булган вакытта ук инде Көнчыгыш Европаның күп кенә кабиләләре хезмәт продуктлары һәм көнкүреш әйберләре алмаша, ягъни сәүдә итә башлаганнар. Археологлар борынгы кешеләрнең торакларын казып, мондый алмашуның таш гасырында ук булганлыгын ачыкладылар. Алмашу вакытында әкренләп берәр товар (мәсәлән, тоз) эквивалентка әйләнә, ягъни барлык башка товарлар шушы товарның билгеле бер күләменә бәрабәр дип санала башлый һәм, шул рәвешле, беренче акча барлыкка килә.

Борынгы заманда, металл акчалар уйлап чыгарылганга кадәр, күп кенә халыкларда акчаның бик киң таралган формасы булып мал-туар хезмәт иткән. Мәсәлән, татар сүзе «мал» терлекне дә белдерә, акча, байлык, товар мәгънәсендә дә кулланыла. XIII гасыр башларында сугылган болгар акчаларындагы «мал» сүзенең «акча» мәгънәсендә булуы очраклы хәл түгел. «Капитал» сүзенең дә «баш» сүзеннән килеп чыкканлыгын әйтеп китик, ә мал-туарны баш исәбе белән санныйлар.

Тиздән акча роле тулысынча металларга, мәсәлән бронзага, ә соңрак алтын һәм көмеш кебек затлы металларга күчә, чөнки алар тутыкмый, бу металларны бүлгәләү җиңел, сирәк очраганлыктан, алар зур кыйммәткә ия. Затлы металларга арзанлы металлар кушып ялган акча ясауга комачау итү өчен дәүләт власте металл акчаларга келәймә суга башлый [1]. Беренче тәңкәләр шулай барлыкка килә.

Язма чыганакларга караганда, Идел һәм Чулман (Кама) буенда хазарлар, болгарлар, суарлар һәм башкортлар, ә төньякта һәм төньяк көнбатышта угро-фин кабиләләре яшәгән. Төрки кабиләләр урман-дала төбәкләрен, ә угро-фин кабиләләре иксез-чиксез урман-

---

[1] Борынгы төрки телендә келәймә *тиген* дип аталган. Без хәзерге тиен сүзе җәнлек тиресеннән түгел, ә шул тиген сүзеннән килеп чыккан дигән фикердә торабыз.

нарны белгәннәр. Мондый күршелек аларга экономик һәм политик яклардан файдалы булган. Нәкъ менә шушы төбәктә башка халыкның идеологиясенә, теленә һәм культурасына түземле караш, индифферентизм күзәтелү бер дә очраклы хәл түгел.

Төрки халыклар бу төбәккә, дулкын-дулкын булып, безнең эра башларында ук килеп чыга. Җәен алар елга үзәннәре буйлап төньякка күтәрелгәннәр, ә кышка далаларга — мал-туар көтүләре юка кар катламы астыннан тибенеп тукланырлык җирләргә төшкәннәр.

Безнең эраның IV—VII гасырларында Идел һәм Урал буйларында төрки элементларның көчәюе күзәтелә. Төрки халыклар, күрәсең, Иделнең көньяк-көнчыгышына да, көньяк-көнбатышына да килеп утырганнар. Җирле халык сәүдә алмашына катнашып киткән. Мондый алмашу баштарак бик примитив булган әле: сәүдәгәрләр сөйләшеп килешенгән урында алмашка дип товарларын калдырганнар, ә җирле кабиләләр, сәүдәгәрләр югында бирегә килеп, үз товарларын калдырганнар һәм үзләренә тиешле товарны алып киткәннәр. Бирედә алмашып алынган затлы тире һәм мех Ерак Көньякка, мондый товарга ихтыяҗ зур булган Иранга, Византиягә һәм гарәп хәлифәлегенә озатылган.

Бу якларда затлы металлдан Хәрәзмдә, Византиядә һәм Иранда эшләнгән күпсанлы әйберләр һәм тәңкәләр табылу көньяк илләре белән сәүдә-алмашу элемтәләренең үсә баруы турында сөйли.

Бирегә көньяк илләреннән кыйммәтле металлардан, күбесенчә көмештән нәфис итеп ясалган төрле савыт-саба да китереп сатканнар. VII гасырда көмешнең аеруча күп килүе сәүдә эшенең тагы да көчәюен күрсәтә. Идел һәм Чулман (Кама) буйларында, Урал якларында табылган күпсанлы көмеш савытлар Ленинградта Эрмитаж стендларын, Париждагы Милли китапханәнең медальләр кабинетын һәм дөньяның башка музейларын бизиләр.

Кама буенда табылган һәм галимнәргә билгеле булган савытлар берничә дистәгә җитә. Бу табылдыкларның Идел һәм Урал белән акча әйләнешен өйрәнү өчен генә түгел, бәлки Иранның культурасын һәм аның башка илләр белән бәйләнешләрен өйрәнү өчен дә зур әһәмияте бар, чөнки Иранның үзендә сасанид

савыт-сабасы бик аз табылган (өч яки дүрт шундый савыт табылуы билгеле).

Кама буенда табылган көмеш әйберләр Иранны гарәпләр яулап алганчы, 208—651 елларда анда хакимлек иткән сасанидлар династиясе исеме буенча, шартлы рәвештә, сасанид көмеше дип йөртелә.

Бу савытларда нәфис итеп чүкеп эшләнгән төрле сурәтләр: атлы сугышчылар, көрәш һәм җәнлек аулау күренешләре һ. б. бар. Иран патшалары сурәтләнгән сюжетлар еш очрый. «Бу патшаларның берәрсе үлгәндә,— дип яза Масуди,— аның сурәтен төшергәннәр... һәм (сурәтне), үлгәннәрнең истәлеге булып калсын өчен, хәзинәгә куйганнар...»

Касәләрдә хәрәзми, согди, төрки (руник) һ. б. язмалар очрый, кайчак аларда мондый касәләрнең «јamaq», ягъни «савыт» дигән исеме дә күрсәтелә. Татар һәм башкорт телендәге «җамаяк» сүзе әнә шул чорларга ук барып тоташа икән. Борынгы савыт-сабада бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән «пул» сүзе (акча мәгънәсендә) дә очрый.

Товар алмашу-сәүдә элемтәләре сасанид Ираны белән генә түгел, Византия белән дә җайга салынган була. Кама буенда табылган Византия савыт-сабасы һәм тәңкәләре моны бик ачык күрсәтә. Аларны гадәттә очраклы рәвештә, җир эшләре вакытында табалар. Мәсәлән, 1925 елны Пермь өлкәсенең Бартым авылы игенчесе Г. Дәүләтшин сабан сөргәндә VI гасырга караган Византия касәсенә тап була, ә 1949 елны шул ук басуда бригадир Кәлимуллин авыр көмеш кубок табып ала. 1950 елны шунда ук колхозчы Фәезханов 264 данә Византия тәңкәсе тутырылган зур көмеш кувшин тапкан.

Сасанид һәм Византия әйберләренең күпчелеге чирәм күтәргәндә табыла, ягъни алар җиргә бик тирән күмелмәгәннәр. Шуңа күрә кайбер галимнәр бу савытларны хәзинә итеп яшермәгәннәр, бәлки Кама буе һәм Көнбатыш Урал төбәге кабиләләре изгеләштергән урыннарга куйган булганнар, дип исәпләгән. Тарихчылар һәм этнографлар Кама һәм Вятка буйларында яшәгән халыкларның әле күптән дә түгел карурманнар эчендә табыну урыннары оештыруы турында сөйлиләр. Мәсәлән, агач потка кием кигезгәннәр дә шуңа тәңкәләр һәм төрле савыт-саба элгәннәр. Ләкин бу күзәтүләрнең XVIII—XIX гасырларга караганын һәм Кама буенда табылган сасанид һәм Византия металлы-



а

1 нче рәсем.

а — көмеш савыттагы канатлы бүре;
б — акча урынына йөргән көмеш савыт.



б

ның замандашы булган кабиләләрнең дини йолаларына турыдан-туры бәйләнмәгәнлеген дә әйтергә кирәк.

Әгәр мондый бәйләнеш булса, без биредә VIII—X гасырларның хазар савытларын, куфи акчаларын һәм X—XV гасырларга караган болгар-татар акчаларын да табар идек. Ә алар табылмый. Күрәсең, Кама буенда III гасырдан башлап көмеш әйберләр җыелуын һәм

көмеш тупланунын VII гасырда көчәюен тулаем Идел һәм Урал буйларында экономика һәм культураның закончалы төстә үсеше белән бәйләп карарга кирәктер. Әйтик, Пермь өлкәсендә көмеш савытлар һәм акчаларның еш табылуы якын-тирәдә шәһәрлекләр, тораклар һәм каберлекләр ачылуга китерә, бу исә анда көчле экономик үзәк булганлыгына бер дәлил. Хәлбуки, баштарак мондый үзәк X—XII гасырлардагы Болгар шәһәрләреннән Кама буйлап төньяктарак урнашкан булган.

Хәрәзм яки Туран (яңа эрага кадәр I гасыр — VIII гасырлар) һәм Рим (безнең эраның I—V гасырлары) тәңкәләре — бу төбәктә табылган иң борынгы акчалар. Ләкин Рим акчалары Көнчыгыш Европаның һәр төбәгендә очрый. Шуны да әйтергә кирәк, биредә акчалар үзләренең туры функцияләрен югалткан булырга тиеш. Ул заманнарда Көнчыгыш Европа кабиләләре үсешнең түбән баскычында торганнар һәм турыдан-туры товар алмашуны (натураль алмашу) гына белгәннәр. Фәкать соңга табарак, Идел һәм Урал буйларына сасанид тәңкәләре күпләп килә башлагач кына чикләнгән күләмдә акча әйләнеше турында сүз алып барырга мөмкин.

Кама буенда Византия акчаларыннан 610—641 елларда хакимлек иткән Ираклий һәм аның улы Ираклий Константин акчалары табылды.

Бартым хәзинәсендә Ираклий акчалары (алар 264 данә) барысы да бер типта, ягъни алар аз гына да кулда йөрмәгәннәр. Бу исә аларның турыдан-туры императорның акча сугу сараеннан алынып, берәр юлбашчыга бүләк ителгәнлеген күрсәтә.

Без бу акчаларның һәм савытларның Кама буена ничек килеп эләгүе турында төрле гөман-фаразлар гына кора алабыз, ләкин алар бирегә очраклы рәвештә генә килеп эләкмиләр, әлбәттә. Аларның монда күпләп туплануы бу якларга төрки телдә сөйләшүче кабиләләр килү вакытына туры килә.

Идел һәм Урал буйларына сасанид көмеше көньяк-көнбатыш юл буйлап кына түгел, бәлки көньяк-көнчыгыш юллар буйлап та килгән дип фараз итәргә мөмкин. Сирия чыганакларыннан сасанид көмешенең көньяк-көнчыгышта эфталитлар дәүләте аркылы хәрәкәт итүе аңлашыла. Мәсәлән, бу чыганакларда бер сугышта эфталитларның фарсы гаскәрен тар-мар китереп, шаһиншаһның үзен әсир итүләре язылган. Ша-

һиншаһ Пероз үзен азат итсәләр, затлы нәрсәләр тәлгән 30 качыр вәгъдә итә. Туктаусыз сугышлар аркасында казна бик ярлыланган була һәм көч-хәл белән 20 капчык алтын-көмеш һәм башка кыйммәтле нәрсәләр җыялар, ә калган 10 капчык өчен шаһиншаһ үзенең улы Кавадны әманәт итеп калдыра. Улын азат итү өчен Пероз бөтен халыкка, хәтта аксөякләргә дә ясак сала.

Затлы металлар килүнең икенче юлы көньяк-көнбатышта. Билгеле булганча, яу чабып Византияне бик еш борчыган Азов буе болгар кабиләләре берләшмәсе VII гасырда таркала. Болгарларның бер өлеше Кавказга күчә (балкарлар), бер өлеше Дунай ягына китә, ә бер өлеше Идел һәм Кама буйларына юнәлә.

Ираклий гексограммалары — куш миллиарисияләр (көмеш тәңкәләр) Көнчыгыш Европада бары ике җирдә: Кавказда һәм Кама буенда гына табылган. Кама буенда Бартым һәм Шестаков хәзинәләре билгеле. Соңгысында, Византия тәңкәләре белән бергә, V—VI гасырларга караган сасанид драхмалары да бар.

Сасанид савыт-сабалары һәм затлы металлар ареалы да, Ираклий акчалары кебек үк, нигездә Кавказ һәм Кама буе төбәкләре. Бу фактлар бирегә болгар кабиләләре килгәч Кама буеның көньяк илләре белән сәүдә элемтәсе ныгуы турында сөйләмиме икән?

Ираклий тәңкәләре 615 елгы акча реформасыннан соң сугылганнар. Бу елларда Ираклий сасанидлар белән авыр сугышлар алып бара. 611 елда фарсылар Сириягә басып керәләр, ә 614 елда Иерусалимны һәм Мисырны яулап алалар.

Ләкин 617 елны Ираклий хазар каганы белән килешү төзи. Чыганакларда язылганча, шаһиншаһ Хөсрәү II, моннан коты очып, каганга аның илчесе аркылы түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Үзеңнең падишаһың, ә минем туганым катына бар да, сезнең йортны, сөекле туганымның йорты буларак, борынборын заманнардан бирле ата-бабаларым да, үзем дә ихтирам иткәнлекне, улларыбыз һәм кызларыбыз аша бик еш туганлашуыбызны әйт». Шулай да каган явы Кавказга басып керә һәм аның гаскәрендә, хазарлардан башка, болгарлар һәм суарлар да була. Хазарлар бик күп байлык — «алтын савытлар, затлы киемнәр», кәтү-кәтү мал-туар кулга төшерәләр, фарсыларны әсир итәләр. Шул вакытта Ираклий хазар гаскәренең башлыгы белән очраша. Император аңа үзенең таҗын

кидерә. Аннары кунак мәҗлесе җыела, шунда хазарларның гаскәр башлыгына император табынындагы барлык кыйммәтле савыт-саба бүләк ителә. Император үзенең кызы Евдокиянең рәсемен күрсәтә һәм, әгәр хазарлар киләчәктә дә фарсыларга каршы сугышырга ярдәм итсәләр, үзара союзны ныгыту йөзеннән, Евдокияне гаскәр башлыгына кияүгә бирергә вәгъдә итә.

Ираннан сасанид акчасы исә Идел буена һәм Урал төбәгенә системалы рәвештә үтеп керә. Аларга җентекләбрәк тукталу кирәк, чөнки нәкъ менә сасанидларның авырлык системасы белән танышу бу якларда үз акчалары — бронза коелмалар килеп чыгуга китергән.

Сасанидларга кадәрге фарсы тәңкәләренең алгы ягына хаким патша сурәте, ә арткы ягына аның атасының сурәте төшерелгән була. Алгы якта патша титулы һәм аның исеме («Фәлән-фәлән хаким, падишаһ — мәлик»), ә арткы якта аның атасының исеме («фәлән-фәлән хакимнең, патшаның атасы) күрсәтелә. Язма чыганакларга караганда, III гасырга кадәр Фар-



2 нче рәсем. Сасан династиясе акчалары (Шапур һәм Вараһран I).

сыда борынгы Базрангидлар династиясе патшалары хөкем сөрә. Ләкин III гасыр башында бер өлкәнең хакиме Сасанның улы Папак Фарсыда властьны үз кулына төшерә. Беркадәр вакыттан соң Папак тәхеткә Рим дәүләте белән уңышлы сугышкан талантлы гаскәр башлыгын — Шапурның өлкән улын утырта. Без-

нең көннәргә Шапурның биш көмеш драхмасы килеп җиткән. Папак тәңкәләре билгеле түгел. Шапур тәңкәләренең алгы ягында Фарсы патшасы таҗы — ярымайлы һәм йолдызлы кулах кигән Шапур, ә арткы ягында аның атасының сурәте төшерелгән. Бу акчалардагы язулар фарсы тәңкәләре өчен гадәти схема буенча төзелгәннәр һәм аларда Папак белән Шапурга «мәлик» титулы бирелгән. Папакның Шапур тәрбияләп үстергән икенче улы беренче тапкыр «шаһиншаһ» титулы ала.

Сасанид акчалары алтыннан (динар), көмештән (драхма) һәм бронзадан сугылган. Көмеш драхмалар аеруча киң таралган. Авырлыклары ягыннан алар ике категориягә бүленәләр: 3,55—3,88 граммлы (Папак — Шапур тәңкәләре һәм Арташирның иң башта чыгарган акчалары) һәм 4,10—4,30 граммлы (Арташирның соңрак сугылган тәңкәләре һәм аннан соңгы барлык сасанид патшаларның акчалары) төрләр.

Арташир тәхеттә вакытта авырлыгы Рим ауреусына тәңгәл алтын тәңкәләр сугыла башлый. Сасанидларның бронза акчалары даими авырлыкта булмаган. Иң әүвәлге бронза тетрадрахмалар 16 граммлы, аның 1/2 һәм 1/6 өлешләре дә бар. III гасырда 16 грамм авырлыктагы потин (кургаш кушылган бронза) тәңкәләр дә чыгарылган.

III—IV гасырларда драхма белән бергә аның 1/2 һәм 1/6 өлешле фракцияләре дә кулда йөргән. 1/6 ле фракция (0,78 граммлы) «даник» (бөртек) дип аталган. Драхма акча берәмлеге генә түгел, бәлки авырлык берәмлеге дә булып хезмәт иткән. Мәсәлән, кайбер савытлардагы язуларда аның драхма исәбендәге авырлыгы да күрсәтелә.

Әгәр сасанид тәңкәләренең алгы ягында шаһиншаһ сурәте уңга таба караган булса, ул аның мөстәкыйльлеген белдергән. Сулга борылган сурәт исә вассал патшаны күрсәткән. Кайчагында тәңкәләрдә шаһиншаһ белән шаһзадә яки шаһиншаһ, шаһзадә һәм шаһинә бергә сурәтләнгән. Түгәрәк легендада падишаһның исеме һәм титулы күрсәтелгән. Сасанид акчаларының (бигрәк тә әүвәл чыгарылганнарының) арткы ягында гадәттә «аташдан» — ут алтаре сурәте тора. Аташданның ике ягында шаһиншаһ һәм төрле аллалар (Ахур, Мазда, Митра, Анахита) сурәте булган.

III—IV гасырларда сугылган сасанид тәңкәләрендә Иран шаһиншаһы тамгасы — «фарр символы», тә-

хет варисы шаһзадә тамгасы «Үгезбозау символы» һәм Фарсы хакименең тамгасы булган ярымай һәм аның өстендәге йолдыз очрый.

Идел һәм Урал буйлары халкы, сасанид савыт-сабасы һәм акчалары йогынтысында, авырлык берәмлекләреннән файдаланырга өйрәнә, билгеле бер авырлык нормаларын кабул итә.

Югарыда әйтелгәнчә, тиздән биредә бронза коелмалар әйләнештә йөри башлый. Андый коелмаларны археологлар Алабугадан ерак түгел Турай авылы янындагы бай курганнарда таптылар. Аларны безнең эраның III—IV гасырларында гун кабиләләре калдырган. Бу юлларның авторы мондый коелмаларның шушында ясалган беренче акчалар булуы ихтимал дигән фикерне кузгатты.

Татарстанның Куйбышев районы Ширбәт авылы янында 73 данә бронза коелмадан (дүртесе яртышар кисәкле) торган тулы бер хәзинә табылды. Ул IV—VIII гасырларга карый. Алар табылган җиргә якын гына бакыр кою остаханәләре ачылды, бу исә ул коелмаларның шушында ясалган булуын күрсәтә. Хәзинәдәге кайбер коелмаларда аркылыга сузылган бау эзләре калган. Күрәсең, аларны бәйләм-бәйләм итеп бәйләгән булганнардыр. Бу акчаларның исәбен билгеләү кызыклы булыр иде. Кызганычка каршы, хәзинәне тапкан кешеләр бәйләмдәге коелмалар санын ачыклый алмаганнар. Без исә моны эшли алабыз.

Бронза коелма 18,5 см озынлыктагы һәм 70 тән алып 111 г га кадәр авырлыктагы өч кырлы озынча сомнан гыйбарәт. Күпчелек коелмаларның авырлыгы 102—106 грамм чикләрендә тирбәлә.

Коелмалар билгеле бер авырлыкта итеп коелган булса кирәк. III—VIII гасырларда Идел буе авырлык системасына нормасы 4,26 граммлы сасанид авырлык системасы йогынты ясаган булырга мөмкин. Бронза коелмалар 25 авырлык драхмасына исәпләнгәннәр (4,26·25=106 г) яки зуррак авырлык стандарты булган 426 граммның (кадакның, фунтның) чирек өлеше итеп коелганнар. Әгәр табылган бәйләмнәр бер кадак тәшкил иткән булса, һәр бәйләмдә дүрт данә коелма булган. Шунысы кызык, драхма системасы бик гомерле булып чыга, ул борынгы Болгарда да, Кыпчак илендә дә кулланыла. Ә «кадак» сүзе үзе шул алтын-көмеш савыт исеменнән (савыт фарсыча *кәдах)* килеп чыккан булса кирәк.

Металл акча урынына йөргән бронза коелмаларның драхма исәбендәге авырлыгы Идел һәм Урал буендагы күп кенә кабиләләрнең Хәрәзм, Иран һәм көньяктагы башка илләрнең сәүдә-алмашу сферасында булганлыгын күрсәтә. Ул заманның алга киткән илләренә биредән затлы җәнлек тиресе һәм аннан эшләнгән әйберләр чыгарылган.

Бронза коелмаларның таралыш территориясе шактый зур. Алар Идел һәм Урал буендагы урта гасыр шәһәрлекләренең культуралы катламнарында һәм бай каберлекләрдә очрый. Дөрес, археологлар аларның ни өчен хезмәт итүләрен аңлап җиткермәгән очраклар да булгалый. Миңа, мәсәлән, шундый бер коелманы Пермь шәһәренең өлкә музеенда родан культурасына (IX—XV) караган табылдыклар арасында күрергә туры килде.

Ижевск (Устинов) археологларының табылдыклары бронза коелмаларның ничек таралуын бигрәк тә ачык күрсәтә. Удмуртия фәнни-тикшеренү институтында зуррак күләмле ике коелма саклана (берсе балта белән урталай киселгән). Коелмалар шактый авыррак булсалар да, конфигурацияләре шундый ук. Алар өч кырлы, урталыкта юанрак. Бөтен коелманың озынлыгы 42 см, урталыктагы киңлеге 2 см, авырлыгы 400 г. Күрәсең, коелмалар 1 кадаклы итеп әзерләнгән булган. Ярты коелма 200 г авырлыкта. Шунысы игътибарга лаек, тышкы рәвешләре нәкъ бер төсле булган бу коелмалар төрле истәлекләрдә табылган. Беренче коелманы Идна-Кар шәһәрлегендә, икенчесен Гурья-Калада (Иванова М. Г. җитәкчелегендәге казу эшләре) тапканнар.

Удмуртия АССРның Кече Пурга районындагы Покров зиратында ир кеше күмелгән бай кабердә (Останина Т. И. җитәкчелегендәге казу эшләре) корбанлык әйберләре комплексы арасында гадәти формадагы бронза коелма табыла. Аның озынлыгы 16,1 см, юанлыгы 0,8 см, авырлыгы 71,5 г.

Шундый ук коелма (өчкә бүленгән һәм аерым кисәкләре бер-берсенә туры килеп тора) Удмуртия өлкә музеендагы бронза әйберләр җыелмасында бар. Ул музейга 1927 елда, А. П. Смирнов казыган Мыдланьшай каберлегеннән китерелгән.

Хронологик яктан караганда да коелмаларның кулда әйләнештә йөрү вакыты шулай ук шактый киң диапазонлы (коелма табылган Турай курганнары III—

V гасырныкы, Рождество каберлегендәге һәм Ширбәт хәзинәсендәге табылдыклар V—VII гасырларга карый). Бронза коелмалар III гасырда кулланышка кергәннәр дип фараз итәргә мөмкин. III гасыр — сасанидлар династиясе хакимлек итә башлаган чор, Идел буена сасанидлар металлы шушы вакытта үтеп керә һәм шуның йогынтысында бу якларда үз акча-авырлык системасы барлыкка килә. Ләкин фактта бронза коелмалар IV гасыр урталарыннан да иртәрәк әйләнешкә кермәгән дип уйларга кирәк. Нәкъ менә шул вакытта гун һәм угро-фин кабиләләре арасында эчке һәм тышкы алмашу көчәя, Көнчыгыш Европада халыкара мәйданга куәтле гун дәүләте чыгу моңа шактый көчле этәргеч була.

Урта Идел буенда бронза коелмаларның әйләнештә йөрүе, күрәсең, VII гасыр белән чикләнә торгандыр, чөнки бу вакытта инде, бик үк көчле булмаса да, акча әйләнеше урнаша башлый, бу исә хазарларда феодаль мөнәсәбәтләрнең үсеше һәм беренче шәһәрләр барлыкка килүгә бәйле. Кама буенча төньяграк территорияләрдә коелма әйләнеше озаграк сакланган. Мәсәлән, Идна-Кар шәһәрлегендә мондый коелма X—XI гасырлар катламында, ә Гурья-Кала шәһәрлегендә XI—XII гасырлар катламында табылган.

Шулай итеп, табылган хәзинәләр һәм аерым бронза коелмалар күрсәткәнчә, Идел һәм Урал буйларында, VII гасырдан да соңга калмыйча, затлы металлар күпләп керү нәтиҗәсендә, үз акча-үлчәү системасы барлыкка килә. Бу исә хазарларда феодаль мөнәсәбәтләр оешып, товар-акча бәйләнешләрен ныгыту һәм әйләнештә акчаның функциясен үстерү өчен кирәкле алшартлар тууга бәйле булган.

Өченче бүлек

ХАЗАР АКЧАЛАРЫ

Мин Итил дигән елга буенда яшим... Бу елга буенда күпсанлы халыклар: буртаслар, болгарлар, суарлар, цәрмисләр яши... Алар һәммәсе миңа хезмәт итәләр һәм миңа ясак түлиләр.

Йосыф, хазар патшасы

ХАЗАР КАГАНЛЫГЫ ОЕШЫР АЛДЫННАН ИДЕЛ ҺӘМ УРАЛ БУЕ

Хазарлар Византия чыганакларында VI гасырдан башлап телгә алыналар. VI гасырның икенче яртысында төрки каганы Истәми Көнчыгыш Европаның күп кенә кабиләләрен, шул исәптән болгарлар белән хазарларны да буйсындыра. Гәрчә хазар дәүләте VII гасырда Төрки каганлыгы таркалганнан соң барлыкка килсә дә, Идел һәм Урал буйларында халыкның күпләп күчүе һәм яңа кабиләара берләшмәләр оешу II—III гасырларга ук карый.

Антик чор авторлары яңа эраның II гасырында беренче тапкыр гуннарны телгә алалар. Клавдий Птолемей аларны Каспий буе түбәнлегендә сарматлар кабиләсе роксоланнар белән янәшә урнаштыра. Борынгы авторларның бу мәгълүматлары гуннар (хунну) турында кытай хроникаларында язылганнар белән аһәңдәш.

Соңрак хазарлар, болгарлар, суарлар, барсиллар һ. б. гуннар патшасы Атилла яуларына тартылалар. Византия чыганакларында атап кителгән Төньяк Кавказ һәм Кара диңгез буендагы күпсанлы кабиләләр арасында әлеге кабиләләр дә булган. Гун кабиләләреннән утургурлар, кутургурлар һәм сарыгурлар күп кенә бәхәсләр кузгатты. Бу сүзләрнең, кабилә исемнәре булмыйча, административ бүленешне белдерүләре бик ихтимал. Борынгы төрки телдә, «утру» — «каршыда, кара-каршы», ягъни «көнчыгыш» дигәнне, «көтүри» — «артта», «көнбатыш юнәлештә» дигән мәгънәне, ә «сары» — «үзәк» мәгънәсен белдерә. Ихтимал, көнбатыштагы күчмә кабилә халкын көтүригәр дип атаганнардыр. Византия чыганакларына караганда, кутургурлар чыннан да башка кабиләләрдән көнбатыштарак урнашкан булганнар.

Соңрак Идел буенда тарих сәхнәсенә имәнкискә-

леләр менә, алар үзләре белән Кама буе культурасыннан кискен аерыла торган культура алып киләләр. Имәнкискә культурасы Каманың уң як ярында Казаннан алып Уфага кадәр һәм көньякта Куйбышевка кадәр шактый зур территорияне алып тора. Имәнкискәлеләрнең VI—VIII гасырга караган авыллары, мәсәлән, Идел буенда Болгардан ерак түгел урнашкан Ширбәт инде борынгы феодаль шәһәрләрне хәтерләтәләр. Аларда культуралы катлам бик калын, ә Ширбәт хәрабәләрендә металл акча урынына йөргән бронза коелмалар ясый торган остаханәләр ачылды.

Болгарларга кадәр яшәгән, ләкин исемнәре сакланмаган имәнкискәлеләр турында карашлар бик төрле.

В. Ф. Генинг имәнкискә культурасы Себердән төрки элементлар килеп, җирле угро-финнар белән аралашкач барлыкка килгән, дип уйлый. П. Д. Степанов бу культура истәлекләрен Көньяк Уралдан көнбатышка күчкәндә биредә тукталып торган угро-мадьярлар (венгрлар) белән бәйли, ә Г. И. Матвеева хезмәтендә исә имәнкискәлеләр белән зарубинецларның культурасында һәм мәет күмү йолаларында параллельләр табыла һәм имәнкискә культурасының көнбатыштан чыгуы турында нәтиҗә ясала.

Исеме Киев тирәсендәге каберлектән алынган зарубинецлар культурасы яңа эрага кадәр II гасырда барлыкка килә. Археологларның бер өлеше аңарда праславяннар культурасын, икенче берәүләр исә балт культурасын күрәләр. Ләкин соңгы фикер хәзергә кадәр исбат ителмәгән, ә икенче яктан зарубинецлар культурасының алга таба үсеше славян культурасына килеп тоташмый.

Билгеле булганча, бу территориядә барлыкка килгән бер генә дәүләт тә,— Идел буендагы Болгар йортымы ул, әллә Казан ханлыгымы,— этник яктан һич тә бер төрле булмаган, бәлки, киресенчә, күп кабиләләрдән торган, күп милләтле характерда булган. Идел һәм Урал буйларындагы урманнар һәм елга бассейннары Кавказның күп телләргә ия булган кайбер төбәкләрен хәтерләтә. Биредә дә бүгенге көннәргә кадәр регион күп милләтле, монда дистәләрчә угро-фин һәм төрки халыклар, бер үк телнең бик үзенчәлекле диалектлары яши. Бу исә регионга төрле вакытларда төрле халыклар килеп утыруы турында сөйли.

Имәнкискәлеләр Кама буена сөрүле игенчелек һәм

металл эшкәртүдә югары техник күнекмәләр алып киләләр, болар исә зарубинец кабиләләренә түгел, бәлки алга киткән утрак тормышлы халыклардан, хосусан кытайлардан өйрәнгән гуннарга хас нәрсәләр. Имәнкискәлеләрдә металл акча әйләнеше гуннар йогынтысында барлыкка килүен басым ясап күрсәтергә кирәк. Мәсәлән, Кама буендагы гуннарныкы дип исәпләнгән Турай каберлегендә IV гасырның ахырына — V гасырның беренче яртысына караган 3 данә металл коелма, ягъни беренче металл акчалар табылды.

Имәнкискә культурасы VIII гасыр башларына кадәр яшәп килә. VIII гасыр — Хазар каганлыгы тарихында үзенчәлекле чор. Авыл хуҗалыгының һәм һөнәрчелекнең үсеше, күпсанлы шәһәрләр барлыкка килү дәүләтнең ныгуына һәм чәчәк атуына гына түгел, җәмгыятьнең сыйныфларга бүленүенә, иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләргә дә китергән. Борынгы мәҗүси иманулар ислам, яһүди һәм христиан диннәре белән бәрелешкән. VIII гасырда имәнкискәлеләрнең «юкка чыгуы» шул замандагы вакыйгаларга бәйле булырга тиеш һәм ул, әлбәттә, игътибардан читтә калмаган булыр.

VIII—IX гасырларда бу территориягә инде Кара диңгез буйларыннан һәм Кавказдан борынгы болгарлар килеп чыга. Халыкның бу рәвешле массакүләм күчүе хазар каганының рөхсәте белән генә эшләнергә мөмкин булган әлбәттә. Төньяк Кара диңгез, Төньяк Кавказ һәм Урта Идел буе кабиләләре арасында савирлар яки суарлар аеруча көчле булганнар. VII гасырда савирларның юлбашчысы Алып Илтәбәрнең, христиан диненә күчеп, мөстәкыйль политика алып барырга омтылуына хазар каганының бик кискен җавап бирүе мәгълүм. Шушы һәм кайбер башка фактларга таянып, без имәнкискәлеләр суарлар булырга мөмкин дип фараз итәбез һәм шуңа күрә бу мәсьәләгә киңрәк тукталырга кирәк дип саныйбыз.

Гуннар дәүләте оешкач һәм бигрәк тә ул таркалганнан соң, Төньяк Кара диңгез һәм Төньяк Кавказның күп кенә кабиләләре, шул җөмләдән савирлар да, гуннар дип йөртелә башлый. Ләкин бу чорга караган Византия чыганаклары аларны, башка кабиләләрдән аерып, «Европа гуннары» дип атыйлар.

Днепр буендагы зарубинецлар культурасы үзенә скиф культурасының бик күп үзенчәлекләрен ала. Мондый йогынты ике яклы булгандыр дип уйларга

кирәк. Тарихчы Стефан Византийский телгә алган савирларның Кара диңгез буенда яшәве, ә соңыннан бу кабиләләрнең Төньяк Кавказда һәм Кама буенда пәйда булуы безгә күп нәрсә сөйли. Геродот язган аргиппейлар телендә «асхи» (ачы) сүзе булган, бу сүз төрки телләрдә хәзер дә бар һәм бу факт тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Ләкин көнбатыш төрки телгә (Идел буендагы XIII—XIV гасырларга караган кабер ташларының икенче стиль теле шуңа керә) гомум төрки телдән беркадәр аерылу хас. Бу телнең үзенчәлеге — саңгырау һәм ярым-яңгырау авазлар булуда, ә яңгырау авазларның бөтенләй диярлек булмавында (бу күренеш угро-фин телләренең көчле йогынтысында килеп чыккан дип санала). Көнчыгыш орхо-енисей руник истәлекләрендә мондый үзенчәлекләр аз. Менә шуңа күрә дә, Стефан Византийский теркәп куйганча, «сапир»ларның «сабир»га әйләнүе бик закончалыклы.

Кайбер галимнәр имәнкискәлеләрнең тел үзенчәлекләре сакланмаган дип исәплиләр. Бу караш дөреслеккә туры килеп бетми. Мәсәлән, авазларның саңгыраулашуын исәпкә алсак, Геродот скиф сүзләре дип китергән аерым сүзләрдә һәм тезмәләрдә борынгы төрки сүзләрнең күплеге гаҗәпкә калдыра. Геродот, скиф аллаларын теге яки бу грек аллаларына тәңгәлләштереп, аларның исемен «эш-шөгыльләре» буенча «греклаштырып» бирә. Ут алиһәсе, йорт-җир учагының химаячесе Гистия — скифча Табити. Күрәсең, бу исем ике өлештән — тап (табыну) һәм ут сүзләреннән тора. Димәк, Табити (Табути) — изге ут. Грек мифологиясенең баш алласы Зевс — Папайга тәңгәлләштерелә. Ягъни Зевс Бабай аллага туры килә. Зевсның улы Аполлон — грек мифологиясендә кояш алласы, дәвалаучы, гаиптән хәбәр бирүче һәм сәнгать химаячесе Гойтосир сүзе аша бирелә. Бу да ике өлештән: «кайтсы» — «балкыш, ялтырау» һәм «ир» сүзләреннән тора. Ягъни Гойтосир (кайтысир) «күк балкышы ире» яки «гүзәл ир» мәгънәсендә. Афродита Урания (күк асты Афродитасы) алиһәсе скифча Аргимпаса сүзе белән бирелә. Без монысы да ике сүздән — «аркон» — «беренчел караңгылык», ягъни күк һәм «апа» (борынгы төркичә «апа» сүзе «ана» мәгънәсендә дә йөргән) сүзләреннән тора дип уйлыйбыз. Аргимпаса (арконапасы) «күк асты алиһәсе (анасы)» дигән мәгънәдә булып чыга.

Геродоттан тагы бер мисал китерик. «Скифларда амазонкалар,— дип яза Геродот үзенең мәшһүр «Тарихы»ында,— «ойорпата» дип атала, эллин теленә тәрҗемә иткәндә бу «ирләрен үтерүчеләр» дигән мәгънәдә, атап әйткәндә: «ойор» — ир, ә «пата» — үтерү дигән сүз». Геродотның ирсез хатыннар — амазонкалар җәмгыяте турында язганнары легенда өлкәсенә карый. Әмма Көнчыгыш Европада хатын-кызны үтерү йоласы (ритуалы) билгеле. Ире үлгәч, хатынын бау белән буып үтергәннәр һәм икесен бергә күмгәннәр. Ә Геродотта сүз, киресенчә, хатын-кызларның ирләрен үтерүе турында бара. «Ойор» сүзе аңлатуга мохтаҗ түгел, ул «ар» яки «ир» формасында еш очрый. Икенче сүзгә — «пата»га килгәндә исә, ихтимал, бу сүзнең тамырында ук ничек итеп үтерү мәгънәсе дә ята торгандыр: ба, бу — «бәйләү, буу». Шулай итеп, көнбатыш төрки теленә хас булганча, тартыкның саңгыраулашуын исәпкә алсак, «ойорпата» (әрпуты) сүзе «ирен буып үтергән» мәгънәсендә булырга мөмкин [1].

Югарыда китерелгән мисаллар имәнкискәлеләрнең зарубинец культурасы белән багланышлары очраклы гына түгеллеген күрсәтәләр.

Имәнкискәлеләрнең төпләнеп утырган җирләреннән, ягъни Идел буеннан VII гасыр азагында — VIII гасыр башында «юкка чыгуы» да очраклы була алмый. Бу хәл төбәктә зур политик үзгәрешләр нәтиҗәсе булырга мөмкин. Ихтимал, атаклы гарәп гаскәр башлыгы Мерванның 735 елгы яхшылап әзерләнгән икенче явы шундый вакыйга булгандыр. Бу сугышта үзләренең юлбашчылары белән савирлар хазар каганына мөһим ярдәм күрсәткәннәр.

Йөз ел диярлек дәвам иткән гарәп-хазар сугышы Мерванның җиңүе белән тәмамланган. Аннары Мерван, башка гарәп әмирләре кебек Төньяк Кавказдагы сугышлар белән генә канәгатьләнмичә, 150 меңлек гаскәре белән Идел буена басып керә. Моны көтмәгән каган, башкаласын калдырып, Иделнең сул як яры буйлап төньякка күтәрелергә һәм шунда дошманга каршы көч тупларга мәҗбүр була. Ләкин Мерван Итил шәһәрен яулап алуга вакыт әрәм итеп тормый, ашыгыч төстә төньякка — күрәсең, савирлар (имәнкискәлеләр) җиренә юнәлә.

---

[1] Соңгы елларда археологлар Дон буендагы курганнарда алтын муенса таккан, кораллы «амазонка»лар күмелгән каберләр таптылар. Шул ук курганнарда ирләрне дә җирләгәннәр.

Хазарлар һәм савирлар җиңелгәч, 737 елда хазар каганы ислам диненә күчә һәм бу хәл Идел буенда ислам диненең рәсми таралуына этәргеч була.

Яңа динне кабул итәргә теләмәгән савир христианнарына һәм аларның күпчелеген тәшкил иткән мәҗүсиләргә карата, күрәсең, нинди дер җәза санкцияләре кулланылгандыр. Һәм савирлар, болгарларның хазар каганлыгында калырга теләмәгән өлеше белән бергә, көнбатышка таба күченгәннәр булса кирәк.

VIII гасырда Урта Идел һәм Түбән Кама буена беренче болгар кабиләләре килеп урнаша. Ләкин алар буш җирләргә килмәгәннәр: биредә инде VIII гасырда ук ислам кабул иткән савирлар яши һәм X гасырдан аларның кабилә үзәге чыганакларда Сивар яки Суар дип аталган шәһәр дә була.

Мәгълүм булганча, хазар каганы исламны шундук кабул итми, ул башта яңа диннең төп кануннары белән танышырга тели. Бу вакытта ул үзе дә каршы таләпләр куйган дип уйларга була. Мәсәлән, гарәпләр, исламның җирле халык арасында тизрәк таралуын теләп, гыйбадәт кылу теле сыйфатында коръән телен түгел, бәлки төрки телне танырга мәҗбүр булганнар.

ТӨРКИ МИРАС

Суар, хазар һәм болгар биләмәләрен кушкач, төрки каганлыгының чикләре VI гасырда Төньяк Кавказга һәм Кара диңгез буйларына барып җитә. Көньяк-көнчыгышта Урта Кытай дәүләте генә дә каганга ел саен ясак итеп 100 мең кисәк ефәк тукыма китергән. Каганлык составына кергән Урта Азиядә дә ефәк корты үстерү һәм ефәк туку эше башланып киткән.

Төрки каганнарының Византия белән сәүдә элемтәләре урнаштырырга омтылуы мәгълүм. Мондый сәүдә византиялеләрне дә кызыксындырган, чөнки алар төркиләрдә фарсыларга каршы көчле булышчы күргәннәр. Көнчыгыштан көнбатышка «ефәк юлы» салынгач ефәк сәүдәсе каганга гаять зур табыш китергән.

Алдагы бүлекләрдә сасанид һәм Хәрәзм акчаларының гуннар чорында ук күренә башлавы әйтелгән иде. Ләкин Идел һәм Урал буйларына тәңкәләр VI—VII гасырларда, ягъни Төрки каганлыгы яшәгән вакытта аеруча күп килә. Соңга таба акча-товар багланышлары тагы да көчәя, ныгый.

Гуннар, ә соңрак төркиләр яшәгән көнчыгыш төбәкләрдә Кытайда сугылган акчалар да әйләнештә була. Идел һәм Урал буйларындагы акча әйләнешенә алар нинди дә булса йогынты ясый алмыйлар, чөнки бу төбәкләргә үтеп кермәгәннәр. Ләкин аларның кайберләрендә төрки телдәге икенчел язулар бар һәм алар төрки каганлыгының гына түгел, бәлки хазар һәм болгар чорларының да акча терминологиясен ачыкларга мөмкинлек бирәләр.

VIII гасырга карый дип фараз ителгән бер тан акчасындагы икенчел язманы төрле галимнәр төрлечә укый, чөнки төркичә язулар, гадәттә, тартыклардан тора һәм андый язуны интерпретацияләү бик кыен (б. ң. ү й. р. м к. ч. а). Мәсәлән, А. М. Щербак аның «Мең акча берәмлеге» һәм «Бер акча берәмлеге» дигән вариантларын бирә. И. Л. Кызласов, оригиналның үзен тикшереп, язманы: «Пин чи. Суккан (койган?) акча» дип укый. И. Г. Добродомов, төрки руник язмалар бу тәңкәләрнең акча функциясен югалтулары һәм амулетка (бөти) әйләнүләре турында сөйли дип исәпли. Ул да ике вариант бирә: «Күз тиюдән мең тапкыр саклый торган чара» һәм «Мең чигил. Бөти». Ләкин И. Г. Добродомовның бу вариантлары фәнни булудан ерак, чөнки ул оригиналның үзе белән таныш булмаган, А. М. Щербак һәм Д. Д. Васильев күчереп төшергән тамгаларның кайберләрен үзгәртеп, үзенчә аңлатырга гына тырышкан.

Без, Кытай акчаларының урталыгында, җепкә тезеп йөртү өчен, дүрткел тишеге булуын истә тотып, исәп эшен җиңeләйтү һәм ялгышу ихтималын калдырмау максатында, тәңкәләрнең берәрсендә, әйтик төен янындагысында, санын, исемен яки аның хуҗасын күрсәткән язу булырга мөмкин дип фараз иттек һәм башка төрле укылыш тәкъдим итәбез: «Биңәү. Йөрем акча».

Язуның без тәкъдим иткән укылышындагы хәрефләр күпчелек күчермәләр белән тәңгәл, ягъни без бер хәрефне дә үзгәртмәдек. Фәкать өченче хәрефнең генә кайбер авторларда аермасы бар. Бу исә әлеге хәрефнең үзенчәлегенә бәйле. Икенче һәм өченче хәрефләрнең «япьләре» кушылып китмәсен өчен, язучы өченче хәрефнең «ябен» беркадәр аска авыштырган булса кирәк. Бөтен бер сүзнең төрлечә укылуы шуннан килә.

Минусинск музеендагы 759 елныкы дип билгеләнгән

гән икенче тәңкәдәге язуны беренче булып А. С. Аманжолов укыды. Аның варианты түбәндәгечә: «Бакыр биңи әб кичиг урыка», ягъни «Мең бакыр — кече угыл өчен йорт». А. С. Аманжолов күчермәсен дөрес дип тапкан хәлдә, без өченче сүзне, тыныш билгеләре була торып, ике мөстәкыйль сүзгә бүлүнең кирәге юк, дип уйлыйбыз һәм язуны түбәндәгечә укыйбыз: «Бакыр. Беңи бекичег урыка». Хәзерге телгә тәрҗемәсе: «Бакыр. Меңе Бекич улына».

«Акча» терминының килеп чыгышына карата ике төрле фикер бар. Кайбер авторларга ияреп, Э. В. Севортян үзенең «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге»ндә акча: «...башта ук көмеш (аксыл) тәңкәне белдергән»,— дип яза. Ләкин төрки телләрнең күпчелегендә тәңкә нинди генә металлдан булмасын, барыбер акча ул. Фәкать үзбәк телендә генә акча сүзенең көмеш тәңкә дигән мәгънәсе билгеле.

Г. Рамстедт бик нигезле рәвештә, «акча» сүзе «агы» (хәзинә, байлык) сүзенә кечерәйтү кушымчасы «-ча» ялганып ясалган дип саный. Ләкин Г. Дерфер борынгы төрки телдә «агы» терминының «ефәк парча» мәгънәсендә очравына нигезләнеп, Г. Рамстедт этимологиясен кире кага. Э. В. Севортян нәкъ менә шуның аркасында Г. Рамстедт версиясеннән баш тарта, күрәсең. Тик Э. В. Севортян акчаның болгар тәңкәләрендә теркәлгән икенче төрки исеме — «мал»ның туры мәгънәсендә «терлек»не белдерүен истән чыгара. Шуңа күрә, борынгы төрки чорда «агы» сүзенең ефәк тукыманы (байлыкны) да белдерүе «акча» терминының агы (ак) сүзеннән килеп чыгуын кире какмый, бәлки аның файдасына сөйли.

Төрки каганнарның станы урнашкан Актау исемендә яки XIII гасыр урда ханнарының станын төркиләр Ак урду дип атаганда да «ак» термины төсне түгел, бәлки «югары», «бөек», «кыйммәтле» мәгънәсен бирә. Гарәпләрнең үз заманында «Ак урду»ны «урду әл-Могаззам», ягъни «бөек урда» дип тәрҗемә итүе очраклы хәл түгел.

ХАЗАР ТӘҢКӘЛӘРЕ

Идел һәм Урал буйларында Хәрәзм һәм сасанид акчаларына алмашка Византия һәм гарәп тәңкәләре килә. Бартым һәм Щербаково хәзинәләрендә табылган Византия гексаграммалары турында без алдагы

бүлектә сөйләгән идек инде. Ираклий гексаграммаларының, Төньяк Кавказдан тыш, Идел һәм Урал буйларында да очравы хазарлар эшчәнлеге белән бәйле булырга тиеш. Акча әйләнешенең төп үзәкләре шәһәрләр булганлыктан, аларга җентекләбрәк тукталыйк.

Хазарларның иң элгәрге башкалаларыннан берсе Бәләнджәр Төньяк Кавказда урнашкан булган (Тер-Сулак елгалары арасында Югары Чирюрт шәһәрлеге). Шәһәр шактый зур (16 мең квадрат метр) һәм калынлыгы 10 ар метрга җиткән, башнялы стеналар белән әйләндереп алынган булган. Хазарларның икенче зур политик үзәге, археолог М. Г. Могомедов билгеләгәнчә, борынгы Бәләнджәрдән көньяктарак урнашкан Сәмәндәр шәһәре була.

Бирегә акчалар хазар, болгар яки суарларның сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә түгел, бәлки Византия империясе белән тыгыз сәүдә һәм дуслык элемтәләре аркасында күпләп үтеп кергәннәр, чөнки, инде әйтеп киткәнебезчә, хазарлар Византиягә фарсыларга һәм гарәпләргә каршы көрәшергә ярдәм иткәннәр.

Шәһәрләр төзелү һәм товар-акча мөнәсәбәтләренең үсүе алмашу чарасы буларак акчага даими ихтыяҗ китереп чыгара һәм аны канәгатьләндерү өчен хазарларның үзләрендә акча сугу эше җайга салына. Шунысы әһәмиятле, хазар акчалары башта ук Византия тәңкәләренә ияреп, шуларга охшатып сугыла. М. Г. Могомедов Бәләнджәр каберлекләрендә Маврикий Тиберий (582—602 еллар), Ираклий һәм аның улы Ираклий Константин (610—641 еллар) чорында сугылган алтын тәңкәләрне генә түгел, бәлки шушы җирләрдә Ираклий һәм Ираклий Константин солидларына (алтын) охшатып сугылган алтын хазар тәңкәләрен дә тапты.

Урта гасырлардагы теләсә кайсы дәүләт кебек үк, хазар каганының килерендә каганлык халкыннан һәм буйсынган кабиләләрдән җыелган ясак шактый зур урын тоткан. Төньяк Кавказ кабиләләре, Кырым, Көнчыгыш Европа халыклары, шул исәптән Дунайдан күчеп килгән кайбер көнчыгыш славян кабиләләре дә ясакны «төтен» исәбеннән түләгәннәр. Борынгы рус елъязмаларында мондый ясакның күләме турында түбәндәгеләр әйтелгән: «А козари имаху на полянех, и на северех, и на вятичех, имаху по беле и веверице от дыма». Бу очракта бер көмеш тәңкә һәм бер тиен тиресе күләмендәге ясакны тудун дигән махсус чи-

новниклар җыеп йөргән. Бу термин «тиун» рәвешендә борынгы рус теленә кереп калган һәм рус фамилияләрендә бүген дә очрый (Тиунов).

Бәләнджәр һәм Сәмәндәр шәһәрләренең исемнәрен фарсы сүзләренә кайтарып калдыру белән килешеп булмый, чөнки бу исемнәр, кушымчалары буенча фикер йөрткәндә, соңгырак чорга караган Болгар, Суар, Биләр шәһәрләренең исеменнән аерылмый. Кушымчаның алгы авазында «й-лашкан сузык авазның «дж» һәм «д»га күчүе игътибарны җәлеп итә. Гомумтөрки «йер» — җир, шәһәр урынына биредә «джәр» һәм «дәр», ягъни консервативрак форма. Татар теленең көнбатыш диалектларында XVIII гасырларда да әле шушындый ук күренеш күзәтелгән (мәсәлән, «дюл» — юл, «дир» — җир һ. б.).

Әлеге Бәләнджәр һәм Сәмәндәр шәһәр исемнәренең төп өлешенә килгәндә исә, алар катлаулы борынгы төрки сүз тезмәләре булса кирәк. Алардагы ән — шәһәр, ил мәгънәсендә. Гарәпләрнең Бәләнджәрне «ил» дип атауларын да әйтеп китик. Шушы «ил»гә соңыннан хазар телендәге «джер» — биләмә (җир, шәһәр) сүзе килеп кушыла.

Бәләнджәр исеменең башлангыч формасын «болхар» сүзеннән эзләүче В. Г. Котович хаклы шикелле. Ул бу сүзләрнең төрлечә яңгыравын күчереп язучыларның ялгышы белән аңлата. Ләкин кайбер гун кабиләләренең — утургур, көтүргүр һәм сарыгурларның исемнәре төрки «кол», «гол» яки «әл» — кул урынына гун-угро-фин сүзе «кор», «гор» кушылып ясалган. Әйткәнебезчә, борынгы төркидә «утру» — каршыда, ягъни көнчыгыш, «көтүри» — артта, ягъни көнбатыш, ә «сары» — «як», ягъни «үзәк» мәгънәсендә. А. Б. Булатов та «болгар» сүзен бол һәм кар, гар — «кул», «канат» өлешләренә тарката. Сүзнең беренче өлеше кайбер тәңкәләрдә «боэл» формасында очрый (боэлгар).

Әгәр безнең фикер сөрешебез дөрес булса, «болгар» исеменә гар — «кул» соңрак килеп кушылган һәм гун-угрофин сүзе «гар» белән гун-төрки «әл» сүзе бер үк мәгънәдә булып чыга. Ә «бәләнджәр» сүзе «болгар» атамасының борынгырак формасыннан ясалганга охшый (бол-ән-джир).

Хазарларның икенче мөһим шәһәренең исеме Төньяк Кавказдагы икенче зур һәм көчле кабилә — суарлар (сабирлар, савирлар) белән бәйле булырга мөм-

кин. Сәмәндәр сүзен саб-эн-дәр рәвешендә реконструкцияләп була (ягъни сув, саб, сав кабиләсенең станы — шәһәре, иле). Монда «м» авазы «в» («б») белән чиратлаша (куман — кубан сүзләрендәге кебек).

VIII гасырдан башлап гарәп (куфи) дирһәмнәре киңрәк тарала. Хазарлар тарихының бу чоры үзәкнең Төньяк Кавказдан Идел буена күчүе белән бәйләнгән.

Тарихчыларга Түбән Идел буенда, хазарларның башкаласы Итил һәм ихтимал, башка шәһәрләре дә булган төбәктә, алардан калган борынгы истәлекләр ифрат аз билгеле. Моның төп сәбәбен Түбән Идел буендагы күп санлы шәһәрлекләрнең фактта җитәрлек өйрәнелмәгән булуы белән аңлатырга кирәк.

Хазар каганлыгының зур шәһәрләреннән булган Варачанның урыны төгәл билгеле түгел. М. Г. Магомедов аны Дербент тирәсенә урнаштыра. Ләкин гарәп авторлары, мәсәлән Ибн Хордадбех яки «Ходуд әл-Галәм»нең авторы, 10 хазар шәһәренең нәкъ бер төсле исемлеген (Итил, Сәмәндәр, Бәләнджәр, Хамлиҗ, Бәйда, Саугар, Хтлг, Лнк, Сур һәм Масмада) бирсәләр дә, Варачанны телгә алмыйлар. Ихтимал, ул гарәп дөньясыннан ераграк, төньяктарак урнашкан булгандыр. Болгарлар яки суарлар кебек ел фасылына карап күчеп йөргәнлектән, хазарларның да башкаласы икәү булган. Варачан каганның җәйге резиденциясе булганлыктан, аны нәкъ менә урта киңлекләрдә, Дон һәм Идел буйларыннан эзләргә кирәк. Мәсәлән, Йосыф каганның хатына караганда, ул Итил шәһәрендә кышлаган, ә яз көне В-р-шан елгасыннан башлап күченә торган булган. Ихтимал, борынгы Варачан шул елга буенда урнашкан булгандыр.

Безнең фаразыбызча, Варачан Волгоград өлкәсе Дубовка шәһәре янындагы Водянск шәһәрлеге белән тәңгәл. Урта гасыр гарәп язучылары, мәсәлән Әбүлфида бу шәһәрне Бәлҗәмән дип, Аксак Тимер тарихчылары Бәлчимкин дип, ә Венеция авторлары Берчиман дип йөрткәннәр. Венецияле Франциск һәм Доминика Пициганиларның 1367 елгы картасында «Барчиман базар» рәвешендә язылган шәһәр Дон буенда, ә 1375 елгы Каталония атласында — Иделнең уң як ярында Водянск шәһәрлеге тирәсендә урнаштырылган.

Ихтимал, һәр ике елганың да ярында Берчиман һәм Берчиман базар дигән калалар булгандыр, чөнки

бу урын — Иделнең Дон белән иң якынайган җире һәм монда олы сәүдә юллары үткән.

Шәһәрнең Берчиман формасындагы исеме соңыннан «ән» — шәһәр сүзе ялгау аркасында килеп чыккан, күрәсең (Барчин шәһәре). Әле генә әйтеп кителгәнчә, Аксак Тимер тарихчылары шәһәр исемен Бәлчимкин формасында кулланалар, ягъни «ән» сүзе Урта Азиянең «кин» (кент) — шәһәр сүзе белән алмаштырылган. Хәер, шәһәрнең җирле исеме Водянск шәһәрлегендә табылган бакыр акчаларда б. р. ч. н. (Барчин) формасында очрый. Бу исемне бар — бару, йөрү һәм чән, сән — шәһәр (кытай, гун) сүзләреннән тора дип карасак, «бару урыны» (шәһәре) килеп чыга. Мәгълүм булганча, борынгылар шушы урында көймәләрен Иделдән Танаиска сөйрәп күчергәннәр.

Монда, ихтимал, иң кызыклысы шулдыр: Водянск шәһәрлегендә археологик казу эшләре Идел буенда беренче тапкыр шактый көчле хазар йогынтысы булганлыгын күрсәтте. Мәсәлән, шәһәрлектә саман кирпечтән салынган куш йорт казып чыгарылды, ул хазар культурасының Югары Дон һәм Азов буйларында таралган икенче һәм өченче варианттагы ике өйле йортларын хәтерләтә. Йортлар таш нигездә (цокольдә) утыралар, ә кирпечләр еш кына матурлык өчен «чыршылап» тезелгән. Үлчәмнәрдәге кайбер тайпылышларны һәм вак-төяк детальләрне исәпкә алмаганда, төзүчеләр тулы симметрия саклаганнар, фоторәсемдә бу ачык күренә (3 нче рәсем).

Торак комплексының ир-ат һәм хатын-кызлар өчен икегә бүленгән булуы турындагы фикер безнең каршыда функцияләре ягыннан нәкъ бер төсле куш йорт булу белән сыешмый кебек: һәр якта чиста, торак бүлмә һәм ипи пешерү, аш-су бүлмәсе бар. Хатын-кызлар ягындагы аш-су әзерләү бүлмәсе һәм көлчә пешерелә торган тандыр ир-атлар ягында кабатланыр идеме икән? Водянск шәһәрлегендә торак каралтыларны куш итеп салу, йортларны симметрияле итеп урнаштыру тенденциясенең хазарлардан килгән тирән тарихи тамырлары бар.

Водянск шәһәрлегендә бер мәчет тә ачылды. Аның 120 сантиметр калынлыктагы стеналары кызыл балчык белән буталган вак ташлардан эшләнгән. Мәчет үзе шактый биек һәм колонналары да булган. XIV гасыр азакларында ук аны мәет куя торган зиратка әйләндергәннәр. Мәчет белән янәшә дә, аның эчендә



3 нче рәсем. Барчин шәһәрендә казып чыгарылган бер үк конструкцияле ике өйле йорт.

дә урнашкан каберләр игътибарны аеруча җәлеп итә. Дон буендагы хазар каберләре (икенче вариант) кебек үк, болар да еш кына эчтән (җир астында) такта белән әйләндереп алынганнар, ә өстән такта белән ябылганнар. Ләкин күбесенчә каберләргә эчтән яндырылган кирпеч тезелгән.

Күмү йоласының элементлары да зур әһәмияткә ия: хазарлар кебек үк, Барчин халкы да мәетне башы белән көнбатышка каратып куйган. Аларның йөзләре генә Мәккәгә таба борып куелган. Бу инде ислам йогынтысы турында сөйли. Ә мәчетнең михрабы көньяккөньяк-көнчыгышка, ягъни Мәккәгә таба караган.

Стеналарны таштан һәм кирпечтән салу ысулында хазар архитектурасына хас үзенчәлекләр Водянск шәһәрлегенең башка корылмаларында да табылды. Әлеге мәчеттә михрабка каршы утыртылган, борынгы Византия чорына хас мәрмәр колонна кайдадыр якында гына хазар корылмалары булганлыгын күрсәтә. М. И. Артамонов Саркел дип фараз иткән хазар каласында да шундый ук колонна табылган.

Идел буена көмеш кенә түгел, алтын гарәп акчалары да үтеп кергән. Дөрес, Көнчыгыш Европа территориясендә алтын куфи тәңкәләре гадәттән тыш сирәк очрый.

В. П. Шилов Әстерхан өлкәсе Черногорский районы Соленое Займище авылы янында хазар кешесе кабердә, А. А. Быков билгеләгәнчә, 760—761 елларда сугылган алтын акча таба. Аның арткы ягында үзәк легенданың өстендә граффито төсмерләнә. А. А. Быков аны күмелгән кешенең шәхси тамгасы дип исәпли. Ләкин без, ике мөстәкыйль тамгадан торган бу язуны, борынгы төрки алфавит нигезендә, лт. ң. — «алтың» дип укырга мөмкин дип саныйбыз.

Кабердә, алтын динардан тыш, ат башы сөяге, ат аягының тубык сөякләре, мәетнең баш артында эченә пычак салынган чүлмәк була.

Янәшәдә генә сарыкның түш сөякләре, җәя һәм сөяк кистән ята. «Тере мәет» идеясе тормыш «теге дөньяда» да дәвам итә дип ышануга бәйләнгән. Мәетнең кулына тоттырылган акчадагы әлеге язу «синең алың» мәгънәсен бирә. Ә борынгы төрки телдә «ал» сүзе берничә мәгънәгә ия: «түбәнге» (мәсәлән, «алтын — таму йери», ягъни «түбәндә — тәмуг иле») яки «алгы», ягъни кемнең яки нәрсәнең дә булса алгы ягында торган нәрсә. Әлеге язуда «ал» — акчаның

үземе, әллә мәетнең бөтен «экипировкасымы» икәнлеге хәзергә аңлашылып бетми.

Шулай итеп, әгәр Бәләнджәр курганнарында Византия тәңкәләре һәм аларга ияреп сугылган акчалар ешрак очраган булса, Идел буендагы әлеге кабер очрагыннан күренгәнчә, соңыннан Византия акчаларын гарәп акчалары кысрыклап чыгара.

Хазариянең үзендә акча сугу эше катлаулы политик шартларда бара. 737 елда каган ислам динен кабул иткәч, Византия акчаларына ияреп түгел, бәлки куфи дирһәмнәрен сугуны үзләштерү максатка ярашлырак була. Өстәвенә, бу дирһәмнәр Көнчыгыш Европа сәүдәсендә абруй казана, зур территорияләрне яулап ала.

Шул рәвешле ориентация үзгәргәч, моның нәтиҗәләре дә көттерми. Мәсәлән, каган станы һәм каганлыкның административ үзәге Түбән Идел буена күчерелә. Биредәге шәһәрләрдә һөнәрче һәм сәүдәгәр мөселманнар күп яши, биредә Кытайдан, Урта Азиядән, Кече Азиядән, славян җиреннән һәм Көнбатыш илләреннән килеп йөрүче сәүдәгәрләрнең юллары очраша.

А. А. Быков 323 данә бөтен һәм киселгән акчалардан торган Девицкий хәзинәсендәге 86 тәңкәгә палеографик анализ үткәрә. Ул акчаларның алгы һәм арткы якларында сугылу урыны һәм вакыты арасында капма-каршылыклар, шулай ук язуларда күп кенә ялгышлар таба. Мәсәлән, I а тибындагы тәңкәдә сугылу елы һиҗри 103 ел (721/722), ә сугу урыны Мәдинәт әс-сәләм, ягъни Багдад дип күрсәтелгән. Ләкин шәһәр буларак Багдадка соңрак, һиҗри 145 елда (762/763) гына нигез салына, ә һиҗри 103 елда омейад хәлифе Йәзид II хакимлек итә (720—724). Табигый, бу акча хәлиф әл-Мәэмун хакимлек иткән (810—833) еллардан да алда сугыла алмаган.

А. А. Быков хәзинәдәге үзе тикшергән акчаларның язуында хәрефләрнең еш кына тоташмаган булуына игътибар итә. Акча сугу осталары хазарларның язуын — үзара тоташмый торган төрки хәрефләрен яхшы белгәннәр дип әйтергә мөмкин.

Язуда еш кына «Мәһди» исемендә «Һ» төшеп калган, ул исә төрки алфавитта бөтенләй юк. Сугу урынының «Мөхәммәдия» дип түгел, «Хәммәдия» дип күрсәтелүе дә төрки әйтелеш өчен гадәти хәл. Болар

барысы да Девицкий хәзинәсендәге акчаларның Хазариядә сугылганлыгын раслыйлар.

Шулай да авторның кайбер фикерләре белән килешәсе килми. А. А. Быков фикеренчә, хазар акча сугу осталары тәңкәләрдәге гарәп язуларын укый белгәннәр, ләкин үз акчалары өчен штемпельләр ясаганда легендаларны, теге яки бу тарихи шартларны исәпкә алмыйча, хәтер буенча гына төзегәннәр. Әмма Девицкий хәзинәсе буенча автор төзегән таблицага карап та без хазар осталарының бик кызыклы тарихи шартларны исәпкә алуларын күрәбез. 12 тип акчаларның 9 ы (II, III, V—X, XII), ягъни VIII гасырга караган тәңкәләр, тәхеттә утырган хәлифнең исемен күрсәтмичә чыгарылганнар. Дөрес, омейад һәм беренче аббасид акчаларында да хәлиф исеме күрсәтелмәгән. Ләкин Мәһди хакимлек итә башлаган (775—785) вакыттан алып акчаларда хәлиф исеме күрсәтелеп килә. Девицкий хәзинәсендәге акчалар VIII гасыр азагында яки IX гасыр башында чыгарылганнар. Ә аларда фәкать тәхет варисының исеме генә күрсәтелгән. Ә даталары IX гасырның беренче чиреге дип билгеләнгән тәңкәләрдә (68 данә, IV, XI типлар), ягъни акчаларның күпчелегендә хәтта хәлифлекнең өченче дәрәҗәле кешесенең кушаматы («ике хакимлек хуҗасы») сугылган. Бу кушамат вәзир Фадл ибн- Сәхилнеке дип уйлыйлар. IX гасырның, ихтимал, 30 нчы елларына караган 2 данә акчада гына хәлиф әл-Мәэмун исеме очрый.

Очраклы хәлме бу? Юктыр. Хазариядә гарәп акчаларына ияреп акча сугу аббасидлар хакимлек итә башлау чорына туры килә. Беренче аббасид Абул Аббас Саффак («Кан эчүче») 750—754 елларда хакимлек итә. Куфидә ныгып алгач, ул хәлифәлекне тәртипкә китерү, исән калган омейадларны юк итү белән шөгыльләнә. Абул Аббас үлгәч, аның туганы Мансур (754—775) хәлиф була. Мансур — зур политик эшлекле, ул бөтен ислам дәүләт политикасын үзгәртеп кора. Аның чорында сасанид авылы Багдад җирендә яңа башкала төзелә башлый. Хәлифне чолгап алган фарсы аксөякләре күптәннән үк хазарларга дошман караштa торганнар.

Мансур хакимлек итә башлагач, ислам тәгълиматында да кайбер үзгәрешләр була. Мансурны омейадлар хакимлек иткән Испания генә түгел, Төньяк Африканың да танымавы очраклы хәл түгелдер. Мисыр

4 нче рәсем. Куфи дирһәме (зурайтылган).

исә аны номиналь төстә генә таный. Күрәсең, аббасидларны хазарлар да танымагандыр. Мансур фарсы яраннары белән бергәләп Кавказга яу чаба, Баку тирәсенә килеп җитә һәм анда нефть чыганакларына ясак сала. Болар барысы да хазар каганы белән Мансур хәлиф арасындагы мөнәсәбәтләрнең өзелүенә китерә, дип уйларга кирәк.

Әгәр безнең фикер сөрешебез дөрес булып чыкса, Девицкий хәзинәсе акчалары хазар каганы белән аббасидлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең бозыла башлавын чагылдыралар. Ахыр чиктә, IX гасыр башларында, хазар каганы яһүд диненә күчә.

Девицкий хәзинәсендәге акчалар сыйфатлары һәм пробалары (960) буенча әйләнештәге дирһәмнәргә иярәп сугылудан бигрәк, яшерен сугуга охшый. Шуңа күрә алар нумизматлар күзеннән озак вакытлар буенча читтә калганнар да. Чагыштырмача соңгырак

1 нче таблица

Хазар таңкалары (Девицкий хәзинәсе)

Акчаның тибы	Акчадагы даталар	Арткы якта датаны ачыклаучы билге	Һиҗри ел	Яңа эра еллары	Таңкаларның саны	Хазар тамгасы
I а	103 (721/722)	әл-Мамун	196—215	811/12—830/31	1	—
I б	104 (722/723)	әл-Мамун	196—215	811/12—830/31	1	—
II	108 (726/727)	әл-Маһди варис булырак	145—158	762/63—775	10	—
III	119 (737)	Түгәрәк эчендә иман символы	136—158	754—775	1	—
IV	119 (737)	Зур-р-риясатайн (Фадл ибн Сәхл)	196—205	811/812—820/21	30	—
V	125 (742/743)	Ике түгәрәк эчендә иман символы	136—158	754—775	1	—
VI	142 (759/760)	Шул ук	136—158	754—775	1	—
VII	144 (761/762)	Түгәрәк эчендә иман символы	136—158	754—775	1	—
VIII	150 (767/768)	Ике түгәрәк эчендә иман символы	136—158	754—775	1	бар
IX	150 (767/768)	Шул ук	136—158	754—775	1	бар
X	150 (767/768)	әл-Маһди варис булырак	145—158	762—763/775	1	бар
XI	150 (767/768)	Зур-р-риясатайн (Фадл ибн Сәхл)	196—205	811/812-820/821	28	бар
XII	162 (772/779)	Ике түгәрәк эчендә иман символы	136—158	754—775	1	бар

акчаларда гына хазар каганының өч чатлы ботакка охшаш тамгасы шактый ачык күренә (VI таблица).

Соңга таба тәңкәләрдә инде хазар акча сугу сарае күрсәтелә башлый. Ләкин Девицкий хәзинәсендә андый акча юк әле. Бу исә охшатып сугылган акчалар чоры белән үз акчаларын сугу чоры арасында күпмедер хронологик өзеклек булган дип уйларга юл калдыра.

Соңыннан хазарларныкы булуы тәгаенләнгән тәңкәләр тасвирламасын Х. М. Френ һәм В. Г. Тизенгаузен бирә. В. Г. Тизенгаузен аларның сугылу урынын билгесез исемнәр санына кертә. 1923 елда Р. Р. Фасмер бу сүзне Арз әл-Хазар («Хазар җире») дип укырга тәкъдим итә. Шулай да, язылышына караганда, бу сүзне каты «с» белән: Арз әл-Хасар дип уку нигезлерәк.

А. А. Быков Арз әл-Хазарда сугылган акчаларның язуы, 220 (832) елгы һәм аннан соңгы елларга караган хәлифә акчалары белән чагыштырганда, борынгырак төстә булуына игътибар юнәлтә. Ул арткы якта үзәк легендадагы аерым хәрефләрнең дугасыман тоташуында кульязмалар йогынтысын күрә, ә VIII гасыр ахырында — IX гасыр башында куфи акчалары өчен бу һич тә характерлы түгел.

Хазар акчаларындагы мондый үзенчәлекле язу нәрсәдән килә соң? Тәңкәләрнең оформлениесендә хазарлар омейадлар традициясен дәвам иттергәннәр дип уйларга кирәк. Алгы якта, аббасид акчаларыннан аермалы буларак, бер генә түгәрәк легенда булу да шул хакта сөйли.

Идел буенда ортодоксаль ислам рәсми төстә кабул ителгән вакытларда хазарларның дини кульязмалардагыга охшаган архаик язулы акча чыгарырга омтылуын Хазар каганлыгы белән Гарәп хәлифәлеге арасында каршылыкларның тагы да тирәнәюе белән генә аңлатырга мөмкин шикелле.

Арз әл-Хазар акчаларының кайберләре 223 (837/838) елда сугылган. Ихтимал, IX гасырның икенче яртысына караган хазар акчалары да булгандыр, ләкин давыллы политик һәм идеологик бәрелешләр вакытында Хазариядә акча сугу эше инде тукталуга, бетүгә йөз тоткан. Борынгы феодаль дәүләтләргә хас закончалык нигезендә, Хазар дәүләте үзе дә таркалу чорын кичерә. Куфи акчаларын сугу эше Идел буенең башка шәһәренә — Болгарга күчә. Анда сугылган иң элгәрге акчалар X гасырның башына (902—908 еллар) карыйлар.

Дүртенче бүлек

ИДЕЛ БУЕНДА X—XII ГАСЫРЛАРДА ТОВАР-АКЧА МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Чыннан да, әгәр мин үземнең казнам исәбенә кала салырга уйласам, әлбәттә, минем өчен һичбер кыенлык булмас иде.

Әлмеш, Болгар әмире

ХАЗАРЛАР МИРАСЫ

X гасыр башында Идел буе болгарлары акча сугу эшен үзләштергәннәр. Соңгы хазар акчалары белән беренче болгар акчалары арасында 60 еллап өзеклек бар. Шуңа күрә акча сугу эшендә хазар традициясе турындагы мәсьәлә бик табигый.

Гади генә тоелган бу мәсьәләне хәл итү өчен, Хазар дәүләтенең һәм аның территориясендә барлыкка килгән яңа дәүләтләрнең тарихы белән бәйле күп кенә башка мәсьәләләрне күздән кичерергә туры килә. Алар арасында экономик мөнәсәбәтләр дә, хазарлар белән болгарларның этник, тел һәм культура уртаклыгы да, болгарларда акча әйләнеше һәм акча-авырлык терминнары куллану һ. б. мәсьәләләр бар.

Тарихи әдәбиятта хазар-болгар этник гомумилеге турында бердәм генә фикер юк. Ә инде тулаем тикшереп карый башласаң, шактый гына тарихчыларның Көнчыгыш Европа далаларында һәрчак үзара дошманлашып яшәгән һәм берсен-берсе алмаштырып торган күчмә халык дулкыннарын күрүләре күзгә ташлана.

Соңгы елларда тел белгечләре гун-хазар-болгар чорына (IV—XIV гасырлар) караган шактый төзек төрки тел материалыннан гыйбарәт күпсанлы язма истәлекләрне ачтылар һәм аларны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрделәр.

Борынгы Көнчыгыш Европадагы экономик бәйләнешләрне өйрәнү монда «кыргый далалар»ны түгел, бәлки гуннар дәүләте, Төрки каганлыгы, Хазар дәүләте яки Идел буе Болгар йорты һ. б. кебек товар-акча мөнәсәбәтләре үскән дәүләтләр күрергә мөмкинлек бирә. Гәрчә бу дәүләтләргә этник бердәйлек хас булмаса да, алар экономик яктан гына түгел, политик

һәм этник яклардан да дәвамчанлыкка, традицияләргә ия булганнар. Ә инде авар, бәҗәнәк яки монгол яуларына килгәндә, алар, элеге дәүләтләргә генә һәлакәт китермичә, байтак халыкларның тарихи үсешендә эз калдырганнар.

Гун кабиләләре арасында «төрки» дигән этноним чагыштырмача тиз тарала. Инде урта гасырлар башына караган чыганакларда ук, мәсәлән, «Алваннар тарихы»нда (VII гасыр) «төрки», «гун» яки «хазар» этнонимнары синоним итеп кулланыла, ә Хазар дәүләте «Төркстан», «Төркиләр иле» дип атала. VII гасырга караган «Әрмән географиясе»ндә дә «Төркстан» төшенчәсе шул мәгънәдә кулланылган.

«Төрки» терминының килеп чыгышына кагылган әдәбият бик зур. Аның ваклыкларына кереп тормастан, бу терминның хазарлар, суарлар һәм болгарлар арасында тиз һәм киң таралуы терминның мәгънәсенә бәйле булганлыгын күрсәтеп узыйк. Баштарак ул, этник мәгънәдән бигрәк, абруйлы, политик мәгънәгә ия булган. «Төрү» термины борынгы төрки телдә «дәүләт»не белдергән, ә -әк кушымчасы ялганган «түрк» сүзе башта зуррак берләшмәгә, дәүләткә кергәнлекне белдергән дип карарга мөмкин [1]. Бу исә чагыштырмача вак кабиләләр өчен тынычлык һәм иминлек гаранты булган. Орхон-енисей руник истәлекләре дә шул хакта сөйли. Хәтта төркиләрнең (тар мәгънәсендә) үзләре арасында да сир, токуз-угыз кебек ыру исемнәре сакланып калган.

Хазар теленең гомумилеге һәм төрки алфавит нигезендә язу барлыкка килү күп кенә тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Бу проблеманы өйрәнү Көнчыгыш Европада товар-акча мөнәсәбәтләрен тикшерүгә турыдан-туры кагыла. Мәсәлән, акчаларда иң беренче төрки язулар, шулай ук затлы металлдан эшләнгән һәм, әйтик, Сент-Миклош хәзинәсендәге кебек алмашу әйбере булып хезмәт иткән савытлардагы язулар хәзергә кадәр канәгатьләнерлек итеп укылмаган, чөнки хазар чорының руник алфавиты тиешенчә өйрәнелмәгән һәм ачыкланмаган, ягъни бу чордагы гомум төрки телнең характеры ук билгесез.

---

[1] Малов С. Е. Памятники древнетюркской письменности. М.; Л., 1951, 44 бит.

Соңгы елларда җыелган тел материалы Хазар дәүләтенең бердәм теле турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Ә Хазар дәүләте таркалгач, шул территориядә яшәгән болгарлар, суарлар, Көнчыгыш Европадагы һәм Кавказдагы башка төрки халыклар бу телне мирас итеп алганнар.

Уйгырларның бер тармагын тәшкил иткән хазарларның теле башта ук төрки нигезле булган һәм суар, болгар, барсиллар һ. б. теленә хас диалекталь үзенчәлекләрнең мәгълүм йогынтысын кичергән.

Бу телнең аерым фрагментлары, безнең фикеребезчә, язма чыганакларда, торевтика һәм эпиграфик истәлекләрдәге язмаларда шактый яхшы сакланган. IV гасырдан башлап алар албан, әрмән, грузин, Сүрия һәм Византия чыганакларында очрыйлар. Әрмән әсәрләрендә алар аеруча күп. Инде гун-төрки теленең аерым фрагментларында ук бу телнең кайбер үзенчәлекләрен — к/қ > х, б > в/п, ф > п, қ > һ авазларның чиратлашуын һ. б. ны күзәтергә мөмкин.

Мондый үзенчәлекләр XIII гасыр авторы Ованнес әсәрендә китерелгән өзектә бик яхшы күренә. Күрәсең, тагы да борынгырак христиан әсәреннән алынган бу өзекне борынгы төрки классик шигыренең үрнәге дип карарга кирәк:

Алтынтен тирәк улты,
Христос йемишин верти.
Пизи өяктән хутарти,
Тәңрим анаси Мәриәм.

Алтыннан тирәк булды,
Христос җимешен бирде.
Безне иблистән коткарды
Тәңрем анасы Мәрьям.

Өзек егерме юлдан тора һәм кайбер авторлар аны азәрбайҗан теленең үрнәге итеп китерәләр. Ләкин аны борынгы татар теле дип тә һәм, тартыкларның характерлы саңгыраулануына нигезләнеп, чуваш теле дип тә карарга була. Күрәсең, бу өзекне хазар-төрки телендә язылган дип санау дөрес булыр. Торевтика һәм эпиграфик язмалар да моны раслый. Кайбер тикшеренүчеләр аерым төрки телләрдә тартыкларның болай саңгыраулануы угро-фин телләре йогынтысында килеп чыккан дип исәплиләр. Мондый үзенчәлекләр гун теленә дә хас булган һәм аның тарихының бик борынгы чорларында ук барлыкка килгән. Мәсәлән, гуннар ха-

кимлек иткән чорда Хәрәзм акчаларында сүз башындагы тартыкның саңгыраулануы күзәтелә һәм Бохара урынына Покара дип языла. Башкала Итил шәһәрендәге аланнар (ягъни хазарлар һәм болгарлар) хәрәзмбәҗәнәк телендә сөйләшәләр дигәндә, Бируни (973—1050 ел тирәсе) Хәрәзмдәге кебек тартыкларның саңгыраулануы һәм угыз элементлары хас хазар-төрки телен күздә тоткан булырга тиеш.

Идел буендагы икенче стильгә караган кабер ташларындагы язуларда да шул ук үзенчәлекләр күзәтелә: «Чәримсән суына барса үлти», ягъни «Чиремсәнгә барышлый (батып) үлде», «вафат болты» — «вафат булды», «Аллаһу тәгали рәхмәти болтын» — «аллаһы тәгалә рәхмәте булсын», «Сәфәр айхы эти» — «сәфәр ае иде» һ. б.[1].

1863 елда татар галиме Х. Фәезханов үзенең болгар кабер ташлары турындагы хезмәтендә, татар һәм чуваш телләреннән файдаланып, «җиәти җүр» санын «җиде йөз» дип укыганда, беркадәр примитиврак булса да, нигездә дөрес юлдан бара. Ләкин бу мәсьәлә буенча бик күп хезмәтләр язылуга карамастан, ул һаман бәхәсле булып кала әле. Хәтта әлеге үзенчәлекләргә нигезләнеп, болгарларда төрки телдән үзгә ниндидер башка бер тел булган дигән теория дә дөньяга килде.

Ә бит дистәләгән болгар шәһәрлекләрендә йөз ел буена үткәрелгән археологик казу эшләрендә мондый теорияне расларлык бернинди язма истәлекләрнең дә табылганы юк. Киресенчә, болгарларның гомумтөрки телдә сөйләшкәнлекләрен, бу телдәге специфик үзенчәлекләрне тулысынча аңлатып булуын раслаучы күпсанлы материаллар тупланды. Мәсәлән, гомумтөрки характердагы болгарча язулы уннарча мең бакыр акчалар табылды.

Бу бик кызыклы тел материалына тарихчылар һәм телчеләр, безнең карашыбызча, әле һаман да игътибар итеп җиткермиләр. Бакыр акчалар җирле әһәмияткә генә ия булып, үзләре сугылган шәһәрдә генә әйләнештә йөргәннәр. Димәк, бакырдан сугылган болгар акчаларындагы «Котлуг булсын яңы пул!» (Котлы булсын яңа пул!) һ. б. язулар Болгар шәһәрендә һәм аның тирәсендә яшәүче һәм норматив болгар телендә

[1] Хакимзянов Ф. С. Язык эпитафии волжских булгар. М., 1978.

сөйләшүче халыкка адреслана. Мондый язуларның иң борынгылары XIII гасырга карый.

Икенче стильдәге борынгы эпиграфик истәлекләр дә XIII гасырга карыйлар. Ләкин аларның теле һәм архаик куфи язуы югарыда китерелгән шигъри өзектәге кебек тел үзенчәлекләренең борынгырак хазар чорына каравы һәм клерикаль (дини) язма тел фрагментлары буларак саклануы турында сөйли. Болгар теленең үсешендәге югарыда әйтелгән үзенчәлекләрнең XIII гасырга инде узылган баскыч булуын, акчалардан тыш, бик матур бер алтын касәдәге язу да күрсәтә: «Сәнә: хәзрәт Мәккәдин Мәдинәга баргали алты йөр ун ити».

Без, бүгенге мәгълүматларга таянып, бу язманың укылышын яңадан карарга кирәк дип уйлыйбыз. Мәсәлән, соңгы сүзне «җиде» дип түгел, бәлки «иде» дип укыганда җөмлә мәгънәви бөтенлеккә ирешә: «Ел: хәзрәт Мәккәдән Мәдинәгә барганда алты йөз ун иде». Әлбәттә, моны мәгънә бөтенлеге генә таләп итми. XII—XIII гасырларга караган чыганакларда «ите» сүзенә «иде» яки «ирде» сүзләре туры килә. Ләкин икенче стильдәге эпиграфик истәлекләрдә аның борынгырак «ити» формасы бар. Сүз башында «әлиф»нең булмавы, икенче стиль эпитафиясендә очраган «уон» (ун) сүзендәге кебек (анда алда «әлиф» юк) калдык дифтонг булуыннан киләдер. Димәк, язудагы датаны һиҗри 610 ел (1210/1221) дип укырга кирәк.

Бу язуда «йөз» урынына шактый ачык итеп язылган «йөр» сүзе дә аны эпиграфик истәлекләрдәге икенче стиль язуларына якынайта.

Бу язуның көзгедә чагылган кебек итеп башкарылуы да игътибарны җәлеп итә. Савытны соңгы тикшерүчеләрдән берсе XIII гасырда Идел буенда эшләгән алтынчы маһир гарәп әлифбасын белмәгән һәм язуны башка савыттагыдан механик төстә күчергән генә дигән фантастик версия күтәреп чыккан иде. Ләкин акча штемпелендәге язулар күрсәткәнчә, көзгедә чагылганча итеп язу өчен аеруча осталык сорала. Ә савыттагы язу төгәл, ачык һәм насталикка якын кул белән башкарылган.

Бу очракта без кайбер башка төрки истәлекләргә дә хас булган яшерен язуга тап булабыз шикелле. Ихтимал, яшерен язу куллану төрки халыкларда «туу» яки «үлү» кебек аерым сүзләргә һәм гыйбарәләргә карата табу һәм эвфемизмнар булуына бәйледер. Табу әйтергә ярамаган теге яки бу сүзне (гыйбарәне) башка

сүз (гыйбарә) белән алмаштыра. Алтын савыттагы язуда, ихтимал, берәүнең туган вакыты яки башка мөһим вакыйганың датасы «ырым»нан саклау өчен шушындый үзенчәлекле ысул белән яшерелгәндер. Кавказда алан күмү мәгарәләрендәге төрки язмалар да, күрәсең, шуны ук күздә тоталар: аерым руник тамгалар танымаслык булып зурайтылганнар яки авышканнар.

Сармат-алан чорына караган бер кабердә табылган өчпочмаклы агат таштагы язуны да шундый ук ырым дип карарга мөмкин. Анда хәрәзм хәрефләре белән язылган язу шул ук әйбердә «киресенчә» кабатлана. Бу әйбер бөти булып хезмәт иткән булырга тиеш.

Хазар дәүләте җимерелгәннән соң, аның территориясендә — Кавказда, Кырымда, далаларда һәм Идел буенда берничә яңа дәүләт оеша. Алар хазар каганлыгының күп кенә культура казанышларын, шул җөмләдән бу дәүләтнең бердәм төрки телен дә, барлык атрибутлары белән бергә, мирас итеп алалар. Кайчагында әлеге ялгыш теориянең тарафдарлары булмаган кешеләр дә, инерция буенча, кыпчак һәм болгар телләре арасында зур аерма булган дигән фикер үткәрәләр.

Безгә билгеле булган барлык фактлар кыпчак теленең дә, болгар теле кебек үк, соңгырак чорга каравын, хазар-төрки теленең шушы җирләрдәге үсешендә закончалы баскыч булуын күрсәтәләр. Көнчыгыш Европага кыпчаклар соң гына килеп чыкканнар дигән караш тарихи чыганаклар белән расланмый. Имештер, «кыпчак» сүзе Сыма Цянда (яңа эрага кадәр 145—87 еллар) ук телгә алына дигән фикер бу сүзләрнең өлешчә охшашлыгына гына нигезләнгән. Ул хронологик күзлектән караганда да ышандырмый, чөнки бу атаманы беренче тапкыр телгә алу белән икенчесе арасында мең еллык чор ята [1].

Иң яңа мәгълүматлар һәм мәсьәләгә тарихи якын килү, шулай ук бу һәм башка этнонимнарны төрки телләрнең үзләренә нигезләнеп аңлату ышанычлырак нәтиҗәләр алырга мөмкинлек бирер иде. Беренчедән, «половец» һәм «кыпчак» дигән ике төрле этнонимны бутарга ярамый. Бүгенге «кыпчак» сүзе — әйтик «көн-

---

[1] Добродомов И. Г. О половецких этнонимах в древнерусской литературе. Тюркологический сборник. М., 1978, 111 бит.

чыгыш славяннар» кебек гомумирәк төшенчә, ә «половец» аерым кыпчак кабиләсен белдерә.

Тикшеренүчеләр борынгы рус телендә генә түгел, күп кенә башка телләрдә дә «половец» сүзенең «аксыл», «ачык төстәге» төшенчәсенә тәңгәл булуына игътибар итәләр. Бу мәсьәлә буенча берничә гипотеза яши. Ләкин, безнең фикеребезчә, бер бик мөһим нәрсә һаман игътибардан читтә кала. Хикмәт шунда ки, рус теле нигезендә туган «половец» сүзе калькалаштырылган формада кулланыла торган азсанлы этнонимнарның берсе (обр, козар, болгар, печенег дигән русча атамалар белән чагыштырыгыз). Ә бу көнчыгыш славяннарның, ихтимал Киев Русе оешканга кадәр үк инде, половецлар белән һәм аларның үзатамалары белән таныш булулары турында сөйли («половец» сүзе шул атамадан тәрҗемә).

Мәгълүм булганча, половецлар үзләрен «сорочиннар» дип йөрткәннәр[1]. «Сары» сүзе дөнья якларын билгеләүдәге катлаулы системага барып тоташа. Бу система буенча әле гуннар чорында ук сары сүзенең «үзәк»не белдерүен без әйткән идек инде (сарыгурлар). Көнчыгыш төркиләрендә бу төшенчәне белдерү өчен VI гасырда ук теркәлгән «ак» сүзе кулланылган. Ләкин һәр ике очракта да бу сүзләр күчелмәгән мәгънәгә: «бөек» мәгънәсенә ия. Ул, күрәсең, үзәктә «бөек» хөкемдарның биләмәсе булуына бәйледер. Ахыргы исәптә «ак» сүзенең «югары», «затлы», «ак төс» мәгънәләре киңрәк тарала һәм гомерлерәк була. Шулай итеп, сорочиннарның халык этимологиясе үзләренең нәселен «сары» яки «ак», «бөек» сүзләре белән бәйли һәм ул башка телләргә дә үтеп керә.

Без «коман» сүзен «коба», ягъни сары сүзенә тоташтыру һәм аны «половец» сүзенә якынайтырга тырышу җитәрлек нигезләнмәгән дип уйлыйбыз[2]. Кыпчак һәм коман сүзләре бер тамырдан булырга охшый. «Кыпчак» сүзе кайбер күчмә кабиләләрнең, шул исәптән төрки телнең кыпчак диалектында сөйләшүче со-

---

[1] Добродомов И. Г. Күрсәтелгән хезмәт, 105 бит. Этноним, күрәсең, ике сүздән: *сары* һәм *чин* сүзләреннән тора, ягъни ул «бөек урданыкы» (үзәк) һәм «гун» сүзләреннән төзелгән. Гуннарны IV гасыр әрмән һәм грузин чыганаклары ченнар дип атый. һ>с>ч күчеше төрки тел диалектларына хас.

[2] Баскаков Н. А. Тюркизмы — этнонимы в «Слове о полку Игореве». Советская тюркология, Баку, 1982, № 4, 16—17 битләр.

рочиннарның яки половецларның уртак үзатамасы, ә «коман» сүзен күрше халыклар яки көнбатыш чыганаклары төрле халыкларның этнонимы сыйфатында кулланганнар. Мәсәлән, Рубрук кыпчакларны һәм каңлыларны команнар дип исәпли. V—VI гасырларга караган әрмән чыганакларында бу сүз тагы да борынгырак «хунан» формасында очрый.

Бу очракта н>м>б авазларының күчеше төрки телләрдә билгеле нәрсә. Шулай ук х>к (арткы) күчеше дә табигый (хунан — куман). Шулай итеп, әлеге авазларның күчеше тарихи чыганакларда теркәлеп калган һәм, күрәсең, «кыпчак» этнонимының килеп чыгышында һәм кыпчакларның формалашуында гуннар һәм аларның үзатамасы билгеле бер роль уйнаган. «Коман» сүзе исә кыпчак телендә үзатаманы түгел, бәлки илне, якны белдергән, -ан суффиксы гуннар телендәге «йорт», «ил» мәгънәсен бирә. Гуннарның бер өлеше урта гасырлар башында Төньяк Кавказда һәм Кубаньда утырып калган. VI гасыр чыганакларында бу өлкә аларның исеме белән «гуннар өлкәсе» дип атала [1]. Бу атама «Кубань» сүзендә сакланган.

Кыпчакларны (венгрча «кун») гуннар белән янәшә кую яңа түгел. Ләкин бу атама, тулаем алганда, төсне билгеләүче сүз (сары, аксыл һ. б.) буларак карала. «Кыпчак» терминының үсешен тарихи планда карап, аның күп гасырлар буена җанлы тел мохитендә үзгәрешен исәпкә алырга, VIII—XI гасырларда формалашкан терминны антик чорга караган Кытай хроникаларыннан эзләмәскә кирәк.

Без «кыпчак» сүзе, «коман» сүзе кебек үк, ике өлештән: *кун* һәм *чак* кисәкләреннән тора дип уйлыйбыз. Инде әйтеп кителгәнчә, н>м>б>п күчеше (кунчак, комчак, кыбчак һ. б.) табигый, ә сүзнең икенче өлешенә килгәндә, күрәсең, ул кыпчак телендә «кеше» дигән мәгънәгә ия булган. Мәсәлән, «Игорь явы турында җыр»да «чага» — половецларның әсир төшкән хатын-кызы.

Җыеп кына әйткәндә, болгар һәм кыпчаклар, Кавказдагы һәм Көнчыгыш Европадагы кайбер башка төрки халыклар кебек үк, Хазар каганлыгы чорында формалашкан уртак телне мирас итеп алганнар дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Димәк, акча-авырлык система-

---

[1] Хауссиг Г. В. К вопросу о происхождении гуннов. Византийский временник, 38 том, М., 1977, 71 бит.

сына караган барлык хазар терминнары Идел бассейнында хазарларның варисы булган болгар теленә дә күчкән дип уйларга кирәк. Фәнгә билгеле булган соңгы хазар акчасы белән беренче болгар акчалары арасында мәгълүм өзеклек булса да, Идел буенда элекке үрнәкләргә ияреп акча сугу да, товар-акча мөнәсәбәтләре дә тукталмаган булырга тиеш.

X ГАСЫРДА СУГЫЛГАН БОЛГАР АКЧАЛАРЫ

VII—X гасырларда Хазар дәүләте затлы җәнлек тиресенә бай Төньяк Кама буе, Обь һәм Тобол елгасы буйлары белән товар алмашу — сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыра. Ләкин Көнчыгыш Европадагы бу борынгы феодаль дәүләтнең закончалы рәвештә таркалуы, Болгар йортының аерылып чыгуы һәм көчәюе товар алмашу юнәлешендә үзгәрешләр китереп чыгара. X—XII гасырларда Көнчыгыш Европага, Төньяк Уралга һәм Түбән Обь буена юл җанлана төшә.

Әйбер алмашуның төньяк-көнчыгыш юнәлештә җанлануын X—XII гасырларга караган сәнгать әйберләренең күпсанлы хәзинәләре раслый. Болар башлыча примитив металл акчалар: Урта Азиядә, Хазар илендә, Византиядә, Русьта һәм Болгар йортында ясалган касәләр, тәлинкәләр, чүлмәкләр һ. б.

Алмашу әйберләре Идел буена көньяк илләрдән Урта гасырлар башында ук салынган юллардан килгән дип уйларга кирәк. Шундый юлларның берсен Ибн Хәүкәл (978 еллар тирәсе) түбәндәгечә тасвирлый: «Абаскуннан хазар җирләренә кадәр диңгезнең сул як яры буйлап утрак тормышлы җирләр сузыла... ә аннары Арран чикләренә кеpәсең һәм Муканны үтеп Баб-уль-Абвав (Дербент) чикләренә җиткәч..., Сәмәндәр өлкәсенә кадәр 4 көн барасың... ә Сәмәндәрдән Итилгә кадәр дала буйлап 7 көнлек юл».

Ләкин IX гасырның азакларында Идел буен Хәрәзм белән бәйли торган кәрван юлы җанланып китә. Электән үк билгеле булган бу юлны 922 елда Багдадтан Болгарга сәяхәт иткән Ибн Фадлан тасвир итә. Хазарлар белән Гарәп хәлифәлеге арасындагы мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе һәм Тимер Капка (Дербент) аша сәүдә юлларының тынып калуы аркасында Урта Азия белән сәүдә итү көчәя.

Идел буенда төрле савытлар һәм бронза коелмалар рәвешендәге примитив акча әйләнеше баскычы инде

узылган була, андый нәрсәләр, акча сыйфатында, нигездә урман кабиләләре арасында гына саклана. Бу чорда Көнчыгыш Европада һәр җирдә металл акчаларга (тәңкәләргә) даими һәм зур ихтыяҗ туа.

Идел буенда куфи дирһәмнәренең шактый интенсив әйләнеше хазар һәм болгарларның Урта Азия белән сәүдә элемтәләре ныгуга гына түгел, бәлки дирһәмнәргә ияреп күпләп акча сугуга да бәйләнгән.

Көнчыгыш Европага куфи дирһәмнәре Идел буе аркылы үтеп кергән, ә Идел буена, үз чиратында, Урта Азия һәм Кавказ аша килгән дигән фикер бар. Акча хәзинәләренә карап фикер йөрткәндә, IX гасырдан башлап Кавказ юлы инде икенче планга күчә. Ләкин монда Иделдән көнчыгышта куфи дирһәмнәре күмелгән хәзинәләрнең гаять сирәк очравы игътибарга лаек. Ягъни, тулаем алганда, Хәрәзмгә юл да шактый очраклы характерда булган. Дөрес, кайбер тикшеренүчеләр Каспий аша су юлы да булу ихтималы бар дип саныйлар, ләкин мондый фикер әлегә дәлилсез гөманлау гына булып кала.

Шулай булгач, Идел буе шәһәрләре акча әйләнешенең төп үзәкләре генә түгел, бәлки «көнчыгыш» акчаларын күпләп сугу үзәкләре дә булганнар дип уйларга туры килә.

Урта Идел хәзинәләрендә X гасырга караган акчаларның күпчелеге болгарлар үз акчаларын чыгара башлаганга кадәр саманид акчаларына охшатып сугылган акчалардан гыйбарәт. Үз акчаларын суккан чорда, ягъни X гасырда да, аларны күпләп чыгаруны дәвам иткәннәр.

Безнең күзәтүләребез буенча, Идел буендагы X гасыр хәзинәләренең төп массасын сан ягыннан шушылай ияреп сугылган акчалар тәшкил итә. Иң аз дип исәпләгәндә дә, алар Көнчыгыш Европа хәзинәләренең яртысын тәшкил итәләр, яки саманид тәңкәләреннән соң икенче урында торалар, ә аббасид акчалары өченче урында. X гасыр башында омейад акчалары әйләнештән чыга. Димәк, Идел буенда нигездә хазар-болгар акчалары кулда йөри, алар арасында сасанид, омейад, аббасид тәңкәләре кебек көнчыгыш акчалары да очрый. Төрле чорларда аларның чагыштырма нисбәте төрлечә булырга мөмкин.

IX гасырда Көнчыгыш белән сәүдә итүдә хазарлар мөһим роль уйнаган булырга тиеш. Хәрәзмнән Шарык

илләренә чыгарылган җәнлек тиреләренең «хазари» дип аталуы шул хакта сөйли.

Мәгълүм булганча, хәлифәлек таркалган чорда идарә иткән хәлиф Абул Фадл Җәгъфар эл-Мөтәваккиллаһ ибн Мөтәсим (847—861) үз биләмәләрен улларына бүлеп бирә һәм тора-бара күпсанлы династияләр, шул исәптән Урта Азиядә Бохараны башкала иткән саманидлар династиясе һәм дәүләте барлыкка килә.

Саманид тәңкәләренә ияреп сугылган иң беренче акчалар хазарларныкы булса кирәк. Ләкин хазарларда VIII гасырда ук башланган акча сугу әше мөстәкыйль, ягъни үз акчаларын чыгаруга китерми. Моны исә каганның яһүд динен кабул итүе илне политик һәм экономик яклардан изоляцияләве белән генә аңлатырга мөмкин. Хәтта каганга буйсынган болгар илтәбәре Әлмеш тә (аның улы каган сараенда әманәт сыйфатында яши) үз акчасын чыгарган бер вакытта, дини карашлары аркасында, каган үз исеменнән түгел, ә саманид тәңкәләренә ияреп кенә акча сугу белән чикләнә. Ә бит, А. А. Быков сүзләренә караганда, хазар шәһәрләрендә ислам динен тотучылар күп булган, алар «...хазарларга очратырга туры килгән иң алдынгы культура вәкилләре булганнар» [1].

Беренче саманид Насир бин Әхмәт (874—892) акчаларына охшатып сугылган тәңкәләр аз һәм еш кына аларны моннан беркадәр соңрак, 914—943 елларда тәхеттә утырган икенче саманид, шулай ук Насир бин Әхмәт акчаларыннан аеру да кыен.

Үрнәкләргә ияреп сугылган акчаларны оригиналның үзеннән аеру җиңел түгел. Күрәсең, VIII—IX гасырлардагы акча сугу осталары өчен яңа сугылган акчаларның куфи дирһәмнәре арасында күзгә ташланмавы, халыкның һәм сәүдәгәрләрнең ул акчаны каршылыксыз кабул итүе әһәмиятле булган. Мәсәлән, Казан губерниясендә табылган һәм Мансур бин Нух тәңкәләренә охшатып акча сугу өчен хезмәт иткән җиз штемпель моны бик ачык күрсәтә. Язуына караганда, ул нумизматлар гадәттә саманид Мансур бин Нухныкы (961—979) дип уйлаган акчалардагы язулардан бик аз аерыла.

---

[1] Быков А. А. Из истории денежного обращения Хазарии в VIII и IX вв. «Восточные источники по истории народов Юго-Восточной и центральной Европы» китабында. М., 1974, 63 бит.

IX гасырдагы Болгар шәһәрләре һәм тораклары хәзергә билгесез. Бу чорда болгарлар Хазар дәүләтенә кергәннәр һәм каганга ясак түләгәннәр. Димәк, Урта Идел буенда да, Кама буенда да хазарларның сәүдә факторияләре булган. Ләкин әкренләп җәнлек тиресе белән сәүдә итүдә беренче урынга Урта Идел шәһәрләре чыга, чөнки алар иң уңайлы һәм табышлы җирләрдә урнашкан булалар. Бу хәл X гасырдан да иртә булмаган, күрәсең. Мәсәлән, сәяхәтче әл-Мөкатдәси (X гасырның икенче яртысы) бу турыда түбәндәгеләрне яза: «Кеш, тиен, ас, сусар, төлке, кондыз, куян, кәҗә тиресе, балавыз, ук, эре балык, бүрек, балык җилеме, балык сөяге, кондыз шифалыгы (бобровая струя), йомшак күн, бал, чикләвек, барс (яки ау эте), кылыч, ярак (кольчуга), каен агачы... Барлык бу товарлар Болгар йортыннан»[1].

Шуңа күрә IX гасыр ахырында яки X гасыр башында хазарлар да саманид тәңкәләренә охшатып массакүләм акча сукканнардыр, дип фараз итү табигый булыр. Мәсәлән, Насир бин Әхмәт (914—943) исеменнән сугылган акчалар шактый табыла. Р. Р. Фасмер бу акчаларның күбесендә Насир бин Әхмәтнең исемен укып була, ә аның варисларының исеме белән сугылган акчалар аз билгеле, дип күрсәтеп үтә. Р. Р. Фасмерның бу фикере борынгырак акчалар күмелгән хәзинәләргә карата гына дөрес. Семенов авыллыгында, мәсәлән, X гасырның икенче яртысына караган хәзинә табылды, анда акчаның күпчелеген Мансур бин Нух (961—976) тәңкәләре тәшкил итә.

Борынгы болгар шәһәрләре халкын формалаштыруда төрле кардәш этнокультуралы төркемнәр: уртак хазар-төрки телдә сөйләшкән болгарлар, хазарлар, суарлар һ. б. катнаша. Тәнки каберлегендәге (борынгы болгарлар) мәет күмү йоласының аерым яклардан Кама буендагы Поломск — Ломатов истәлекләрендә, Башкортстандагы кайбер истәлекләрдә, Салтово (хазар) истәлегендә, Олы Тархан каберлегенең (тагы да борынгырак болгарлар) истәлекләрендә һ. б. аналоглары табылу очраклы гына түгел.

X гасырга караган хазар, болгар һәм суар акчаларын аларны суктырган хөкемдарлар исеме буенча күздән кичерик.

---

[1] Хвольсон Д. А. Известия о хозарах, буртасах, болгарах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар ибн-Даста.- СПб., 1869, 181 бит.

1. Габдулла бин Тәкин. Бу хөкемдарның акчалары, төрле ялгышларына һәм төгәлсезлекләренә карап фикер йөртсәң, үрнәкләргә ияреп сугылган гадәти акчалардан аз аерыла. Сугылу урыны ачык төшмәгән: әллә Нисабур, әллә Суар. Ботель хәзинәсендә Габдулла исеме белән чыгарылган биш данә акча булган.

Кайбер тикшеренүчеләр Габдулла исеме сугылган тәңкәләрнең Болгар йортыныкы булуына шикләнәләр. Ләкин акча язуында хөкемдар атасының төрки исеме булу гына түгел, язуның кайбер үзенчәлекләре дә сагайта. Мәсәлән, алгы якта мәҗбүри символ исәпләнгән «Мөхәммәт — алла илчесе» урынына «Илаһе. Мөхәммәд Габдулла бин Тәкин» сүзләрен укыйбыз. Ягъни символның башы бар һәм шунда хөкемдарның исеме белән атасының исеме басылган. Акчада шундый мөһим элементны ялгыш кына төшереп калдыру мөмкин түгел. Хикмәт шунда, аббасидлар акчасында әлеге символ омейадлар символы урынына куела башлый.

Хазарлар белән аббасидлар арасында дини нигездә каршылыклар килеп чыгуы билгеле. Аббасидлар чорындагы хазар акчалары иске омейад акчаларындагы язуны кабатлыйлар. Шунысы кызык, омейад акчаларының арткы ягындагы әлеге символ болгарларның саманидларга ияреп суккан чагыштырмача соңгырак акчаларында да очрый. Мәсәлән, «Сәмәрканд»та Мансур бин Нух исеменнән һиҗри 365 елда сугылган һәм Семенов хәрабәләрендә табылган бер акчада гадәти символ урынына коръәннең 112 нче сүрәсеннән алынган шул ук омейад символы тора: «Алла бердер, мәңгелектер, ул тудырмый, тумаган һәм аңа беркем тиң түгел.» Боларны исәпкә алып, борынгырак хазар мәзһәбендәге ислам Идел буенда X гасырда да яшәп килгән дип фараз итәргә була.

Шушы уңайдан, болгарларның ислам динен кайчан кабул итүе турындагы мәсьәләгә кагылышлы сорау туа. Шик тә юк, Идел буенда ислам дине 737 елда (хазар каганы ислам диненә күчеп, мөселманлык тарала башлаган ел) рәсми төстә кабул ителгән.

Тәнки каберлегендәге мәет күмү йоласына караганда, болгарлар X гасырдан гына, утрак тормышка күчә баруга бәйле рәвештә, мәетне яңача җирләү йолаларын үзләштергәннәр. Хәер, шунысын да әйтергә кирәк, мәет җирләү йоласы, бигрәк тә күчмә халыкларда, хәтта дин кабул иткәч тә, кагыйдә буларак, бик

акрын үзгәргән. Ибн Рустә 903—912 елларда язылган «Кыйммәтле хәзинәләр китабы»нда болгарлар арасында ислам диненең нәкъ менә шәһәрчекләрдә таралуын хәбәр итә: «Аларның күпчелеге ислам динен тота, шәһәрчекләрдә аларның мәчетләре һәм башлангыч мәктәпләре, мәзиннәре һәм имамнары бар».

Ихтимал, бу борынгы хазар мәзһәбендәге ислам булып, гыйбадәт кылуда клерикаль төрки лексика зур урын тоткандыр. Шуңа күрә Ибн Фадлан килгәнче укылган һәм аны гаҗәпкә калдырган хөтбәдә болгар хөкемдарының төрки исеме телгә алынуын Идел буенда VIII гасырдан ук килгән традицияләр белән генә аңлатырга мөмкин.

С. А. Янина мөселман диненең уңышлары Ибн Фадлан исеме белән бәйле дигән ялгыш фикернең таралуына «...хикәянең тенденциоз булуыннан бигрәк, аның тәрҗемәсенең һәм аңлатмаларының тенденциоз булуы» булышлык иткән, дип уйлый.

Ибн Фадлан килгәнгә кадәр мәчеттә хөкемдар өчен гыйбадәт «Йа ходай, Балтавар патша, болгар мәлиген ярлыка» рәвешендә яңраган. Хөкемдарның исеменә карата төрле фикерләр яши. Берәүләр аңарда хөкемдар исемен, икенче берәүләр болгарларның бер кабиләсе булган берсулларның исемен күрә. Өченче галимнәр аны болгар хөкемдары титулы илтәбәр (илитбер) дип уйлый. Бүгенге әдәбиятта моның хөкемдар титулы булуы мөмкин дип карала. Ихтимал, бу чыннан да шулайдыр, Ибн Фадлан хөтбәнең «патша, фәлән-фәлән илтәбәр» дигән гомуми формуласын китергәндер.

Р. Р. Фасмер Габдулла бин Тәкиннең акчаларын билгеләү кыен булганга, аны Болгар хөкемдарлары арасында иң соңгы чиратка куя. Ләкин гадәттә борынгырак хөкемдарның акчасын билгеләү кыенрак, соңга таба акча сугу алымнары камилләшә, язулар да ачыграк төшкән була.

Габдулла бин Тәкин чыннан да Идел буе болгарларының хөкемдары булганмы һәм үз исеменнән акча сукканмы икәнен хәзергә тәгаен генә әйтү кыен. Бәлки киләчәктә, яңа акчалар табылгач, бу мәсьәләне ахыргача хәл итеп булыр.

2. Җәгъфәр бин Габдулла. Бу хөкемдарның акчасы әле күптән түгел генә билгесез иде. Җәгъфәр бин Габдулла исеме, ягъни болгар патшасы Әлмешнең мөселманча исеме төшкән акча сыныгы беренче тапкыр Новгород шәһәрендә археологик казу эшләре

үткәргәндә икенче Нерев хәзинәсендә табылды. Акчаның бер кисәге генә булса да, С. А. Янина аның Җәгъфар бин Габдулланыкы булуын бик нигезле итеп дәлилли алды.

Акчада Әл-Моктафи хәлифнең (902—908), саманид әмир Исмәгыйль бин Әхмәтнең (892—907) һәм Җәгъфар бин Габдулланың исемнәре бар. Акча чыгарылган датаны 902—908 еллар, ягъни әл-Моктафи хәлифлек иткән еллар дип билгеләргә мөмкин.

Ибн Рустәнең: «Болгарларның төп мөлкәте —сусар тиресе; болгарларда алтын яки көмеш тәңкәләр юк» дигән сүзләрен туры мәгънәсендә аңларга кирәкмидер. Көнчыгыш Европада «тире» акчалар кулда йөргәнлеге турында соңгырак гасырларга карата да мәгълүматлар бар.

Идел буенда VIII йөз ахырыннан, һәрвакыт регуляр тәртиптә булмаса да, үз акчалары сугыла башлавын без күпсанлы тәңкәләрдән беләбез. Шуңа күрә көнчыгыш авторларының «тире» акчалар турындагы хәбәрен аерым төбәкләрдә яки хәтта авыл халкының төп массасы арасында натураль алмашу гамәлдә булган дип аңларга кирәк.

Җәгъфар бин Габдулланың туры варислары чыгарган акчалар турында сүз алга таба булыр. Шул ук вакытта Идел буенда сугылган кайбер акчалардагы исемнәрнең чорын билгеләү кыен, ләкин акчадагы даталарга һәм башка билгеләргә карап, аларның борынгырак чорда сугылуын чамалап була. Идел буе Болгар дәүләтенең оешу тарихын без белеп бетермибез. Акчалардагы бу исемнәр һәм акча сугылган шәһәрләр Болгар дәүләте оешкан чордагы аерым феодаль төркемнәрнең бәрелешләренә ишарә булырга мөмкин.

3. Насир бин Әхмәт. Насир бин Әхмәтнең һәм әл-Муктадир хәлифнең һиҗри 301 елда (913/914) сугылган акчаларын Р. Р. Фасмер болгарлар саманид дирһәмнәренә охшатып суккан акчалар арасында аеруча уңышлылары дип саный. Ул Насир бин Әхмәт саманид әмирнең исеме дип уйлаган. Бәлки шулайдыр да. Ул чагында мондый тәңкәләр җирле акча сугу сараеның исеме күрсәтелгән бердәнбер акча булып калалар. Икенче яктан исә, Мөэмин акчаларында да (аның да атасының исеме Әхмәт) шул ук сугу урыны күрсәтелгән.

Үзенең кайбер хезмәтләрендә Х. М. Френ мондый акчаларның сугылу урынын «Сагар» дип транскрип-

цияли, ләкин «Сувар» дип укый. Р. Р. Фасмер Мөэмин бин Әхмәтнең һиҗри 366 елгы акчалардагы шул ук сугылу урынын «Суар» дип тә, «Болгар» дип тә укырга мөмкин дип саный, С. А. Янина исә «Суар» дип уку ягына авыша. Чыннан да, язуны Болгар дип укырга ныклы нигез юк. Икенче яктан, Талиб бин Әхмәтнең Суарда сугылган акчаларында исә «Суар» сүзе аермачык укыла һәм төрлечә аңлатуга урын калдырмый.

Югарыда сөйләнгән акчаларда сугылу урынын күрсәткән сүзне без нәкъ язылганча Сагар дип укып, аны хазар шәһәре Савгар (гарәп язылышында) дип фараз итәбез. Бу шәһәр Ибн Хордадбехнең (820—912) «Юллар һәм дәүләтләр» китабыннан билгеле.

4. Әмир Биләр. Акчаларга бу исем Әл-әмир б.л.р. м.а.л. рәвешендә сугылган. Исемне укуга карата төрле һәм кайчагында капма-каршы фикерләр бар. Без икенче стиль болгар кабер ташларында шундый ук исем очравына таянып, әмирнең исемен «Биләр» дип уку ягында торабыз. Өченче сүз, ихтимал, акча мәгънәсендәге «мал» сүзе булыр.

Дәүләт Тарих музее коллекциясендә чагыштырмача яхшы сакланган шундый ике данә акча бар. Бер данәсендә һиҗри 308 ел датасын укырга мөмкин. Бу дата Җәгъфар хакимлек иткән заманга туры килә. Ләкин монда гадәттән тыш берни дә юк. Җәгъфар Хазар дәүләте таркалып, Болгар йорты аерылып чыккан катлаулы чорда хакимлек итә. Аның атасы хазар титулы илтәбәр исемен йөртә, ә ул гарәпләрнең әмиренә тиң. Ибн Фадлан китабында китерелгән хөтбәгә карап фикер йөрткәндә, Әлмеш болгар мәлиге, ягъни болгар патшасы дигән яңа титулга ия була, монысы каганга тиң. Илтәбәр титулын Суар хөкемдары да, ихтимал, бүтән кабиләләрнең юлбашчылары да йөрткәндер. Шуңа күрә ниндидер яңа әмирнең акчасы чыгарылу табигый тоела.

Акчаларның сугылу урыны турында кистереп кенә ни дә булса әйтүе кыен. Шунысы мөһим, бу акчалар барысы да стильләре буенча Җәгъфар (Әлмеш) акчаларына ияреләр. Димәк, алар акча сугыла башлаган, ягъни Болгар дәүләте оеша башлаган чорга карыйлар. Җәгъфар бин Габдулла акчасы белән охшашлык һәм сугылу вакытының да аның хакимлек итү чорына туры килүе язуны башкача аңлатырга да мөмкинлек тудыра. Әмир исеме дип фараз иткән

сүзне «әл-әмир Биләр малы», ягъни «Биләр әмире акчасы» дип тә укырга мөмкин.

5. Мәмәктай бин Җәгъфар. Башлангыч чорда сугылган һәм беренче тапкыр С. А. Янина тасвир иткән бу акчаның алгы ягында Җәгъфар дигән язу бар, ә арткы ягындагы язу м. м. к. т. и. бин Җәгъфар дип укыла. С. А. Янина алгы якта эмирнең исеме, ә арткы якта аның улының исеме сугылган дип исәпли. Соңгысын ул укымый, ләкин аның соңрак хакимлек иткән Микаил исеме түгеллеген билгеләп үтә. Безнең фикеребезчә, ул исемне Мәмәктай дип укырга мөмкин. Икенче стильдәге кабер ташларында булган язуларга караганда, Мәмәк болгарларда киң таралган исем була, аның үзенчәлекле кушымчасы да болгарларга хас [1].

Акчада һиҗри 309 ел датасы бар, ләкин С. А. Янина билгеләп үткәнчә, бу акчаны Җәгъфар бин Габдулланың варисы, ягъни Мәмәктай бин Җәгъфар суктырган булырга тиеш.

6. Микаил бин Җәгъфар. Микаил бин Җәгъфар исеменнән сугылган акчаларда, башлыча, саманидлар дәүләтенең төрле шәһәрләре күрсәтелгән һәм шуңа күрә күпчелек нумизматлар аларны саманидлар суктырган дип исәпләгән. Ләкин Р. Р. Фасмер бу акчаларның Микаил бин Җәгъфарныкы булуын ышандырырлык итеп дәлилләде. Бу хөкемдарның билгеле булган барлык акчалары да диярлек Р. Р. Фасмер тарафыннан тасвир ителә. С. А. Янина Дәүләт Тарих музеендагы коллекциядән Микаил бин Җәгъфарның тагы бер акчасын тасвир итте. Анда хөкемдарның исеме м. и. к. а. л. рәвешендә сугылган. Түгәрәк легендасында сугу урынын укып була («Биболгар» — Болгарда).

Болгар акчалары арасында Микаил бин Җәгъфар акчасы иң күп очрый, шул сәбәпле ул озак еллар тәхеттә утырган һәм каганга ясак түләгән атасына караганда мөстәкыйльрәк булган дип фараз итәргә мөмкин.

Новгородтагы икенче Нерев хәзинәсе акчалары арасында хөкемдарның исеме бераз башка формада, ахырга «әлиф» өстәп сугылган (м. и. к. р (л?). а.) тәңкә табылды. Тышкы күренеше буенча ул Микаил бин Җәгъфар акчалары белән бер вакыттарак сугылган. С. А. Янина мондый акчаны Җәгъфарның өченче улы

---

[1] Хакимзянов Ф. С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978, 189—190 битләр.

суккан булырга мөмкин дип саный. Ләкин, безнең уебызча, мондый нәтиҗә ясау өчен мәгълүмат җитәрлек түгел. Ихтимал, бу — тәураттагы Микаил исеменең төркиләштерелгән «Михайла» кебек бер варианты гынадыр. Өстәвенә акчаларда бу исем Микал, Микиал рәвешендә язылган очраклар да сирәк түгел.

7. Габдулла бин Микаил. Дәүләт тарих музее коллекциясендә Абдулла бин Микаил исеменнән чыгарылган ике данә акча бар. С. А. Янина Габдулланың Микаил бин Җәгъфар улы икәнлеген исбат итте.

Шунысы кызык, акчалар бик кыска арада гына тәхеттә утырган әл-Мустакфи хәлиф исеме белән сугылган.

Ихтимал, Болгар хөкемдарлары да, саманидлар кебек үк, яңа хәлиф әл-Мутины танымыйча, акчаларга һаман әл-Мустакфи исемен куеп килгәннәрдер.

8. Талиб бин Әхмәт. Бу хөкемдарның акчалары Суар шәһәрендә һиҗри 337, 338, 341, 347 елларда сугылган. Алар элекке нумизматларга да яхшы таныш булганнар. Талиб бин Әхмәт акчалары әл-Мустакфи (944—946) хәлиф исеме белән чыгарылган. Димәк, һиҗри 347 елда бу хәлиф исеме белән сугылган акчалар ул тәхеттән төшерелгәч (345) чыгарылган.

9. Мөэмин бин Әхмәт. Идел буе болгарлары суккан акчаларны тикшергәндә, Р. Р. Фасмер Мөэмин бин Әхмәт акчаларын да тасвир итә, ләкин мондый акчалардагы Әхмәт исеме ихтимал Хәсән исемен башкача язу гына булыр дип уйлый. Ләкин С. А. Янина ике Мөэминнең: Мөэмин бин Әхмәтнең һәм Мөэмин бин әл-Хәсәннең акчалары барлыгын исбат итте.

Мөэмин бин Әхмәт акчалары Насир бин Әхмәт акчалары чыгарылган сарайда ук, ягъни Сагарда сугылган. Моннан тыш, С. А. Янина Мөэмин бин Әхмәт акчаларында Мөэмин бин әл-Хәсән акчаларындагы тамгадан аерылып торган үзенчәлекле тамга булуына игътибар итә.

Мөэмин бин Әхмәт акчасы ат-Таи хәлиф (974—992) исеме белән чыгарылган.

10. Мөэмин бин әл-Хәсән. Мөэмин бин әл-Хәсән акчалары Болгарда һиҗри 366 елда әл-Мути хәлиф (946—974) исеменнән сугылган. Нумизматлар арасында Мөэминнең атасының исемен укуда төрле фикерләр булуын әйткән идек инде. Р. Р. Фасмер Мөэминнең атасының исеме аермачык әл-Хәсән дип укыла торган акчалар да тапты.

Мөэмин бин әл-Хәсән акчаларының күбесендә руник алфавитның баштүбән әйләндерелгән «б» хәрефе сыман тамга бар (ул хәзерге «А» хәрефен хәтерләтә). Аерым руник хәрефләр һәм язулар X—XI гасырга караган материалларда яхшы күренә. Шушындый ук тамга Биләр һәм Болгар керамикасында еш очрый. Болгар чорындагы Үрмәт хәрабәләрен казыган вакытта бу юлларның авторы чүлмәк яндыру мичләре ачкан иде. Анда табылган савыт төпләрендә шул ук тамгалар бар.

Мөэмин бин әл-Хәсәннең һиҗри 370 елда ат-Таи хәлиф (974—992) исеме белән чыгарылган акчалары билгеле.

АКЧА СУГЫЛМАГАН ЧОРДА ТОВАР-АКЧА МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Болгар илтәбәрләре тарафыннан акча чыгарганнан соң, X гасыр азагында Болгарда һәм Суарда үз акчаларын сугу тукталып тора. Башка көнчыгыш илләреннән кергән куфи дирһәмнәре XI гасырның икенче чирегеннән башлап юкка чыга. Мондый гадәттән тыш хәл, бер яктан, акча сугучы илләрдә җир астындагы көмеш чыганакларының ярлылануыннан, икенче яктан исә базарда алмашу чарасына ихтыяҗның үсә баруыннан килеп чыга.

Ләкин акча сугылмаган чорда товар җитештерү һәм товар әйләнеше тукталмый. Киресенчә, X гасыр белән чагыштырганда, XI гасырда һәм бигрәк тә XII гасырда Идел буенда шәһәрләрнең, товар җитештерү һәм сәүдәнең бик тиз үсүе күзәтелә. XIII гасырның беренче чирегендә Урта Азиядә һәм Азәрбайҗанда көмеш акча сугу эше яңадан торгызыла һәм моны анда көмеш кризисыннан чыгу дип карарга мөмкин. Ә Идел буенда көмеш кризисыннан кайчан һәм ничек чыкканнар соң?

Түбән Иделдә XII гасырда болгарларның көчәюе һичшиксез экспансив характерда булган. «Болгар тарихы»ның авторы, Болгар тарихчысы Якуб ибн Ногман сүзләренә нигезләнеп, сәяхәтче әл-Гарнати хәбәр итүенчә, болгарлар белән хазарлар арасындагы бәрелеш дини нигездә башланган һәм зур гаскәр җыйган хазар патшасы болгарларга беренче булып һөҗүм иткән. Ләкин ул тар-мар ителә һәм соңыннан болгарлар куйган шартларны кабул итәргә мәҗбүр була. Чыннан да XII гасырда Иделнең урта агымында гына түгел,

түбән агымында да хазарлардан бигрәк болгарлар билгеле бер йогынтыга ия булалар. Гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати «Хазар илендә» монгол явына кадәр 50 еллар элек була һәм Саксин шәһәрендә 20 ел яши. Аның мәгълүматлары ышанычлы һәм тарихчыларда зур кызыксыну тудыра. 1135—1136 һәм 1150 елларда ул Саксиннан Шәһре Болгарга сәяхәт итә, шул ук вакытта сәүдә эше белән дә шөгыльләнә, үзе күргәннәрне язып бара. Аның сүзләренә караганда, Болгар сәүдәгәрләре «Караңгылык диңгезе»нә, ягъни Төньяк Боз океанына кадәр барып җиткәннәр. «Аларда көн бик озын, сәүдәгәрләр кояш кырык көн баемый, ә кышын төн шундый ук озын була дип сөйлиләр»,— дип яза әл-Гарнати.

Сәяхәтчеләр әл-Гарнатидан соң да җәнлек тиресе һәм морж теше белән сәүдә итүнең табышлы булуына игътибар итәләр. Гарәп сәяхәтчеләре сөйләвенә караганда, андый ерак төньяк халыкларына болгар сәүдәгәрләре генә барып җиткән. Марвази: «Болгарлар анда эт җигелгән чаналарга утырып, җирдә беркайчан да эреми торган кар көртләрен ерып баралар, кием-салым, тоз һәм башка товарлар китерәләр»,— дип яза. Ибн Батута сүзләренә караганда, мондый ерак арага сәяхәтне яхшы оештыра алган бай сәүдәгәр генә чыгып китә. Әллә ни ерак булмаган араларга исә чаңгыда барып сату иткәннәр. «Ә аларга (Йура халкына) юл беркайчан да кар китми торган җирдән бара,— дип яза әл-Гарнати.— Һәм кешеләр аякларына кияргә тakталар шомартып ясыйлар; һәр тактаның озынлыгы бер ба [1], ә киңлеге бер карыш. Мондый тактаның башбашлары җирдән күтәрелеп тора, ә урталыкта сәяхәтче аягын куя торган урын...»

Болгар сәүдәгәрләре төньяк халыклары өчен аларга бик кирәкле тимер әйберләр: уклар, сөңгеләр, кылычлар, гарпуннар һәм шулай ук тоз һәм кием-салым кебек көнкүреш әйберләре алып барганнар. Болгарлар төньякка XII гасырда тыныч юл белән, алыш-бирешне үстерү юлы белән үтеп кергәннәр. Болгар йорты турында әл-Гарнати: «Бу илдән югарырак исәпсез-сансыз халыклар яши, алар Болгар патшасына җан башыннан ясак түлиләр»,— дип сөйли. Күрәсең, бу хәбәрнең реаль нигезе бар. Алга таба әл-Гарнати түбән-

---

[1] Б а — өч метрга тигез.

дәгеләрне яза: «Ә аның (Болгарның) бер өлкәсе бар, андагы халык харадж[1] түли, алар белән Болгар арасында бер айлык юл, ул өлкәне Вису дип атыйлар. Икенче өлкә дә бар, анысын Ару диләр, анда кондыз һәм ас, менә дигән тиеннәр аулыйлар». «Ару өлкәсе» — Каманың уң як яры, ул үзенең бу исемен соңгы вакытларга тикле югалтмаган. Вису өлкәсенә яки иленә килгәндә исә, Марвази сүзләренә карап фикер йөрткәндә, ул «котыпка таба алардан (болгарлардан) егерме көнлек юл ераклыгында».

Әл-Гарнати хәбәр итүенчә, хазарларның төп байлыгы — тозны Болгарга корабларда ташыганнар. Анда инде сәүдәгәрләр тозны башка өлкәләргә илтеп сатканнар. Тозлыклар Саксиннан югарырак берничә көн барырлык арада, хәзерге Баскунчак тирәсендә булган. Тоз чыганаклары дәүләткә гаять зур файда китергәннәр һәм казнаны баета торган бу килергә сәяхәтчеләр һәрвакыт игътибар итәләр. Әл-Гарнатидан соң нәкъ йөз ел үткәч, бу төбәктән икенче бер сәяхәтче — Вильгельм де Рубрук үтеп китә. «Бу өлкәнең төньягында күлләр бик күп, аларның ярында тоз чыганаклары бар; аларның суы күлгә әләгү белән, боздай каты тоз хасил була; шул тозлыклардан Батый һәм Сартак күп табыш алалар»[2].

Көньяк-көнбатышта Болгар иле Азәрбайҗан белән сәүдә элемтәләре урнаштыра. Анда төньяк халыклары белән сәүдә иткәндә табыш китерерлек кылычлар ясаганнар. Көньяк-көнчыгышта Болгар белән Хәрәзм шаһларының мәнфәгатьләре кисешә. Төньяк-көнбатышта исә Владимир-Суздаль Русе белән дә шул ук хәл була.

Әл-Гарнатиның бу төбәкләрдәге кризис чорында акча әйләнеше турында сөйләгәннәре игътибарга лаек. «Аларда кулда кургаш йөри, сигез Багдад маны бер динар тора. Кургашны кисәкләргә турыйлар да, шуңа үзләре теләгән җимеш, икмәк һәм ит сатып алалар»,— дип яза ул. Археологик казу эшләре вакытында табылган кургаш кисәкләре дә аның бу сүзләрен раслый. Болгарда, Суарда, Биләрдә һәм Идел буеның башка шәһәрләрендә меңләгән шундый кургаш түгәрәкләр табылды. Бу түгәрәкләргә төрле бизәкләр төшкән, уртада тишекләре бар. Кургаш турау һәм кою, ихтимал, үзәкләштерелгән тәртиптә эшләнгәндер.

---

[1] Җир исәбеннән салым.
[2] Рубрук В. Путешествие в Восточные страны. М., 1957.

XII гасырның 80 нче елларында әйләнешкә, кургаш тәңкәләр урынына, Насир лид-дин хәлиф исеменнән (1180—1225) сугылган бакыр акчалар керә.

Кургаш тәңкәләр, чыннан да алыш-биреш чарасы булып хезмәт иткән хәлдә дә, вак базар сәүдәсенә генә хезмәт күрсәтә алган. Зур шәһәрдәге күләмле сәүдә операцияләре өчен исә әйләнеш чарасы буларак затлы металлар һәм, көмеш кытлыгы чорында, нигездә алтын кирәк булган.

Болгар шәһәрендә табылган һәм Татарстан Дәүләт музеена А. Ф. Лихачев коллекциясеннән кергән пыяла герләр әнә шул алтын әйләнешенә бер дәлил булып торалар. Алар барысы 8 данә.

Пыяла герләрнең кайчан кулланылганлыгын билгеләгәндә аларның авырлыгы ышанычлы нигез булып хезмәт итә. Алар 4,23 һәм 4,095 г лы мыскал системаларының өлешләрен (фракцияләрен) тәшкил итәләр. Әш шунда, монголларга кадәрге чорда куфи дирһәмнәре Болгарда 4,095 г лы мыскал исәбеннән, ә монгол явы килер алдыннан Насир лид-дин акчалары 4,235 (4,26) г лы мыскал нигезендә сугылган. Димәк, 4,095 һәм 4,235 г лы мыскал стандартлары XII гасырның икенче яртысында гына очраша алган. Дөрес, Идел буенда 4,095 г лы мыскал исәбеннән XII һәм XIV гасырларда да акча сугылган, ләкин 4,235 г лы мыскал белән алар XIII гасырда да, XIV гасырда да аралашмыйлар инде.

Алтын һәм көмеш коелмалар күмелгән хәзинәләр дә кыйммәтле металларның әйләнештә йөрүен раслаучы дәлил булып хезмәт итәләр. Мәсәлән, 1882 елда Биләр шәһәрендә алтын һәм көмеш коелмалар табыла. Ә 1895 елда Пермь губерниясенең Мөслим авылында алтын һәм көмеш әйберләр арасында 5 данә алтын борта (пластинка) табалар.

XI—XII гасырларга, ягъни «акчасыз чор»га караган шактый күп санлы көмеш коелма хәзинәләре дә табылды. Тулы кыйммәтле тәңкәләрне даими чыгаруны җайга салу өчен җитәрлек булмаса да, бу металл, күрәсең, әйләнештән тәмам юкка чыкмый. Идел һәм Кама буйларында, Вятка, Пермь һәм Казан губернияләрендә түгәрәк көмеш коелмалар — *бәлешләр* күмелгән уннан артык хәзинә билгеле.

Көмеш бәлеш күмелгән хәзинәләрнең үзенчәлеге

бар — алар гадәттә бөтен хәлдәге яки төрле зурлыкта итеп туралган көмеш кисәкләреннән торалар. Бу исә аларның кулда әйләнештә күп йөрүе турында гына түгел, бәлки бу чорда көмеш кисәкләреннән тыш әйләнештә вак акча булмавы турында да сөйли.

Бөтен хәлдәге һәм туралган көмеш коелмалар күмелгән хәзинәләрдә VIII—X гасырларга караган акчалар да, XII—XIII гасыр акчалары да табылмаган. Фәкать бер хәзинәдә генә X гасырга, акча сугылмаган чорга караган куфи дирһәмнәре билгеле. Моннан көмеш коелма хәзинәләр нәкъ менә шул акча сугылмаган XI—XII гасырларда әйләнештә йөргән дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

АКЧА СУГУ ЭШЕНЕҢ ТОРГЫЗЫЛУЫ

Идел буенда XII гасыр азагында — XIII гасыр башында, ягъни монголлар явы килгәнче акча сугу эшенең булу-булмавы нумизматика әдәбиятында катькат махсус тикшерелгән мәсьәлә. Шуңа күрә, монгол явы килер алдыннан Болгарда акча сугыла башлау турында ни дә булса сөйләгәнче, бу проблеманың тарихына кыскача гына тукталып үтәргә кирәк. Мәсьәләнең асылы шунда ки, Болгар шәһәрендә сугылган көмеш һәм бакыр акчалар арасында Багдад хәлифе Насир лид-дин исеменнән чыгарылганнары да очрый. Аларында суккан елы булмаса да, Х. М. Френ, Насир лид-дин исеменнән сугылуны нигез итеп алып, бу акчалар Болгарда 1180—1225 елларда, хәлиф хакимлек иткән чорда, чыгарылган дип саный. Ләкин моннан соң Урта Азиядә һәм Болгарда нинди дер бер Насир лид-дин исеменнән сугылган, ләкин үзләрендәге даталарга караганда, соңгырак чор тәңкәләре дә табылды. Х. М. Френ Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган Болгар акчаларында соңгырак чорга хас билгеләр юклыгын күрми кала алмаган. Бусы бик мөһим нәрсә, чөнки XIII гасырда, чингизидлар вакытында, Болгарда сугылган барлык акчаларда Кыпчак олысының яки бөек монгол кааның тамгасы тора. Ләкин Х. М. Френ, бу фактларга гына таянып, аларны монголларга кадәрге чорга кертә алмый һәм билгесез тәңкәләр санына кертә.

XIX гасырның танылган ориенталисты П. С. Савельев Х. М. Френның фикерен яклый һәм Насир лиддин исеме куелган Болгар акчалары монголларга ка-

дәрге чорда сугылган, дип исәпли. Ләкин, гәрчә кызыклы һәм дөрес күзәтүләр ясаса да, аның кулында ышанычлы фактлар булмаган. Болгарда «акчасыз чор»дан соң яңадан акча сугыла башлау мәсьәләсе хәл ителмичә калган.

Шулай итеп, узган гасыр нумизматлары каршына акчалардагы язуны өйрәнү нигезендә генә хәл итеп булмый торган мәсьәлә килеп баса.

Аны хәл итү өчен төгәл метрологик тикшеренүләр кирәк иде. Мондый тикшеренү исә, тәңкәләрнең бәһасен ачыклаудан тыш, датасыз акчаларның кайсы чорга караганлыгын да билгеләргә мөмкинлек бирә.

XIX гасыр рус ориенталистлары арасында үзенең җентекле һәм объектив хезмәтләре белән танылган А. Ф. Лихачев Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган Болгар акчаларының хронологиясенә беркадәр ачыклык кертүгә ирешә. Ул Насир лид-дин исеменнән сугылган тәңкәләрнең норматив авырлыгын 2,04 һәм 2,466 г нар арасында эзләргә кирәклеген әйтте, ә чингизидлар чыгарган акчаларның авырлыгы исә шактыйга кимрәк. Ләкин Мункә кааның 23 дирһәмнән торган акчалары һәм Ариг-Буга кааның 98 данә акчалары өчен А. Ф. Лихачев иң җиңел һәм иң авырлары турында гына метрологик мәгълүмат бирә. Бу, күрәсең, ул чор нумизматикасында метрологик тикшерү ысулларының камил булмавыннан килеп чыккандыр. Шуңа күрә А. Ф. Лихачев мөһим нәтиҗәләр ясамый. Насир лид-дин акчаларының авырлыгындагы аермага карата фикере дөрес булса да, А. Ф. Лихачев аны ахырына кадәр җиткерми, үстерми. Нигәдер аны XIII гасырның 90 нчы елларына караган акчаларда Тукта ханның мөселманча исеме (Насир лид-дин) аптыраштa калдыра. Ул аларда хәлифнең титулын күрсәткән «әмир әл-мөэмин» (хак динлеләр әмире) дигән сүзләр булмавына игътибар итә. Шулай да А. Ф. Лихачев Насир лид-дин хәлиф акчаларын, күп кенә билгеләренә карап, XII гасырныкы дип саный.

Урта гасырларда сугылган башка акчалардагы кебек үк, Насир лид-дин акчаларында да аларның бәһасе күрсәтелмәгән. Акча кыйммәтле металлдан, бу очракта көмештән булганлыктан, тәңкәнең кыйммәте аның авырлыгына карап билгеләнгән.

Авырлык — акчаның мөһим күрсәткече, һәм ул очраклы була алмый. Шуңа күрә акчаның авырлык нормасын билгеләү хәлиткеч әһәмияткә ия: ул Насир

лид-дин акчаларының сугылу нормасын даталары яхшы билгеләнгән башка акчалар белән чагыштырып, хронологик ачыклык кертергә мөмкинлек бирә.

Болгарда Насир лид-дин исеменнән көмештән һәм бакырдан сугылган берничә типтагы тәңкәләр билгеле. Барлык типтагы акчаларның алгы ягында түбәндәге язу бар: «Хак динлеләрнең хакиме эн-Насир әд-диналла».

Арткы яктагы язулардан түбәндәге ике төрен аерырга була: «Динар. Болгарда сугылган» һәм «Тормыш — мизгел; аны изге эшкә куллан».

Метрологик тикшерү күрсәткәнчә, Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган дирһәмнәрнең бер үзенчәлеге бар, алар көмеш болгар-татар акчаларының безгә билгеле булган башка чыгарылышларыннан сугылуның техник алымы белән аерылалар. Диаграммадан күренгәнчә, аларның авырлыгы бик төрле, шунлыктан гадәти график метод белән аларның нинди авырлык нормасы буенча сугылганлыгын ачыклау кыен. Аларны сукканда билгеле бер авырлыктагы көмештән билгеле бер сандагы тәңкәләр чыгарылган, ә аерым тәңкәләрнең авырлыгын тикшереп тормаганнар. Идел буенда көмеш тәңкәләр сугудагы мондый архаик ысул XIII гасырда һәм бигрәк тә XIV гасырда күзәтелми, ягъни алар XIII—XIV гасырларның акча системасына керә дә алмыйлар. Беркә хан (1257—1266) акчалары авырлык ягыннан бик төгәл һәм аларның Насир лид-дин акчаларының авырлыгы белән бернинди уртаклыгы юк.

Әлеге тәңкәләр 426 г көмештән (кадак) 200 данә итеп сугылганнар, ә аерым тәңкәләрнең авырлыгы үзара шактый аерылган, әмма монысы акча сугучы осталарны борчымаган. Шулай да 426 г көмештән нәкъ 200 данә тәңкә ясаганда, осталарның ничек эш итүенә карамастан, уртача авырлыктагы тәңкәләр күбрәк чыгарга тиеш булган. Күпсанлы тәңкәләрне үлчәү юлы белән, без моны ачыклый алабыз. Болар Насир лиддин хәлиф исеменнән чыгарылган бакыр тәңкәләргә дә бер үк дәрәҗәдә кагыла. Бакыр акчаларның авырлыгы ул кадәр җентекләп тикшерелмәгән дә, чөнки бакыр бәһале металл түгел. Ә көмеш тәңкәләрнең бу рәвешле «игътибарсыз» ясалуы исә көмеш акча сугу эшенең әлегә кабат җайга салынып җитмәвеннән дә килеп чыккандыр дип уйларга кирәк.

XIII гасыр башында, Урта Азияне монголлар басып алганга кадәр, Хәрәзмдә ратль дип аталган авырлык берәмлеге гамәлдә булган, һәм Хәрәзм шаһы Мөхәммәд (1200—1223) акчалары шул берәмлек исәбеннән сугылганнар.

Әгәр Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган Болгар акчаларын Беркә хан заманында чыгарылган дип уйласак, бу хәл фәкать соңгы хәлиф Мустасим үлгәч, ягъни 1257 елдан соң гына булырга мөмкин. Хәлиф исән чагында Беркә аның белән дуслык мөнәсәбәтләре саклый һәм Мустасимны җәзалап үтергән Хулагуга кискен каршы чыга. Хулагуның бүләкләрен һәм хәлифнең Багдадтагы казнасыннан җибәрелгән өлешне Беркә хан кабул итми, ә илчеләрне җәзалап үтерә. Димәк, фәкать 1257 елдан соң гына акчалар башка хәлиф исеменнән сугылырга мөмкин.

Насир лид-дин хәлиф исеменнән чыгарылган бакыр тәңкәләргә соңыннан Мункә каан титулы һәм тамгасы күрсәтелгән штемпель сугылган. М. А. Сайфеддини билгеләвенчә, Мункә каан хәлиф үлгән елны, ягъни 1257 елны вафат була. Шулай булгач, әгәр хәтта Насир лид-дин исеменнән Беркә заманында акча сугылган дип фараз итсәк тә, аларга кабатлап штемпель сугыла алмаган.

Насир лид-дин хәлиф исеменнән акча сугылуны очраклы тарихи вакыйга белән бәйләү мөмкин түгел. Акча, бигрәк тә бакыр тәңкәләр, шул кадәр күп чыгарылган ки, XIII гасырда Идел буенда Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган тәңкәләр саны белән чагыштырырлык күләмдә ясалган башка бакыр акчалар билгесез. Күп булганга, алар озак вакытлар буена сугылган, Идел һәм Кама буе шәһәрләрендәге сатуалу ихтыяҗын монголларга кадәрге чорда канәгатьләндереп килгән һәм аларны сугу монголлар басып кергәч кенә туктатылган дип фараз итәргә мөмкин. Әгәр дә аларны соңрак, Беркә хан заманында суккан булсалар, бакыр эквивалентка мондый ихтыяҗ туу яңа чыгарылышларны таләп иткән булыр, акчалар Насир лид-дин исеме белән генә чикләнмәс иде. Фактта исә Идел буенда бакыр акчаны күпләп җитештерү һәм акча әйләнешендә бакыр һәм көмеш тәңкәләрнең яхшы көйләнгән нисбәте йөз ел диярлек вакыт үткәч, XIV гасыр башында, 1310—1311 елгы акча реформасыннан соң гына барлыкка килә. Бакыр тәңкәләргә кабаттан штемпель сугылу бу мәсьәләнең кайбер якларын гына

характерлый. Насир лид-дин хәлиф исеменнән чыгарылган тәңкәләргә Мункә каан исеме язылган штемпель басу ул тәхеткә менгәч, ягъни 1251 елдан соң гына башланырга мөмкин. Бу чорга кадәр Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган иске тәңкәләр әйләнештә йөри алган. Бакырга яңадан штемпель басу белән бер үк вакытта Мункә каан исеменнән көмеш акчалар да чыгарылган, чөнки бакыр тәңкәләр вак акча ролен генә уйнаганнар. Яңа штемпель басылу бакыр акчаларның курсы инде башка булуы, аның Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган көмеш һәм бакыр тәңкәләр арасындагы нисбәткә бәйле булмавы турында сөйли. Хәлиф исеменнән чыгарылган дирһәмнәр, күрәсең, әйләнештә йөрмәгән, чөнки хәзинәләрдә Мункә каан акчалары арасында да, Беркә хан акчалары арасында да очрамый. Димәк, әлеге тәңкәләрнең көмеш акчалар арасында юклыгын аларның Мункә вакытында әйләнештә булмавы белән аңлатырга кирәк.

X гасырда Болгарда сугылган куфи тәңкәләрендә, хәлиф исеменнән тыш, Болгар әмиренең дә исеме күрсәтелгән. «Акчасыз чор»дан соң, Насир лид-дин исеменнән чыгарылган беренче тәңкәләргә Болгар әмиренең исеме ни өчен куелмагандыр — монысын әйтүе кыен. XIII гасырда Болгар йортындагы политик тормыш безгә билгесез. Ихтимал, хазарлардагы кебек, биредә дә ике хаким булгандыр. Соңгырак чорларда Казанда сәет кулында ханга караганда да зуррак власть тупланиуын искә алсак, Болгарда политик властьның рухани кеше кулында булу ихтималы да бар. Һәрхәлдә, Рәшид әд-дин хәбәр иткәнчә, Болгарга Батый гаскәре килгәндә анда бер генә әмир булмаган, гаскәрне фәкать ике юлбашчы: Баян белән Җик каршы алганнар һәм баш органнар. Алар да тиздән баш күтәрәләр, ләкин озакламый җиңелүгә дучар булалар.

КРИЗИСТАН ЧЫГУ

Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган бакыр акчаларны тикшерү шул ук хәлиф исеменнән сугылган көмеш тәңкәләр Болгарда «акчасыз чор»дан соң чыгарылган беренче акчалар түгел дип фараз итәргә мөмкинлек бирә. Көмеш һәм бакыр нисбәте төгәл билгеләнгән акча әйләнеше әзер килеш тумаган. Моңа кадәр ниндидер башлангыч чор булып, ул вакытта акча бик үк оешып җитмәгән тәртиптә чыгарылырга,

акча әйләнешенең интенсивлыгы да кимрәк булырга тиеш.

Бакыр акчаларны тикшерү күрсәткәнчә, алар үзләренең зурлыгы һәм авырлыгы ягыннан ике төрле категориягә кискен аерылып торалар. Ике төр акчалар да Насир лид-дин хәлиф исеменнән, ләкин төрле штемпель белән сугылганнар, бу исә аларның төрле вакытта чыгарылуын күрсәтә. Әгәр диаметрлары зуррак экземплярлар булуны очраклы тайпылыш белән генә аңлатып булса, без кечерәк диаметрлы тәңкәләр арасында зурракларының штемпеле белән сугылганнарын да күрер идек (акчага зур штемпельнең бер өлеше генә төшкән булыр иде). Ләкин без андый акчаларны белмибез. Кечерәк диаметрлы акчалар үз зурлыкларына туры килгән штемпель белән сугылганнар.

Өстәвенә Насир лид-дин исеменнән сугылган Болгар акчаларының бу ике төре арасындагы аерма күзгә бәрелеп тора. Татарстан дәүләт музееның А. Ф. Лихачев төзегән нумизматик материал исемлегендә бер зур акча түбәндәгечә тасвир ителә: «Гадәттән тыш зур булуы белән аерылып торучы экземпляр. Бакыр.» Безнең карашыбызча, авыррак һәм зуррак диаметрлы акчаларны борынгырак чорныкы (хәлиф хакимлек иткән еллар чигендә) дип, атап әйткәндә, XII гасырның азагында яки XIII гасырның беренче унъеллыгында, ягъни Насир лид-дин хәлиф (1180—1225) исеменнән көмеш тәңкәләр чыгарыла башлаганчы сугылган дип санарга кирәк.

Җиңелрәк һәм кечерәк бакыр акчаларның сугылу һәм әйләнештә йөрү вакыты шик-мазар уятмый. Алар чираттагы хронологик чорга карыйлар һәм Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган көмеш тәңкә типларын кабатлыйлар һәм, безнең фикеребезчә, алар белән бергә кулда йөргәннәр, чөнки вак акча буларак хезмәт иткәннәр. Алар эреләренә караганда ике тапкыр җиңелрәк.

Шулай итеп, XII гасыр ахырында — XIII гасыр башында әйләнешкә кургаш акчаларга алмашка эре бакыр акчалар керә. Бакыр акча сугу шәһәр базарларының алмашу чараларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен зур әһәмияткә ия булса да, кризистан алып чыкмый әле, чөнки әйләнештә көмеш тәңкәләр булмый.

Аннары көмеш дирһәмнәр һәм вак бакыр акчалар чыгарыла. Гадәти бакыр акчаларның билгеле бер микъ-

дарын динар дип атаганнар[1]. Беренче дирһәмнәр динар буларак исәпләнгән. Кайбер көмеш тәңкәләрдә динар дигән язу очравы игътибарга лаек (мәсәлән: «Динар. әл-мал Болгари» — Динар. Болгар акчасы).

Көмеш тәңкәләр сугуны яңадан җайга салу инде көмеш кризисыннан чыгу турында сөйли. Көмеш акчаның әйләнешкә күпләп керүе товар-акча мөнәсәбәтләрен җанландырып җибәрә һәм Идел буеның экономик үсешенә ярдәм итә.

Көмеш кризисыннан чыгу мәсьәләсе безнең каршыга: XIII гасыр башында Болгар акча сугу сарае ничек итеп көмеш тәңкәләрне регуляр тәртиптә чыгаруны оештыра алган? — дигән сорауны куя.

XII гасыр ахырына Болгар йорты югары үсешкә ирешә һәм, шәһәрләрнең саны һәм зурлыгына карап фикер йөрткәндә, Көнчыгыш Европада зур һәм алга киткән дәүләткә әйләнә. Эчке сәүдәне генә түгел, тышкы сәүдәне дә оештырган күпсанлы шәһәрләрдән казнага ясак һәм салымнар рәвешендә көмеш коелмалар — бәлешләр кереп торган, шулар акча сугуны яңадан башлап җибәрү өчен чимал базасы булып хезмәт иткәннәр. Ләкин андый база, фәкать сәүдә әйләнешләренә генә исәп тотса, артык ныклы була алмый, чөнки көмеш кризисы күрше илләрне дә читләтеп узмаган.

Кыскасы, XIII гасыр башында Идел буенда көмеш акчаның масса-күләм сугылуын Болгар дәүләтенең экономик яктан көчәюе һәм XII гасыр ахырына аның дәүләт чикләре киңәюе белән аңлатырга мөмкин. Түгәрәк көмеш коелмалар — бәлешләр табылган хәзинәләр топографиясе аларның Идел, Кама һәм Урал буйларында әйләнештә йөрүен генә түгел, бәлки шушында ясалуын да күрсәтәләр. Димәк, Урал тауларының чимал (көмеш) ресурслары биредәге базарларның көмешкә булган ихтыяҗын канәгатьләндерүдә мөһим роль уйнаган дип уйларга була.

Шунысын да әйтеп китик, Уралдагы борынгы шахталар һәм базлар патша чиновникларына затлы металл эзләү, штольнялар һәм шахталар кора башлау өчен төп ориентирлар булып хезмәт иткәннәр. Затлы металл эзләү эшләре Уралда XVII гасырда башлана. Петр I вакытында инде Урал шахталары көмеш бирә

---

[1] Динар — алтын акча. Бу очракта ул исәп берәмлеге булып хезмәт иткән.

башлый һәм элек үзенең чимал базасы булмаган Россиядә акча сугу эшен алга таба үстерү өчен алар шактый әһәмияткә ия булалар.

Патша Алексей Михайловичның кабинетында аның: элекке заманда татарлар алтын-көмешне каян алганнар? дигән соравына 1670 елгы җавапның күчермәсе сакланган. Бу документта «Уфа дистриктында таш таулар артында Уфа, Гадай һәм Җаек елгалары тамагында, тауларда бихисап алтын һәм көмеш байлыгы бар, әүвәлге заманнарда борынгы Себер татарлары һәм калмыклар ул таулардан алтын һәм көмеш рудалары чыгарганнар һәм эреткәннәр; әле хәзер дә шул эретү мичләренең һәм базларның эзләре күренә...» — дип язылган.

Акча сугу өчен көмешнең таулардан чыгарылуы шуннан да күренә: Кыпчак олысы төзелгәннән соң, Болгарда акча чингизидлар исеменнән сугылган, ләкин көмеш һәм бакыр тәңкәләрне күпләп сугу XIII гасырларга, ягъни монгол ханнары кулында талап җыелган көмеш аеруча күп вакытка түгел, бәлки XIV гасырга — Үзбәк хан тәхеткә утырып, Көнбатыш Себер олыска кушылган чорга туры килә.

БОЛГАРДА АКЧА ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ ҺӘМ АКЧА ИСӘБЕ

Монголларга кадәрге Идел буенда акча терминологиясе турында фикер йөртү өчен, тәңкәләрдәге легендаларга (язуларга) һәм язма чыганакларга таянырга мөмкин.

Дөрес, язма чыганакларда Идел буендагы акча әйләнеше һәм акча системасы начар яктыртылган. Бу мәсьәләләргә кагылышлы күпчелек мәгълүматларны без гарәп һәм фарсы сәяхәтчеләренең һәм тарихчыларының хәбәрләреннән алабыз.

XII—XIV гасырларда Идел буендагы акча исәбе һәм бигрәк тә акча терминологиясе борынгы татар язма истәлекләрендә шактый тулы чагыла, ул истәлекләр исә башка телләргә тәрҗемә ителмәгән һәм нумизматик әдәбиятта файдаланылмыйча килә иде. Бу истәлекләрнең язылу вакыты яхшы билгеле, чөнки гадәттә язу датасы әсәрнең соңгы юлларына өстәлгән була. Аларда еш кулланылган акча терминнары һәм акча исәбе ул заманның акча әйләнешен җитәрлек кадәр тулы чагылдыралар. Кулланылган акча терминнарын күзәтү күрсәткәнчә, гарәп теленнән алынган

төп, рәсми терминнардан тыш (алары тәңкәләрнең үзләренә сугылган), көнкүрештә җирле атамалар да йөргән.

Монголларга кадәрге чорның акча-үлчәү системасын тасвирлау өчен борынгы татар шагыйре Кол Галинең һиҗри 609 елда (1212) язылган «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын күздән кичерик.

Гәрчә XIV гасыр әсәрләре белән чагыштырганда, поэмада акча терминнары азрак булса да, анда сәүдә һәм акча турында бик күп сөйләнә. Ләкин поэмада кулланылган «мал» (акча, байлык), «алтын» (акча һәм исәп-хисап берәмлеге), «кызыл алтын» (ягъни алтын металлының үзе), «ярмак» (акча берәмлеге) һ. б. терминнар Идел һәм Кама буйларында акча исәбе һәм аның төп атамаларының монгол ханнары исеменнән күпләп акча сугыла башлаганчы шактый элек барлыкка килүен күрсәтәләр.

Мал һәм **ярмак.** Поэмада «мал» термины хәзерге заманның «акча» сүзенә тәңгәл мәгънәдә бик еш кулланыла. «Мал» термины гомумән байлыкны белдергән очракта гадәттә ул башка берәр сүз белән бергә кулланыла (мал һәм хуҗалык, мал һәм хәзинә һ. б.). Шунысы кызык, Болгарда Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган кайбер тәңкәләрдә «әл-мал Болгари» дигән язу бар. Без аны «Болгар акчасы» дип тәрҗемә итәбез. Бу терминның акча язуында да һәм XIII гасыр башларына караган әсәрдә дә мәгънәдәш булуы очраклы түгел, дип уйларга кирәк.

Әсәрдә очрый торган «ярмак» термины «ярылган акча», «вак акча» мәгънәсендә. Бу уңайдан Ибн Гардизиның (XI гасыр) Кама болгарлары дирһәмне кисәкләргә бүләләр һәм бу кисәкләр мөстәкыйль акча берәмлеге булып исәпләнгән, дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр. Шулай итеп, «мал» термины кебек үк, «ярмак» термины да борынгырак чорда килеп чыккан дип фараз итәргә мөмкин.

Поэмада ярмакның арзан булуы телгә алына. Мәсәлән, сәүдәгәр кол сатып алганда сатучыга:

> Ничә бәһа алырсыз, әйдең имди.
> Вә ләкин кулымда һич алтыным юк.
> Терлек белән комачым бар, атласым күп.
> Ярмагым бар берничә, кыйммәте юк,—

ди.

Соңрак исә аның кулында 18 ярмак булганлыгы

ачыклана. XIV гасырның беренче яртысында Идел буенда 18 дирһәмгә ат алып булган. XIII гасыр башларында, ягъни поэма язылган вакытта, «акчасыз чор»дан соң көмеш кытлыгы сизелгән чорда 18 көмеш тәңкә шактый зур сума исәпләнгән. Мәсәлән, «Игорь явы турында җыр» әсәреннән (XII гасыр ахыры) иң арзан бәяле колны бер «ногата»га алып булуы күренә. Шуңа күрә безгә поэмада телгә алынган «ярмак» көмеш тәңкәне түгел, бәлки бакыр акчаны белдергән дигән фикер нигезлерәк тоела.

Динар һәм алтын. Көмеш тәңкәләрнең исеме аларның үзләренә язылган. Насир лид-дин хәлиф исеменнән сугылган кайбер типтагы көмеш акчаларда, инде әйтеп киткәнебезчә, «Динар. Болгарда сугылган» дигән сүзләр бар. Билгеле булганча, Көнчыгышта XIII гасырга кадәр «динар» сүзе алтын акчаларда гына булган. Ләкин биредә хата юк. Кайбер башка типтагы көмеш Болгар тәңкәләрендә дә динар сүзе очрый, мәсәлән: «Динар. әл-мал Болгари». Бу очракта динар, күрәсең, исәп берәмлеге булып хезмәт итә. Бакыр акча әйләнеше чорыннан соң, көмеш тәңкәләрдә аларның ничә бакыр тәңкәгә торулары күрсәтелергә тиеш булган һәм «динар» сүзе нәкъ әнә шул күрсәтмәне биргән дә. Бакыр тәңкәләрдә — XIV гасырның беренче чирегенә караган Үзбәк хан пулларында, мәсәлән, «16 пул — дәник» дигән язу бар. Үзбәк хан дирһәме 2 дәник авырлыкта булгач, бакыр акчадагы язуны укучы кеше 32 пулның бер дирһәмгә тигез булуын аңлаган. Ә Болгарда сугылган көмеш акчалардагы «динар» терминына килгәндә исә, алар белән эш гадирәк булган, чөнки моңа кадәр исәп берәмлеге булып хезмәт иткән «динар»ның яки җирле терминология буенча «алтын»ның ничә бакыр тәңкәгә бәрабәр икәнлеге һәркемгә билгеле булган. Шунысы игътибарга лаек, билгеле бер сандагы бакыр тәңкәләрне исәпләү берәмлеге буларак «динар» XIII гасыр башында Азәрбайҗанда да кулланыла.

«Алтын» сүзе «Кыйсса-и Йосыф»та металл мәгънәсендә түгел, бәлки я «көмеш тәңкә» мәгънәсендә кулланыла, яисә исәп берәмлеген белдерә. Мәсәлән, алтын савыт «400 алтын» дип бәяләнә. Ләкин «алтын»ның вак акчага ничек алмаштырылганлыгын әсәрдән аңлавы кыен. Әйткәнебезчә, поэмада саф алтын телгә алынганда һәрвакыт «кызыл» сүзе өстәлә («кызыл алтын ат» — ягъни алтыннан ясалган ат, «кызыл алтын

кадах» — алтыннан ясалган касә, «кызыл алтын беләзек» — алтын беләзек һ. б.).

Поэмада «динар» сүзе дә очрый, ләкин ул алтын тәңкәне белдерүдән бигрәк, «алтын» сүзе кебек үк, көмеш тәңкә яки исәп берәмлеге дигән төшенчәгә туры килә. Мәсәлән, гүзәл Йосыфны күрергә дип сарайга килгән һәркемнән патша берәр динар түләтә. Шушы очрактан тыш, әсәрдә динар сүзе телгә алынмый, халык исә сарайга 10 көн буена агыла. Ләкин акча исәбе булып «алтын» йөри. Унынчы көнне һәркем 10 алтын алып килә, ягъни динар белән алтын синоним буларак кулланылганнар. «Динар» терминын көмеш тәңкә мәгънәсендә һәм «алтын»ның синонимы итеп куллану, безнең фикеребезчә, очраклы гына түгел. Насир лид-дин исеменнән сугылган көмеш акчаларда да «динар» сүзе бар һәм динар татарча алтын дип йөртелгән.

Борынгы татар поэмасы «Кыйсса-и Йосыф»ка, дирһәмнәрдә очраган терминнарга, шулай ук безгә кадәр килеп җиткән тәңкәләргә нигезләнеп, без монголларга кадәрге чорда — Насир лид-динның хәлифлек иткән еллары белән чикләнгән һәм беренче Болгар акчалары аның исеменнән сугылган вакыттагы акча исәбенең һәм акча терминологиясенең түбәндәге картинасын торгыза алабыз.

«Акчасыз чор»дан соң XII гасыр азагында яки XIII гасырның башында Болгарда бакыр акчалар — якынча 7,0 г авырлыктагы ярмаклар гына әйләнештә йөргән һәм аларны 426 г авырлыктагы 60 данәлек «өем» исәбеннән сукканнар. Бу уңай белән XIII гасырның башында ук «Кыйсса-и Йосыф»та кулланылган «алтын» терминын искә төшерү урынлы. «Алтын» сүзе металлны гына түгел, бәлки микъдар берәмлеген дә белдергән, һәм аның бу мәгънәсе татар теленең диалектларында сакланып калган. Шулай итеп, алтмыш эре тәңкә рәсми телдә «динар» яки җирле терминологиядә «алтын» дип йөртелгән. Ихтимал, «алтын»ның килеп чыгышы тагы да борынгырактыр. X гасырда саманидларның Болгарда әйләнештә йөргән куфи тәңкәләре уртача 3,49 г авырлыкта булган, ягъни 60 акча 204,75 г авырлык исәбеннән, ә 120 данәсе стандарт 409,5 г авырлык исәбеннән сугылган.

Икенче чорда көмеш «мал» (тәңкә) сугыла. Алардагы терминнарга карап фикер йөрткәндә, «мал»лар динар буларак исәпләнгән, ягъни алтмыш бакыр акча-

га бәрабәр булып йөргән (дөрес, бакыр акчалар инде ике тапкыр җиңеләеп өлгергәннәр). 426 г көмештән 200 көмеш тәңкә сукканнар. Ике көмеш тәңкәгә 120 җиңел бакыр акча яки «сом» (426 г) туры килгән. «Сом» (бөтен) сүзе «Кыйсса-и Йосыф»та очрамый. Ләкин XIV гасырда сомның фракциясе булган ярмак һәм алтын куллану (XIV гасырның беренче яртысында 1 сом 20 алтыннан — динардан, 120 ярмактан — дирһәмнән торган) бу термин монголларга кадәрге чорда да булган дип фараз итәргә юл ача.

Шул рәвешле, XII гасыр азагында — XIII гасыр башында Болгарда тәңкә сугыла башлау көмеш кризисыннан чыгуны күрсәтә, һәм акча сугу эшенең яңадан торгызылуы XI—XII гасырларда Идел буеның бөтен социаль-экономик үсешенең нәтиҗәсе булып тора.

Бишенче бүлек

XIII ГАСЫРНЫҢ УРТАСЫНДА ҺӘМ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ИДЕЛ БУЕНДА АКЧА ҺӘМ АКЧА-ҮЛЧӘҮ СИСТЕМАСЫ

> **Сүбәдәй.** Бу шәһәр безгә бик озак каршы торды — әллә никадәр огланнарыбыз һәлак булды һәм яраланды. Мин аның халкын кырып бетерәм.
>
> **Елюй Чу-цай.** Әгәр халыксыз җир алсаң, аны ничек файдаланмак кирәк!.. Әгәр халкын кырып бетерсәң, һичбер табышы булмас, димәк, көч юкка гына түгелә!
>
> *Кытай чыганагыннан*

КЫПЧАК ОЛЫСЫ БАРЛЫККА КИЛҮ

Идел буеның акча системасында XIII гасырның уртасында һәм икенче яртысында акча сугуда үзенчәлекләр бар, аларны бу төбәкнең экономик һәм политик тарихындагы кайбер күренешләр китереп чыгарган. Идел буенда XIII гасыр — Кыпчак олысы яки Ак Урда (Алтын Урда) төзелгән вакыт. Менә шушында Идел буе тарихы ике чорга: монголларга кадәрге һәм монголлар чорына бүленә дә.

Тарих сәхифәләрендә монголларны «татар» яки «монгол-татар» дип атау шактый еш очрый. Бу атаманың каян һәм ничек килеп чыкканлыгын берничә сүз белән генә аңлатып үтик.

Безнең эрага кадәр үк Кытай хроникаларында махсус иероглиф белән язылган «татар» сүзе очрый. Ул «татань» дип укыла, ә хәзерге галимнәр аны «дада» дип тә укыйлар.

Чыганаклардан күренгәнчә, дада дип аталган кабиләләр этник яктан бик төрле булганнар. Аеруча борынгы чыганакларда ул тунгус (манчжур) кабиләләре атамасы булганга охшый, ә X—XI гасырларда шундый исемле төрки кабилә дә булган. XII һәм бигрәк тә XIII гасырларда Кытай чыганаклары дада, ягъни «татар» дип бары тик монголларны гына атыйлар.

Әлбәттә, мондый терминологик чуарлыкның үз сәбәбе бар. Хикмәт шунда, дада ул этноним түгел, бәлки кушамат кына. Кытайча ул «кырагай» мәгънәсендәге сүз. Безнең «кырагай» сүзе кытай «дада»сына тулысынча тәңгәл килә, чөнки «дада» — күчмә дигән сүз генә түгел, бу сүздә беркадәр кимсетү дә төсмерләнә. Кытайлар монголларны мэн-да (монгол-татар), ягъни «монгол-кырагай» дип, яки бер сүз белән «дада» (татар) дип кенә атаганнар. Кытай чыганакларын яхшы өйрәнгән монгол тарихчысы Чулууны Далай сүзләрен китерик: «Юань чорына караган тарихи әсәрләрдә «мэнчу жень» (монгол) һәм тагы да ешрак «да-да» (татар) этнонимнары очрый. Юань чорында кытайлар, монголларны кимсетеп, күбесенчә татар дип атаганнар. Алар кулланган «татар» атамасы «кыргый», «тупас» дигән мәгънәгә ия. Мәсәлән, кытай китапларында еш кына «татар дәһшәте», «татар золымы», «барча татарларны кырып салыйк!», «татарларны куыйк!» кебек тәгъбирләр очрый. Юань чорында кытай халкы арасында киң таралган «татар» этнонимы татар нәселеннән булган күчмә халыкны түгел, бәлки барлык монголларны аңлаткан» (Чулууны Далай. Монголия в XIII—XIV веках. М., 1983).

Шулай итеп, монгол яуларында нинди дә бер аерым татар кабиләләре катнашмаган, «татар» дип монголларны атаганнар. Бу факт тарихта күптән ачыкланган (Куликовская битва. М., 1980).

Монгол яулары башлангач тиз арада Европага «монгол» мәгънәсендәге «татар» атамасының үтеп керүен галимнәр XIII гасырда Кытай белән Европа илләре арасында шактый тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре урнашу белән аңлаталар. Күрәсең, көнбатыш халыкларына монгол яулары турында: «Татарлар килә!» дип шом салучылар сәүдәгәрләр булгандыр.

Тарихи яктан дөрес булмаган, ясалма монгол-татар (ике халык мәгънәсендә) атамасы узган XIX гасырда гына, бу проблемаларны үзе дә тирән аңлап бетермәгән П. Наумов хезмәтләрендә очрый башлый.

Шунысы игътибарга лаек, шул ук тарихчылар хезмәтеннән файдаланган К. Маркс, даһи сизгерлеге аркасында, әлеге терминнарны дөрес кулланган. Мәсәлән, ул «Эчке низагларына да карамастан, **монголлар** үз биләмәләрен **Казан Болгариясе** чикләреннән дә арырак җәелдерәләр»,— дип яза (ассызыклау *К. Марксныкы*).

Монголлар Төркстанны басып алгач, Каспий диңгезенең көньяк яры буйлап юл ярып, Дон буе далаларына килеп чыгалар һәм Көнчыгыш Европа халыклары өстенә ябырылалар. Рус дружиналарының һәм кыпчакларның 1223 елда Калка буенда монголларга каршы батырларча сугышуы тарихка яхшы билгеле. Монголлар, һөҗүмнәрен дәвам итеп, шул ук елны Идел буена бәреп керәләр һәм шунда хазар-болгар гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителәләр [1]. Монголларның болай хурлыклы төстә җиңелгән очраклары бик сирәк булуын әйтергә кирәк. Бу хәл Идел буеның Кыпчак олысы оешканга кадәр үк зур потенциаль мөмкинлекләргә ия булуы турында сөйли. Революциягә кадәрге традицион тарих фәне исә Идел буеның экономик һәм культура үсешен һәрчак Ак Урда (Алтын Урда) төзелү белән бәйләп килде.

Монголлар икенче яулары вакытында Идел буе, Дешт-и Кыпчак яки Дешт-и Хазар кабиләләрен бик авырлык белән генә җиңәләр. Бу вакыйгалар тасвирланган тарихи чыганакларда кыпчакларның монголларга аеруча нык каршы торулары турында сөйләнә. Кыпчаклар, монголлар кебек үк, дошманга каршы менә дигән атлы гаскәр куя алганнар, ә атлы гаскәр ул заманнарда төп көч булып саналган. Шулай да кыпчаклар җиңелгәннәр, чөнки мәкерле һәм аяусыз дошман хәрәкәтләренә каршы көрәштә алар оешканлык һәм бердәмлек күрсәтә алмаганнар.

Бачман дигән берәүнең монголларга каршы батырларча көрәшүе тасвирланган тарихи хикәягә карап фикер йөрткәндә, илбасарлар Идел буенда каты каршылыкка очраганнар. Кытай елъязмасы Юань-ши хәбәр

---

[1] История Татарии в документах и материалах. М., 1957, 41 бит.

итүенчә, хан угыллары Мункә һәм Батый гаскәрләре берләшкәч кенә Куантенгиз (Каспий диңгезе) буенда баш күтәргән Бачманны җиңә алганнар. Үзенең кыю һөҗүмнәре белән монголларга бик зур зыян китергән Бачманны әсир иткәч, Мункә аңа тезләнергә боерган. «Тезләнергә мин дөя түгел»,— дип җавап биргән горур Бачман [1]. Бу җавабы өчен халык юлбашчысын Мункә каршында кылыч белән икегә ярганнар...

Тәхет өчен көрәшкәндә, монгол династиясе ханнары, җирле халык һәм руханилар арасында абруй казанырга тырышып, ислам дине кабул иткәннәр. Үз көчләренә ышанган вакытта исә алар динне санга сукмаганнар, мәҗүси булып калганнар, Чыңгыз хан фәрманнарын мөселман дине кануннарыннан өстен күргәннәр.

Монгол ханнары үзләренең күчмә урдаларында (станнарында) яшәгәннәр һәм төрле шәһәрләргә баскакларын җибәрә торган булганнар. Шуңа күрә бүгенге тарихчылар, атамаларны дөрес файдаланып, «татар золымы» дип түгел, ә «урда золымы» (ордынское иго) дип язалар. Урда золымы рус халкының гына түгел, Идел буе халыкларының да үсешен тоткарлаган.

Монголлар төрки халыклар белән әле Монголиядә үк дошман булганнар һәм аларны бердә коллыкка төшерергә яки юк итәргә омтылганнар. Мәсәлән, 1221 елны Сәмаркандны алгач, алар төркиләрне башка әсирләрдән аерып алганнар һәм, монголларда кабул ителгәнчә, утыз меңнән артык кешене кырганнар... Рәшид-әд-дин: «...бүген барлык төрки кабиләләрнең Чыңгыз ханның колы һәм гаскәре булуына үз күзләрең белән күреп ышанасың»,— дип яза.

Монголлар Дәшт-и Кыпчакны, Хәрәзмне, Төньяк Кавказны, Кырымны, Болгарны яулап алгач, нигездә төрки халыклар яшәгән һәм зур экономик мөмкинлекләргә ия булган Идел буе шушы гаять зур дәүләтнең үзәгендә кала.

Бу факт, күрәсең, Кыпчак олысының көчәюен тәэмин итеп, монгол династиясе ханнарына Көнбатыш Европа илләре белән генә түгел, башка монгол дәүләтләре белән, атап әйткәндә хулагуидлар Ираны белән, йөз ел буена диярлек сугыш алып барырга мөмкинлек биргән. Рәшид әд-дин Хулагу белән Беркә арасында

---

[1] Дөягә атланыр алдыннан, аңа: «Тезлән!» дигән команда бирәләр.

бердәмлек булмау һәм Кыпчак олысы гаскәре Иранга басып керү аркасында, монголлар Мисырны яулап ала алмаганнар, дип яза.

Әйтергә кирәк, хәзергә кадәр бу дәүләтне төрлечә атап йөртәләр. Узган гасыр рус ориенталистлары хезмәтләрендә ул Алтын Урда, Жучи олысы, Батый йорты, Кыпчак патшалыгы рәвешләрендә очрый. К. Маркс, атаманың эчтәлегенә игътибар итеп, аны «Кыпчак патшалыгы» дип атый. Язма истәлекләрдән күренгәнчә, чынлап та, күчмә кыпчаклардан башка, Хәрәзм, Кырым яки Идел буе шәһәрләре халкы сөйләше төрки телләрнең кыпчак группасына карый.

Кыпчаклар үзләре бу дәүләтне «Кыпчак» яки «Кыпчакбашы» дип йөрткәннәр. «Ак Урда» атамасы исә дәүләткә түгел, бәлки ханның станына, резиденциясенә кагылган. Һәр ханның үз урдасы булган. Монголиядә үзенең урдасында утырган баш хан «каан» дип аталган. Фарсылар үз ханнарының станын Урду-и Заррин, ягъни Алтын Урда дип, кытайлар — Цзинь-Чжан, ягъни Алтын Чатыр, ә төрки халыклар Ак Урду дип атаганнар. «Ак» сүзе борынгы төрки телдә «бөек», «затлы», «хәзинә» дигән мәгънәгә ия.

Тарих төгәллекне ярата. Бу дәүләтне күчеп йөргән хан станы дип кенә күз алдына китерү дөрес булмас иде. Ул югары утрак культурасы (антик чордан башлап!) булган Хәрәзмне дә, монголларга кадәр үк 200 ләп шәһәре булган Болгарны һәм, гомумән, Идел буен да, автономиясен саклап калган рус князьлекләрен дә, ягъни урда ханнары ясак җыйган барлык төбәкләрне үз эченә алган.

Олыс төзелгәч, Идел буенда иске шәһәрләр торгызыла, яңалары калкып чыга һәм акча сугу эше дә яңадан җайга салына.

Кыпчак олысының барлыкка килү сәбәпләре шул замандагы фикер ияләрен дә кызыксындырган. Фарсы тарихчысы Җүзҗани: «Чыңгыз ханның өлкән улы Жучи Кыпчак җиренең һавасын һәм суларын күргәч, бөтен дөньяда моннан да күркәмрәк җир, моннан да сафрак һава, мондагыдан да татлырак су, моннан да иркенрәк тугайлар һәм көтүлекләр булуы мөмкин түгел дигән уйга килә»,— дип яза. Ләкин аның улы Батый яудан соң кыпчак җирләре саналган Төньяк Казахстанда — атасы үзенең Алтын Урдасы белән күченеп йөргән җирләрдә дә, Кырымда да, яки Төньяк Кавказда да калмый, үзенең гадәттән тыш зур дәү-

ләтенең үзәге итеп Идел буен сайлый. Бу очраклы гына бер нәрсә түгел: Батый да, Жучи кебек үк, Чыңгыз ханның басып алган илләрдә шәһәрләрне көл итү һәм халыкны кырып бетерү стратегиясен хупламый. Идел буеның (һәм Русь иленең дә) тарихыннан күренгәнчә, ул мондый яулардан соң, әкрен генә булса да, аякка баскан һәм үсешен дәвам иттергән. Идел буе яңадан күп санлы шәһәрләре, ныклы акча системасы һәм сәүдәсе булган эре экономик үзәккә әйләнә. Әгәр Түбән Идел күчмә тормыш алып бару өчен барлык шартларга ия булса, Урта Иделдәге күпсанлы шәһәрләр ханны ук-җәя ясаучы корал осталары, алтынчылар белән генә түгел, ясак рәвешендә акча белән дә тәэмин итеп торганнар. Мөселман сәүдәгәрләре, сату-алу эшенә уңай шартлар тудырган Батый ханны олылап, Саин (рәхимле) хан дип атый башлаганнар. Табигый, буйсындырылган илләрнең экономик үсешенә булышырга ханны һәм аның варисларын рәхим-шәфкать түгел, бәлки экономик файда артыннан куу мәҗбүр иткән.

Җиңүгә ирешкәч, монголлар, күбәүләр уйлаганча, Идел буена күчеп утырмаганнар һәм ниндидер өр-яңа дәүләт тә төземәгәннәр, бәлки Кытайда, Иранда, Хәрәзмдә һәм башка илләрдәге кебек үк, җирле халыкларны буйсындырып, коллыкка төшергәннәр, төбәкнең политик һәм экономик тормышын үзләренчә үзгәртеп кенә корганнар. Рәшид әд-дин сүзләренә караганда, Идел буенда монголлар, үзләре буйсындырган башка илләрдәге белән чагыштырганда, күп тапкырлар азрак булганнар. Мәсәлән, Иранда да, Кытайда да әле XIII гасыр азакларында һәм XIV гасыр башларында монгол кабиләләре күчеп йөргән аерым төбәкләр булган.

Чыңгыз хан үзенең өлкән улы Жучига, Кыпчак илен яулап алу өчен, 1000 әр сугышчы башында торган дүрт әмирне бүлеп бирә. Шуннан соң кааннар Идел буена башка гаскәр җибәрмиләр. Һәрхәлдә Тукта хан заманында (1291—1312) аның гаскәрләрендә генә түгел, сул канат башы Баян урдасында да шул 4000 кешенең нәсел-нәсәбеннән башка монголлар булмаган [1].

Археологик һәм нумизматик материаллар В. В. Бартольдның «Монгол империясе оешу германлылар Рим өлкәләренә басып кергәндәге кебек халыклар күченүе

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, II том, Л., 1941.

белән бәйле булмаган» дигән фикерен раслыйлар. Икенче яу (1236—1242) тәмамланганчы ук инде анда катнашкан монгол гаскәрләре, үзләренең булачак каганнары Мункә һәм Гуюк җитәкчелегендә, Үзәк Монголиягә китеп баралар һәм тиздән анда тәхет өчен үзара көрәш куба. Ихтимал, яу тәмамлангач, монгол гаскәрләренең бер өлеше Идел буенда Батый урдасында монголлар урнаштырган тәртипне саклау өчен калгандыр. Ләкин, шөбһәсез, җирле кабиләләр массасы арасында монголлар бик аз өлеш кенә алып торганнар. Батый хан үлеп, Кыпчак олысында чуалышлар башлангач һәм тәхеткә ислам диненә күчкән Беркә хан (1257—1266) утыргач, әлеге монголлар да ватаннарына кайтып киткән булырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, Идел буена караган язма чыганаклар буенча да, археологик материаллар (шул чорның уннарча шәһәрләре билгеле) буенча да Идел буенда шактый санда монголлар булуын расларлык дәлилләр табылмый. Көнчыгыш Европада XIII—XV гасырларга караган күпләгән каберлекләр арасында монголларныкы дип әйтерлек кабер истәлекләре юк [1].

Кызганычка каршы, моны борынгы акчалар ярдәмендә дә раслап булмый. Монголлардагы акча әйләнеше безгә билгесез — ул булмаган. Дөрес, Болгарда акча сугу эше беренче чингизидлар вакытында, Батый хан заманында ук торгызыла, ләкин монголларга кадәрге чорда да акча Багдад хәлифе, ягъни аббасидлар исеменнән нәкъ шулай ук чыгарылып килә бит. Тәңкәләр, авырлыкка кагылышлы кайбер үзенчәлекләрне искә алмаганда, Болгар акча сугу традицияләреннән читкә тайпылмыйча сугылганнар, ә XIV гасырга хас үзенчәлекләр акча системасының алга таба үсешеннән килеп чыккан. Акча теге яки бу ханның теләге буенча чыгарылмый, бәлки товар-акча мөнәсәбәтләренең җитәрлек кадәр югары үсеш нәтиҗәсе булып тора.

БОЛГАРДА АКЧА СУГУ ЭШЕНЕҢ ТОРГЫЗЫЛУЫ

Көнчыгыш Европада чингизидлар исеменнән сугылган беренче акчалар Болгарда — халык тыгыз утырган, болгар һәм хазар шәһәрләре күп булган Идел буенда, ягъни акча эквивалентына ихтыяҗ сизелгән,

[1] Федоров-Давыдов Г. А. Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов. М., 1966.

ваклап сәүдә итү эше киң җәелгән һәм монголларга кадәр күп элек гадәти акча әйләнеше булган төбәктә чыгарыла. Болгар шәһәре, монгол яуларына кадәр булгандагы кебек, озак еллар буена акча сугу үзәге булып кала. Болгар йортының монгол династиясе ханнарыннан теге яки бу дәрәҗәдәге автономиясе турында ул акчалар буенча фикер йөртеп булмый. XIII гасырда Болгарда сугылган акчалар — Кыпчак олысының рәсми дәүләт акчалары булып исәпләнгән.

Биредә җирле акча терминологиясе яшәп килгән, һәм монгол чиновниклары җирле халык белән аралашканда шул терминнарга җайлашырга тиеш булганнар. Монгол ханнары исеменнән сугылган акчалар җирле акча традицияләренә бәйсез итеп чыгарыла алмаган, нәкъ шулай ук алар авыл-шәһәрләрдә кулланылган авырлык берәмлекләренә дә яраклашырга тиеш булганнар, чөнки затлы металлдан ясалган тәңкәләр иң элек авырлыкларына карап бәяләнгән.

Болгарда чингизидлар исеменнән беренче акча Батый хан (1237—1256) заманында сугыла. Батый Европа илләренә яу чапканнан соң, 1242 елның язында, Идел буена кайта. Беренче чингизидларның акчасы фәкать Болгарда гына сугылган. Бу исә, монголлар басып алган башкаланың шактый тиз аякка басуы турында сөйли. Качып киткән шәһәр халкы үз нигезенә әйләнеп кайткан. Төбәкнең экономикасы җанланган. Димәк, шәһәрләрне торгызырга комачау итәрлек көчле факторлар булмаган дип әйтергә нигез бар.

Түбән Идел буенда Батый хан дәверендә яңа шәһәр — Сарай әл-Мәхруса төзелә башлый. Хазар шәһәре Саксин, күрәсең, үзенең әһәмиятен җуя һәм чыганакларда кабат искә алынмый. Безгә кадәр килеп җиткән күпсанлы язма чыганакларга караганда, башкалалардагы сөйләм теле кыпчак группасына кергән Идел буе төркисе булган.

Бу елларны Батый бернинди дә яңа яулар оештырмый, шуңа күрә яңа шәһәр төзү өчен һөнәрчеләрне һәм ун меңнәрчә колларны хазар-болгар, кыпчак җирләреннән һәм Ак Урдага кергән башка төбәкләрдән генә җыя ала.

1254 елда Монголиядән кайтып килешли Рубрук Сарай шәһәрендә була. Ул аны яңа төзелгән шәһәр дип атый. Ләкин XIII гасырда Болгар үзенең экономик әһәмиятен югалтмый, шактый вакытлар буена Болгардан башка шәһәрдә акча сугылмый әле.

XIII гасырның 50 нче елларын чингизидлар исеменнән акча сугыла башлау вакыты дип санарга ярый. Батый Идел буенда XIII гасырның 40 нчы елларыннан ук турыдан-туры хакимлек иткән булса да, Мунке каан (1251—1257) исеменнән сугылган акчаларны гына даталары тәгаен билгеле дип санарга мөмкин. Мункә исеменнән көмеш тәңкәләр сугылган һәм Насир лид-дин хәлиф (1180—1225) исеменнән Болгарда сугылган бакыр акчаларга яңа штемпель басылган. Бакыр акчаларга яңадан сугу өчен хезмәт иткән штемпельләр Мункәнең көмеш тәңкәләргә сугылган типларын кабатлый.

Монгол яуларыннан соң Идел буе шәһәрләрендә көмешнең бик нык тезаврацияләнүе (кулда тупланыуы) аркасында, Насир лид-динның исән калган бакыр акчалары гына әйләнештә йөргән булуы да ихтимал. Ә Мункә исеме төшкән яңа штемпель белән сугылган акчалар, көмеш тәңкәләр чыгарылганга кадәр, монгол династиясенең беренче акчасы булган.

Көнчыгышта акча регалиясе, ягъни үз исеменнән акча чыгару хокукы гадәттән тыш югары бәяләнгән. Шуңа да карамастан, Батый хан заманында тулы авырлыктагы көмеш тәңкәләр аның исеме белән түгел, бәлки Мункә исеме белән сугылганнар. Безнең карашка, бу хәл ул чордагы политик вакыйгалар белән аңлатыла. Гуюк каан үлгәннән соң, монголларның башкаласы Каракорымда тәхет, өлкәнлек буенча, Батыйга күчәргә тиеш була. Җүзҗани сүзләренә караганда, тәхет варисы мәсьәләсен хәл итү өчен җыелган кешеләр Батый ханга: «Син безнең патшабыз булырга тиеш, чөнки Чыңгыз нәселеннән берәү дә синнән өлкән түгел...»,— дигәннәр. Ләкин Батый Тулуйның улы Мункә файдасына тәхеттән баш тарткан һәм: «Аны тәхеткә мин, Батый утырткач, чынлыкта хөкемдар мин булырмын»,— дигән [1].

1251 елны Батый корылтай җыя һәм шунда каан тәхетенә Мункә утыртыла. Күп тә үтми, элегрәк вафат булган Үдегәй каанның кардәш-ырулары Мункә каанга каршы оештырган заговор фаш ителә. Аңа катнашкан кешеләр Батый хан боерыгы буенча җәзалап үтерелә. Мондый шартларда Батыйның Мункә исеменнән акча суктырырга ныклы нигезе була. Ул акчаны үзе

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. II том, Л., 1941.

куйган каан исеменнән чыгарып, башка монгол олысларына үрнәк күрсәтергә тели.

Болгарда Мункә исеме белән сугылган көмеш тәңкәләр 1,24 г авырлыкта. 1,24 г лы тәңкә, күрәсең, йөз дирһәм авырлыгы исәбеннән чыгып сугылгандыр. 298 г авырлыктагы (йөз дирһәм кадәр) металлдан 240 тәңкә чыккан. 2,98 г лы авырлык дирһәме Идел буенда гамәлдә йөргән 4,26 г лы мыскалдан көнчыгыш авырлык системасында кабул ителгән принцип буенча килеп чыга: $\frac{4,26 \cdot 7}{10} = 2,98$ г. 4,26 г лы мыскал исәбеннән Болгарда монголларга кадәр үк акча сугылганын без күргән идек инде. Димәк, чингизидлар чыгарган беренче акчаларның авырлыгына карап фикер йөрткәндә, монгол ханнары метрология өлкәсендә дә яңалык кертмәгәннәр. Акча сугуда традицион, җирле авырлык берәмлекләре файдаланылган. Болгардагы экономик тормышның бу чорыннан акча терминнарына кагылышлы нинди дә булса мәгълүматлар калмаган. Ләкин XIV гасырның язма истәлекләре бу яктан да монголларга кадәрге чор белән чагыштырганда кискен үзгәрешләр булмавын күрсәтәләр. Шул рәвешле, акча исәбе һәм акча терминнары монгол яулары килгәнче нинди булсалар, шул килеш кала биргәннәр. Ләкин яңа тәңкәләрнең бик мөһим үзенчәлеге дә бар: монголларга кадәрге чор акчаларыннан аермалы буларак, аларның авырлыгы һәм күренеше бик төгәл.

Әгәр бу чордагы акча исәбендә 1,24 г авырлыктагы 240 данә тәңкә теоретик яктан 298 г лы 100 авырлык дирһәме тәшкил итсә, 120 тәңкә, ягъни Идел буендагы акча әйләнешенә хас сом 149 г авырлыкта булырга, ягъни 298 г лы авырлык стандартының нәкъ яртысын тәшкил итәргә тиеш. Мондый авырлык берәмлекләре гамәлдә йөргәнлекне Болгарда табылган герләр раслый. Түбәндәге авырлык категориясе герләре билгеле: 1) 286 г авырлыктагы гер — тимердән, куб рәвешендә (коррозияне исәпкә алганда, авырлык 298 г булырга тиеш); 2) 145 г авырлыктагы гер — тимердән, куб рәвешендә (теоретик авырлыгы 149 г, ягъни 298 г ның яртысы); 3) 2,93 г авырлыктагы гер — бронзадан, куб рәвешендә (теоретик авырлыгы 2,98 г, ягъни бер авырлык дирһәме тәшкил итә).

Мункә исеме сугылган әлеге акчалардан тыш, махсус тамга куелган икенче типтагы Болгар акчалары да бар, алары да Мункә каан тәхеттә утырган чорныкы

дияргә була. 45 данә шундый тәңкә Әлмән хәзинәсендәге 216 тәңкә арасында табылды. Бу тәңкәләр дә, Мункә каан исеменнән сугылган акчалар кебек үк, датасыз һәм җитмәсә аларга үзләрен суктырган хөкемдарның исеме куелмаган. Ләкин аларның 1,24 г лы сугылу нормасы Мункә каан исеменнән сугылган акчаларның норматив авырлыгына туры килә, һәм бу аларның XIII гасырның акча әйләнешендәге хронологик урынын билгели. Андый авырлык нормасы белән алар фәкать Мункә каан исеменнән акча сугылган чорда гына чыгарылырга мөмкин.

ОЛЫСНЫҢ АЕРЫЛУЫ. ГАЛИ (ЮГАРЫ) ТАМГА

Идел буенда Кыпчак тәхете өчен кискен көрәшне чагылдырган акча сугу эше XIII гасырның 60 нчы елларында аеруча кызыклы төс ала. Нәкъ менә шушы чорда Болгар акчаларында махсус тамга һәм язмалар — олысның Монгол империясеннән аерылу билгеләре барлыкка килә. Шуны да онытмаска кирәк, Батый һәм аның күчмә урдадагы яраннары мәҗүси булганнар, ә Идел буенда хазар чорыннан алып ислам диненең тамыр җәюе күзәтелә. Шуңа күрә XIII гасыр урталарына караган Болгар акчаларында яңа тамга һәм махсус язу сугыла башлау бу чорда Идел буенда барган кискен политик һәм идеологик көрәшне чагылдырып, монголларга каршы көчләр һәм җирле алпавытларның куәте турында сөйли. Кызганычка каршы, моңа тарихчылар җитәрлек игътибар итмиләр. Идел буенда Батый урдасында булган чакта сәяхәтче Рубрук язган сүзләр бик гыйбрәтле: «Һәм мин шуңа гаҗәпләнәм, бирегә кайсы иблис Мөхәммәт канунын алып килгәндер... Бу болгарлар — иң явыз мөселманнар, алар кебек башка берәү дә Мөхәммәт канунын шулай нык тотмыйдыр».

Үләренә күп калмый, Батый хан үзенең улы Сартакны традиция буенча үзе урынына Кыпчак олысының ханы булырга кааннан рөхсәт алу өчен каан станына җибәрә. Мункә каан Сартакны хөрмәт белән кабул итә һәм аңа атасының тәхетен бирә. Сартак Мункә сараенда чакта Батый хан үлеп китә. Аның кинәт кенә үлүе шикләндерсә дә, тарихчылар кулында моны ачыкларлык мәгълүматлар юк. Христиан дине тоткан Сартак урынына җирле мөселман руханилары һәм феодаллар ислам дине кабул иткән Беркәне —

Батый ханның энесен тәкъдим итәләр. Сартак хан Иделнең уң як ярындагы резиденциясенә кайтып килешли юлда үлә (аны агулыйлар). Ләкин Мунқә каан олысның ханы итеп Беркәне түгел, бәлки Сартакның кече яшьтәге улы Улакчыны раслый. Улакчы да шул ук елны үлеп китә. Фәкать шуннан соң гына Беркә, Мунқә кааның теләгенә каршы килеп, олысның тәхетенә хуҗа була (1257—1266). Беркәгә кааның теләгенә каршы торырга Идел буе шәһәрләренең һәм күчмә тормышлы кыпчакларның сепаратистик омтылышлары ярдәм итә.

Бу уңайдан кыпчак гаскәр башлыгы, Хулагу ягында сугышкан һәм Беркәгә каршы барудан баш тартып, бөтен гаскәре белән аның ягына күчкән Җәләлетдиннең үз сугышчыларына әйткән сүзләре бик характерлы: «Сез минем күркәм сыйфатларымны һәм затлы нәселдән булуымны беләсез. Мин сезнең белән бер нәселдән һәм гәрчә Хулагу хан миңа тулысынча мәрхәмәтле булса да, мин сезнең кылычка ризык булуыгызга юл куймаячакмын. Мин болай уйлыйм: әйдәгез, монгол куәте һәм бәхете белән хушлашыйк һәм мин үземне дә, сезне дә монгол фәрманыннан азат итәрмен» [1].

Ләкин олыста монголлар яклы политика тарафдарларының хәле шактый нык була әле: аларны олыста Батыйның бик зур йогынтыга ия булган өлкән хатыны Баракчин яклый. Баракчин Беркә ханны тәхеттән бәреп төшерү өчен заговор кора һәм аның урынына күндәм Туда Мәңгене утыртмакчы була. Ләкин Баракчинны фаш итәләр һәм Хулагу хан станына качарга маташканда тотып алалар да җәзалап үтерәләр.

Шул вакыттан алып Кыпчак олысы монгол империясеннән аерыла башлый. Бу аерымлану Монгол империясенең башка олысларына караганда иртәрәк була. Ханнар мөстәкыйль политика алып бара башлыйлар. Эш монголлар белән сугышуга тикле барып җитә. Шундый сугышларның берсендә Беркә бөек кааның үзен тар-мар китерә, ә 1262 елны Иран монголлары белән сугыш башлана һәм фактта шул сугыш монголларга Мисырны яулап алырга комачаулый да. Хулагуидлар сараеннан чыккан рәсми версия буенча, Рәшид әд-дин: «Низаглар Беркәнең үзсүзле булуы ар-

---

[1] Рашид ад-дин. Сборник материалов летописей, III том, М.-Л., 1946.

касында килеп чыккан»,— дип яза [1]. Икенче бер фарсы тарихчысы Вассаф Беркәнең Ираннан Арран белән Азәрбайҗанны дәгъва итүен әйтә [2]. Әгәр Урта гасырлар башында бу өлкәләрнең Иран белән Хазар каганнары арасында низаг чыгуның сәбәбе булганлыгын искә алсак, эш ханның үзсүзлелегендә генә түгеллеген аңларбыз. Аны мөһим сәүдә юллары узган төбәкләрне кулга төшерергә омтылырга Кыпчак алпавытларының мәнфәгатьләре мәҗбүр итә. «Батыйның Беркә исемле энесе дә бар,— дип яза Рубрук.— Аның көтүлекләре Тимер Капка янында урнашкан, Персиядән һәм Төркиядән кайтучы барлык мөселманнарның юлы шуннан уза...»

Олысның аерылуы акча сугуда чагылыш таба. Югарыда әйтеп кителгәнчә, чингизидларның беренче акчалары Болгарда Мункә каан исеменнән сугылганнар. Бу акчаларның алгы ягында Каракорым кааның исеме һәм сабы бөтәркәле, ике җәпле сәнәк рәвешендәге тамгасы, ә арткы ягында урталыкта бөтәркәсез генә ике җәпле сәнәк (күрәсең, Батый ханның тамгасы) һәм акча сугылган урынның, ягъни Батый хан хакимлек иткән Болгарның билгесе урнаштырылган.

Кыпчак дәүләтенең мөстәкыйльлеген күрсәткән беренче акчалар Беркә хан заманында сугылган. Әлмән хәзинәсендәге акчаларда үзенчәлекле тамга беренче тапкыр очрый. Соңыннан ул тамга билгесе генә түгел, бәлки олысның тамгасы булып та китә.

Әлмән хәзинәсендә кеше сурәтенә охшашлы шундый ук тамга төшкән 45 тәңкә бар. Бу сурәт кыпчак далаларында очрый торган, бер кулына касә тоткан балбалларны хәтерләтә. Тәңкәләрдә тамга тирәсендә «Тамга-и гали», ягъни «Бөек тамга» дигән язу бар. Шулай итеп, тамга тирәсендәге язуга карап фикер йөрткәндә, бу тамга гади түгел, бәлки төп, югары тамга, ул монгол кааны тамгасыннан аерылып тора һәм аңа каршы куела.

Шул вакыттан башлап Беркә тамгасы һәм аның олысы монгол кааның тамгасына һәм хакимлегенә бәйле түгел дип игълан ителә. Аннары бу «Гали тамга» XIII гасырда Болгарда сугылган барлык көмеш

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, II том, 74 бит.

[2] Шунда ук, 81 бит.

тәңкәләрдә олысның гербы, кыпчак символы рәвешендә урнаштырыла. Нумизматик әдәбиятта аны кайчак «Батый йорты тамгасы» дип тә йөрткәлиләр, ләкин мондый атама дөрес түгел. Чыгарылган акчаларга карагандa, Батыйның мондый тамгасы булмаган. «Гали тамга» Батый йорты политикасына һәм аның интересларына каршы, аның өлкән хатынын һәм улларын һәлак иткәннән соң, ягъни Батый йорты юк ителгәч кенә куела башлый.

Гали тамгалы акчаларда дата юк һәм аларда акчаны суктыручы хөкемдарның исеме дә куелмаган. Ләкин, инде әйтеп кителгәнчә, мондый акчаларның 1,24 г лы итеп сугылу нормасы Мункә каан исеменнән сугылган акчаларның норматив авырлыгы белән тәңгәл һәм ул акчаның датасын билгели.

Бу акчаларның абсолют датасын билгеләргә тырышып карыйк. Мункә каан исеменнән сугылган Батый хан акчаларында ике җәпле сәнәккә охшаган махсус тамга бар. Батый белән Мункәнең мөнәсәбәтләренә карап фикер йөртсәк, Батый ханга аноним акча сугуның һәм бөек каан тамгасына икенче «төп» тамганы каршы куюның хаҗәте булмаган шикелле. Батый хан 1256 елда үлә. Мункә каан исә Батый үлеп бер ел үткәч, 1257 елда үлгән. Шул ук елдан алып, әле бөек каан үлгәнче дип уйларга кирәк, Кыпчакта инде Беркә хан тәхеттә утыра. Шушы вакыттан башлап Мункә каан исеменнән акча сугу туктатыла, ләкин акчаларга үз исемен куярга Беркә хан әле җөрьәт итми. Бик ихтимал, Кыпчак олысы тамгасы төшкән әлеге аноним акчалар Мункә исән чакта сугылгандыр. Мункә исеменнән чыгарылган әүвәлге акчалар белән бертигез авырлыкта булсалар да, бу инде политик аерымлыкның башлангычы, ерак Каракорымда утырган каанһар тамгасыннан үзгә булган, яңа, мөстәкыйльлек тамгасы игълан итү булган.

XIII ГАСЫРНЫҢ 60—80 НЧЕ ЕЛЛАРЫНДА АКЧА-АВЫРЛЫК СИСТЕМАСЫ

Тәхеткә утырганчы ук ислам дине кабул иткән һәм Багдад хәлифләре белән хат алышкан Беркә, тәхеткә менгәч, Мисыр белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыра. Мисырны яулап алу белән куркыткан Хулагу хан һәм Беркә арасында бәрелеш булганнан соң, бу мөнәсәбәтләр тагы да җанлана төшә. Мисыр солтаны

Бибарс әмере белән Мәккәдә Беркә хөрмәтенә тантаналы намаешлар (процессияләр) оештырыла, мәчетләрдә аның саулыгы хакына гыйбадәт кылалар[1]. Катлаулы эчке политик көрәш шартларында Идел буенда традицион Көнчыгыш политикасы җиңеп чыга.

Беркә, Мисыр белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырганда һәм Мисыр солтаны — Кыпчак йортыннан чыккан Бибарска монголларга каршы көрәштә ярдәм иткәндә, үзенең әле генә оешкан дәүләт системасында җирле казанышлардан гына түгел, бәлки гарәп культурасы казанышларыннан да файдаланган, күрәсең. Хәер, бу йогынты бер яклы гына булмаган. Бу чорда мәмлүкләр хакимлек иткәнгә, Мисырны еш кына «төрки дәүләт» дип атаганнар. әл-Макризи түбәндәгеләрне язган: «Ә төрки дәүләттәге әмирләрнең һәм гаскәриләрнең киеме үзгәргән... һәм сугышчылар хезмәттә чагында татар кафтаннары һәм бүреге киеп йөри башлаганнар...» Шулай итеп, Беркә хан, үзенең варислары кебек үк, үз интересларын, шулай ук җирле руханиларның һәм дөньяви алпавытларның интересларын күзәткән, һәм баштан ук үзенең эшчәнлеген бөек кааннар политикасына каршы куйган. Олыстагы барлык ясаклы халыкның санын алу (1257—1259) ул хакимлек итә башлаган елларга туры килә, олыска буйсынган төбәкләрдә унбашлары (десятниклар), йөзбашлары (сотниклар), меңбашлары (тысячниклар) һәм төмән башлары (темниклар) рәвешендә даими хәрбиполитик оешмалар төзелә. Ләкин бу үзгәртеп корулар монгол характерында түгел, бәлки нигездә болгар характерында булалар. Моны без идарә итүдә төрле халык вәкилләре булган җирле аксөяк катлауның актив катнашуыннан күрәбез.

Беркә хан чыгарган беренче акчаларда Кыпчак олысының аерымлана баруы ачык чагыла. Беркә, ханнар арасында беренче булып, акчаны үз исеменнән суктыра башлый. Әлмән хәзинәсеннән күренгәнчә, Беркәне алмаштырган Мәңге Тимер үзен инде «әл-әгъзам» («иң югары») дигән титул белән атый. Ханнар мөстәкыйльлекне күрсәткән һәм каанга тиң солтан титулы алалар. Аннары титуллар торган саен катлаулырак, чуклырак була бара. Мәңге Тимер акчаларының арткы ягында гарәптә акча сугуны керткән Габдел Мәлик

---

[1] Закиров С. Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом. М., 1966.

хәлиф заманындагы гадәти форма тора: «Бу дирһәм Шәһре Болгарда сугылды».

Әлмән хәзинәсендә, «Гали тамга» дигән язулы акчалардан тыш, Беркә хан исеменнән сугылган 130 данә акча бар, аларның норматив авырлыгы 1,56 г. Хәзинәдә тагы Мәңге Тимернең 7 данә тәңкәсе, 22 данә аноним Болгар акчалары һәм, ниһаять, Биләр шәһәрендә сугылган 6 данә аноним тәңкәләр бар. Барлык бу акчаларның авырлыгы акча сугу эшенә Беркә хан заманында кертелгән 1,56 г лы норматив сугу авырлыгыннан аерылмый. Әгәр мондый үзенчәлекләрне реформа дип атап булса, бу реформаның сәбәпләре безгә билгесез. Әлмән хәзинәсендә Мункә каан акчалары юк. Мункә исеменнән Батый хан заманында сугылган акчаларның тыелган булуы бик ихтимал. Беркә яңа каан Ариг Буга исеменнән вак номинал гына суктырган. Әлмән хәзинәсендәге исемсез Болгар һәм Биләр акчалары эчке низаглар чорында сугылган дип уйлау табигый.

Беркә хан суктырган акчаларның 1,56 г лы норматив авырлыгы һәм шул ук чорда Ариг Буга каан исеме белән сугылган көмеш номиналларның 0,52 г лы авырлыгы акчаның Батый хан чорындагыдан башка авырлык нормалары буенча сугылуын күрсәтәләр. Авырлык нормаларының болай үзгәрүен һәм яңа тип тәңкәләр чыгаруны чын мәгънәсендә акча реформасы дип атап буламы?

Бу очракта без бик үзенчәлекле акча реформасы күрәбез. Хикмәт шунда, Г. А. Федоров-Давыдов югарыда тасвир ителгән Әлмән хәзинәсенә охшашлы Болгар акчалары хәзинәсен тикшерә һәм анда да Батый хан акчаларын тапмый [1]. Ләкин иң кызыклысы шул: Г. А. Федоров-Давыдов тасвир иткән хәзинәдә дә, Әлмән хәзинәсендәге кебек үк, 1,56 г лы Беркә хан акчалары янында сугу нормасы 1,24 г, ягъни Батый тәңкәләренә хас авырлык нормасы буенча сугылган исемсез акчалар очрый. Димәк, Беркә хан өчен акчаның авырлык нормасы түгел, бәлки андагы язу принципиаль әһәмияткә ия булган. Мункә каан исеменнән чыгарылган Батый акчалары тыелган була.

Бөтенләй яңа авырлык стандарты (1,56 г) буенча сугылган акчалар Беркә хан заманында авырлык ре-

---

[1] Федоров-Давыдов Г. А. Два клада болгарских монет XIII века. НЭ, М., X том, 167 бит.

формасы да үткәрелүен күрсәтәләр. 4,26 г лы мыскал системасы һәм 2,98 г лы авырлык дирһәме системасы стандартлары озак еллар буена гамәлдә йөри һәм кабатлы авырлыклары төрлечә булган герләр бик күбәя, өстәвенә, кулдан гына ясалганга, алар тиешенчә төгәл дә булмыйлар һәм болар барысы да сәүдә эшендә кыенлыклар тудыра. Һәрхәлдә, хулагуид Газан хан үзе үткәргән реформаны шушы сәбәпләр белән аңлата. Аның фәрманында: «...урда һәм төрле шәһәр базарларында һәркемнең, үз файдасын күзәтеп һәм табыш артыннан куып, таштан, балчыктан, тимердән һәм башка нәрсәдән гер ясавы һәм һәрчак үз теләге белән аларның авырлыгын арттыруы һәм киметүе мәгълүм булды. Аларда шул авырлык нигезендә сату итәләр һәм ярлы халык алдана һәм зыян күрә. Мондый хәл безнең дөньяны бизәүче фикеребезгә туры килми, һәм без аны хупламаячакбыз. Амуйе елгасыннан алып Мисырга кадәр барлык биләмәләребездә алтын һәм көмеш акча авырлыклары үлчәүлекләрен төзәтергә, аларга келәймә сугарга һәм барлык биләмәләребездә башкалада без урнаштырган ныклы тәртип буенча эш итәргә, аннан тайпылмаска боерылды».

Беркә хан үткәргән авырлык реформасы да илдә авырлык системасын унификацияләүне күздә тоткан, чөнки дәүләт чикләренә, Идел буеннан тыш, Хәрәзм, Кырым һәм башка өлкәләр дә кергән һәм һәр җирдә үзләренең авырлык стандарты гамәлдә йөргән. Өлкәләр башында гадәттә хан билгеләгән вәкилләр утырган. Иранда Газан хан заманында мондый вәкилләргә реформаның барышын күзәтергә, хосусый кешеләрнең герләрен тикшерергә һәм бу герләргә закон билгеләгән стандарт буенча келәймә сугарга кушылган. Болар, дәүләт күләмендәге чаралар булып, нык рәвештә тормышка ашырылганнар.

Беркәнең тәкъва мөселман булуын замандашлары арттыралар булса кирәк. Ләкин шунысы шөбһәсез, ислам динен тоткан алпавытлар арасында ул диндарлык үрнәге булып, ә керткән яңалыклары дәүләтне зирәк идарә итү мисалы булып саналган.

Итальян Пиголотти сүзләренә караганда, 1335 елда Сарайда 1 ман якынча 1,950 кг авырлыкта булган. Димәк, әгәр Пиголотти мәгълүматы дөрес булса, Беркә хан керткән һәм 0,195 г лы кират нигез итеп алынган авырлык системасы гомерле булып чыккан дигән сүз.

Беркә ханның акча-авырлык реформасыннан соң

акча 4,68 г лы мыскал исәбеннән сугылган. Тәңкәләр уртача 1,56 г, ягъни $^1/_3$ мыскал, ә вак көмеш акчалар 0,52 г авырлыкта, ягъни эре тәңкәләрнең $^1/_3$ өлешен тәшкил иткәннәр.

Идел буенда таралган иң кечкенә акча-авырлык берәмлеге дәник булган. 1,56 г лы эре акча 0,78 г лы ике дәниктән торган. Акчаны бик төгәл авырлыкта итеп сукканнар һәм, бозылмаган булса, аны өстәмә рәвештә үлчәү-тикшерү кирәк булмаган. Мәсәлән, Беркә ханның без үлчәгән 130 данә акчасыннан 45 данәсе, ягъни $^1/_3$ е диярлек 1,50—1,56 г авырлыкка туры килә. Иң җиңел акча 1,39 г, иң авыры 1,69 г. Очраклы алып үлчәгән акчалар авырлыгындагы аерма 0,30 г чамасында гына, ягъни акча авырлыгының $^1/_5$ өлешеннән дә кимрәк.

Акчалардагы язуларга карап фикер йөрткәндә, дәник исәбеннән үлчәү XIV гасырда киң тарала. Ләкин мондый исәп, күрәсең, монголларга кадәрге, бигрәк тә «акчасыз чор»дагы Идел буеның акча-авырлык системасына ияру булыр. Ул вакытларда кыйммәтле металл кисәкләрен һәрвакыт тикшереп, үлчәп торганнар. Югарыда, ихтимал, «акчасыз чор»да гамәлдә йөргән пыяла герләр комплекты арасында 5 дәникле гер дә булуы әйтелгән иде. Асылда дәник авырлык һәм акча берәмлеге булып тора, бу очракта ул $^1/_6$ мыскал тәшкил итә.

Шунысы кызык, югарыда китерелгән акча-авырлык берәмлекләре арасында 4,68 г лы мыскал гадәттән тыш аз урын тота. Без классик алтын динар яки 4,235 г лы мыскал турында сөйләгән идек инде. Ләкин 4,235 г лы «классик» мыскал әйләнештә 423,5 г лы, ягъни бер кадаклы авырлык стандарты кулланылган чорда гамәлдә була алган. Беркә хан реформасыннан соң, 468 г лы кадак фракциясе стандарт булып киткәч, ихтимал, 4,68 г лы мыскал «классик» яки «алтын» дип исәпләнә башлагандыр.

Мондый мыскалның «алтын» дип аталуына читләтә дәлилне без Сарай әл-Җәдидтә табылган көмеш касәдәге язуда күрәбез: «Биш сом таки игерми нукрат мыскал ярым», ягъни «Егерме ярым көмеш мыскал биш сум тәшкил итә». Язу XIV гасырга карый һәм аның турында сүз алда булачак. Әлегә безне язудагы «нократ мыскалы», ягъни көмеш мыскал гыйбарәсе кызыксындыра. Идел буенда сом эре исәп берәмлеге яки көмеш коелма буларак билгеле, шулай булгач, 20,5 мыскал, әгәр нигез итеп гадәти мыскалны алсак,

5 сом авырлыкка тигез була алмый. Артык кечкенә бу. Күрәсең, язуда юкка гына «көмеш мыскал» турында сүз бармый торгандыр. Әгәр дә XIII—XIV гасырларда Идел буенда алтын һәм көмеш нисбәте якынча 1 : 10 булганлыгын игътибарга алсак, «көмеш мыскал»ның авырлыгы 46,8 г тәшкил итәр. Шундый 20,5 мыскалның авырлыгы чыннан да 5 сом авырлыкка тигез булырга мөмкин. Димәк, 4,68 г лы мыскал «алтын» дип аталган. Ун мыскаллы авырлык фракциясенең булуын Татарстан Дәүләт музеендагы герләр җыелмасы раслый. Анда 46,10 г лы һәм 46,16 г лы тимер герләр бар. Аларны 46,8 г лы «нократ мыскалы» дип карарга була. Дөрес, шактый эре мыскал килеп чыга, ләкин бу очракта сүз гади терминология турында гына бара.

Реформадан соң норматив авырлыклары 1,56 г булган акчалар яңа кертелгән 468 г лы стандарт авырлыгына 300 акча исәбеннән сугылырга тиеш булган.

Бу чорда Болгар акчалары түбәндәге исәптән чыгып сугылырга тиеш булганнар:

0,195 г лы 4 кират 0,78 г лы дәник тәшкил итә;
0,78 г лы ике дәник 1,56 г авырлыктагы 1 ярмак яки 0,52 г авырлыктагы 3 вак көмеш тәңкә;
1 мыскал (4,68 г) = 3 ярмак (дирһәм);
1 алтын яки динар (9,36 г) = 1,56 г лы 6 ярмак (дирһәм);
1 нократ мыскалы (46,8 г) — 30 ярмак (дирһәм);
1 сом (исәп һәм авырлык берәмлеге) = 120 ярмак (187,2 г);
1 кадак = 300 ярмак (468 г).

Бу системадагы сом түбәндәге акча, акча-авырлык һәм авырлык берәмлекләренә тигез:

1 сом =	120 ярмак (дирһәм)
	40 мыскал
	20 алтын
	2/5 кадак (1/5 ман)

1257 елда Мункә каан үлгәннән соң, аның Ариг Буга һәм Хубилай исемле ике туганы каан титулы өчен дәгъва куптаралар. Бу көрәштә Беркә хан Ариг Буганы яклый һәм, күрәсең, Болгар акча сугу осталары шул сәбәпле вак номиналлы (0,52 г авырлыктагы) акчаны Ариг Буга исеме белән чыгаралар.

Ахыргы исәптә үзара көрәштә Хубилай җиңеп чыга һәм Монгол империясенең бөек кааны титулын ала. Хубилай каан үзенең башкаласын Кытайга күчерә. Болгарда Ариг Буга исеменнән акча сугуның мәгънәсе калмый. Ихтимал, Ариг Буга акчалары гомумән тыелгандыр — аның акчасы гына булган нибары бер

хәзинә билгеле, ләкин башка хәзиналәрдә алар очрамый. Әмма Беркә хан Хубилай исеменнән дә акча сугарга ниятләми. Кыпчак феодаллары илнең экономикасын Кытайга буйсындыруга каршы чыкканнар дип уйларга туры килә. Чыннан да Кыпчак иле Кытайда утырган монгол кааны исеменнән акча сугылмаган бердәнбер олыс булып кала. Шулай итеп, җирле аристократиягә таянган Беркә ханның Кыпчакны мөстәкыйль дәүләткә әйләндерергә омтылуы, аның монгол кааннары белән мөнәсәбәтләре XIII гасырда Болгарда сугылган акчаларда шактый ачык чагылыш таба.

XIII ГАСЫРНЫҢ 90 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА АКЧА ӘЙЛӘНЕШЕ

Тикшерелә торган чорда акча әйләнешендәге характерлы үзенчәлек шунда: Болгарда акча сугудагы Беркә хан заманында ук кертелгән норматив авырлык 1,56 г нан 1,365 г га кадәр кими. Авырлык нормасының болай кимүе шул чорга караган тәңкәләрне үлчәү юлы белән яхшы раслана. Яңа сугылган акчаларның норматив авырлыгы ни сәбәпле кимегәнен ачыклау өчен, безнең фикеребезчә, моны шул чордагы тарихи вакыйгаларга бәйләп карарга кирәк.

XIII гасырның 90 нчы елларында Кыпчакта Жучи нәселеннән булган варислар арасында эчке бәрелешләр булуы мәгълүм. Ихтыярсыз, йомшак Туда Мәңге хан (1282—1287) хакимлек иткән вакытта үзәк властьның көчсезләнүе сизелә башлый.

Бу — Батый ханның өлкән хатыны Баракчин Беркә хан урынына тәхеткә тәкъдим иткән Туда Мәңге (Батыйның оныгы) булырга тиеш. Туда Мәңге олыска карата Батый политикасын үткәрергә тырышканмы? Мәгълүматлар җитәрлек булмагач, моны әйтүе кыен, ләкин мондый политика кыпчак алпавытларының интересларына капма-каршы булган. Бейбарс сүзләренә караганда, Туда Мәңге тәхеттән үзе ваз кичкән, ләкин башка мәгълүматлар буенча, акылга зәгыйфьлеге сәбәпле аны тәхеттән төшергәннәр. Соңгы версияне Рәшид әд-дин бирә, күрәсең монысы кыпчак феодалларын законлы ханны тәхеттән төшерүдә гаепләргә тырышкан хулагуидлар арасында туган версиядер. Хулагуидларның Туда Мәңгене яклавы аның нәкъ менә монголларга файдалы политиканы үткәрергә тырышуын күрсәтә. Ләкин Беркәдән соң һәм бигрәк тә олысның тагы да ныграк аерымлануына һәм кыпчак алпавытлары-

ның көчәюенә китергән Мәңге Тимер хакимлегеннән соң, Туда Мәңгенең политикасы уңыш казанмаган. Ул хакимлек иткән вакытларда Хәрәзмдә, хәтта Сарайда сугылган күпсанлы исемсез акчалар аның властеның какшаганлыгы, йомшаклыгы турында сөйлиләр. Исемсез акчалар Болгарда һәм Биләрдә дә чыгарылган.

Феодаль төркемнәрнең көрәше һиҗри 680 елда (1281/1282), тәхеткә Туда Мәңге утырган вакытта башлана һәм ул кораллы бәрелеш төсен ала. Чыннан да Мәңге Тимер үлгәч, тәхеткә монгол гореф-гадәтләренең химаячесе Нугай тырышлыгы белән, васыятькә каршы килеп, ханзадә Тула Буканы түгел, бәлки Туда Мәңгене утырталар. Ләкин җирле алпавытлар (мәсәлән, Мәңге Тимернең уллары) ярдәме белән, Тула Бука (1287—1291) Нугай тарафдарлары кулыннан властьны тартып ала. Бу хәл Көнбатыш олысның төмән башы Нугайның ачуын чыгара. Көнчыгышта Күк Урдада да чуалышлар һәм тәхет өчен көрәш кабынып китә. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев фикеренчә, XIII гасырның соңгы чиреге Кыпчак иленең киң өлкәләрен биләп алган өзлексез феодаль сугышларда үтә.

Бу сугышта биләмәләре Дунайның сул як ярыннан, Кырымнан һәм Днепрның аръягыннан алып Тимер Капкага кадәр җәелгән Нугайның катнашуы хәлиткеч әһәмияткә ия була.

Нугайның хәрби эшчәнлеге белән XIV гасырның икенче яртысында властька һәм тәхеткә омтылган төмән башы Мамайның астыртын казынулары арасында параллель үткәрү кызыклы булыр сыман. Ул да чама белән шул ук тирәләрдә хәрәкәт итә һәм анда соңыннан Кырым ханлыгы оеша. Нугайның хәрәкәтләре куәткә ирешкән феодалның тәхеткә омтылышы гына булмый, күрәсең: аның артында мөстәкыйльлек турында хыялланучы билгеле бер көчләр торган, һәм аларның интереслары бер булган. Бу көчне без кыпчакларда күрәбез. Көрәш яшертен төстә бара, һәм кыпчаклар хаким династия нәселеннән булмаган вәкилләрне тәхеткә тәкъдим итә алмыйлар, чөнки бу вакытта көрәш «законлы» характерын югалткан булыр иде. Нугай олысын үзенең уллары һәм яраннары ярдәмендә идарә иткән. Ләкин Жучиның оныгы булган Нугай үзе монда Хазар каганлыгы чорында ук яшәгән төрки бәкләрбәге титулын йөртә, үзенең хәлен ныгыту өчен ислам динен кабул итә һәм бу турыда Мисыр солтанына хәбәр итә.

Феодаль сугыш үзәк власть тарафдарларының җиңүе белән тәмамлана. Шәһәрләр һәм сәүдәгәрләр Тукта хан (1291—1312) ягын тоталар. Тукта үз ягына Нугайны да аударуга ирешә, ә аннары аның үзен дә тар-мар итә. Ләкин Нугайны җиңү әле эчке феодаль сугышларга нокта куймый. Тукта ханга Нугайның уллары һәм башка өлкәләрнең ханзадәләре белән туктаусыз сугышлар алып барырга туры килә.

Династия низаглары дәүләтнең экономик тормышына да тәэсир итмичә калмый. Туктаусыз сугышлар аркасында халыктан ясак регуляр төстә җыелмый, шунлыктан казна бушап кала, тулы авырлыктагы акча чыгаруга затлы металл җитми. Династия низаглары чорында көмеш фонды күпсанлы тәхет варислары кулында таркау хәлдә генә булган. Шуңа күрә тулы авырлыктагы акчаны даими чыгарудагы специфик кыенлыкларны искә алырга кирәк. XIII гасырның 90 нчы елларында акчаның норматив авырлыгы 1,56 г нан 1,365 г га кадәр төшүе, авырлык нормасы 1,365 г лы акчалар хәзинәсендә 1,56 г лы акчаларның бөтенләй булмавы акча-үлчәү реформасы үткәрелүен һәм иске акчаларның әйләнештә йөрүе тыелганлыгын күрсәтә.

Династия низаглары чорында чыгарылган акчаларның бер үзенчәлеге — төрле типтагы, ләкин гали тамга сугылган исемсез һәм анэпиграфик (елы һәм сугу урыны күрсәтелмәгән) тәңкәләр сугылуда.

XIV гасырның икенче яртысына һәм XV гасырның беренче чирегенә караган исемсез акчаларны күзәтү мондый акчаларның нәкъ менә династия низаглары чорында, тәхетне кем алачагы билгеле булмаган вакытларда сугылганлыгын күрсәтә.

Реформа 90 нчы елларда үткәрелгән, ләкин кайсы хан хакимлек иткәндә булуын ачыклау кыен. Мәңге Тимер (1266—1282) һәм Туда Мәңге (1282—1287) тәхеттә утырган чорда Болгарда сугылган акчаларда авырлык нормасының кимүе сизелми. Тула Бука (1287—1291) акчалары аз сакланган, аларның нинди авырлыкта чыгарылганлыгын билгеләү дә мөмкин түгел. Акча-авырлык реформасы Тукта хан (1291—1312) тәхеттә утырган елларда үткәрелгән булырга охшый. Ул, әкренләп, көндәшләрен җиңүгә ирешкән һәм бердәнбер хөкемдар булып калган. Аның исеменнән акча Болгарда гына түгел, бәлки XIII гасырның 80 нче елларында Хәрәзмдә һәм Сарайда эшли башлаган акча сугу сарайларында да чыгарыла.

Ләкин монда бер нәрсә аптыраштa калдыра: реформадан соңгы акчалар ни өчен аларны суктырган хөкемдар исемен күрсәтмичә, аноним рәвештә чыгарылган соң? Билгеле булганча, Тукта хан хакимлек итә башлаганда әле Нугайга бәйле булган һәм, әгәр тәхеттә нығып калса, аңа һәрвакыт буйсынырга сүз биргән.

Ләкин мондый акчалар, исемсез чыгарылу өстенә, елы һәм урыны күрсәтелмичә сугылганнар. Тәхеткә менгәч, акчаны бик яшерен төстә, хәтта аларның сугылу урынын да күрсәтмичә чыгару Туктага нигә кирәк булды икән? Югарыда әйтелгәнчә, шундый ук исемсез акчалар XIV гасырның икенче яртысында чуалышлар чорында да сугылган. Бу акчалар чыгарылган Болгар шәһәренең, күрәсең, мөстәкыйль үк булмаса да, үз власте, бәлки администрациясе булгандыр һәм, анда реформа үткәреп, кемнең көчле булачагын белмәгән хәлдә, исемсез һәм анэпиграфик акчалар чыгарыла. XIII гасырның 80 нче елларында Хәрәзмдә һәм Сарайда да Тукта хан тәхеткә утырып, анда нығып җиткәнче исемсез акчалар сугыла. Болар барысы да шәһәрләрнең администрациясе күчмә Урда ханнарына номиналь рәвештә генә буйсынганлыкны күрсәтә.

Насир лид-дин аллаһе (иман һәм алла ярдәмчесе) дигән данлыклы титул белән Тукта чыгарган тәңкәләрнең датасы тәгаенләнгән — алар һиҗри 692 еллардан (1293) билгеле. Бу акчаларның арткы ягына сугылу урыны (Шәһре Болгар) һәм елы күрсәтелгән.

Реформадан соңгы акчаларның 1,365 г лы авырлык нормасы Болгар шәһәрендә 1967 елда табылган хәзинәдәге акчаларның авырлык диаграммасында яхшы чагыла.

Реформадан соң акча сугудагы авырлык стандарты 409,5 г лы кадак булырга мөмкин. Бу фаразны Болгарда табылган герләр дә раслый. 409,5 г лы кадак исәбеннән, элекке кебек үк, норматив авырлыгы 1,365 г лы 300 данә акча сукканнар. 409,5 г лы авырлык стандарты Көнчыгышта яхшы билгеле булган, Болгарда да VIII—XI гасырларга караган әүвәлге хәлифәлек акчалары шул исәптән сугылганнар.

90 нчы елларда тормышка ашырылган акча-авырлык реформасын түбәндәгечә күз алдына китерергә мөмкин:

2 дәник (0,6825 г лы) = 1 ярмак (дирһәм) (1,365 г лы);
1 мыскал (4,0952) = 3 ярмак (1,365 × 3 г);

1 алтын (8,19 г) = 6 ярмак (1,365 × 6 г);
1 сом (163,8) = 120 ярмак (1,365 × 120 г);
1/2 кадак (204,75) = 150 ярмак (1,365 × 150 г);
1 кадак (409,5 г) = 300 ярмак (1,365 × 300 г).

90 нчы еллардагы реформадан соң гамәлдә йөргән акча-авырлык системасында да, XIII гасырның 60 нчы елларындагы акча-авырлык системасындагы кебек үк, акчаларны тикшерү һәм йөкләрне үлчәү берәмлекләрен куллануда беркадәр аерма сизелә.

Кыйммәтле металларны һәм акчаны үлчәү өчен мыскал (1/100 кадак) кулланылганлыгын без вак герләргә карап беләбез, ә йөкләрне үлчәү өчен, ихтимал, 96 өлешле система кулланылгандыр (моны А. Терещенко тапкан герләр комплексы раслый). 409,5 г лы кадак системасына кергән герләр Татарстан Дәүләт музеенда бар.

1 өлеш = 4,26 г (4,265525 г) ...	1/96
2 өлеш = 2×4,26 = 8,53 г ...	1/48
3 өлеш = 3 × 4,26 = 12,8 г ...	1/32
4 өлеш = 4 × 4,26 = 17,06 г ...	1/24
6 өлеш = 6 × 4,26 = 25,59 г ...	1/16
8 өлеш = 8 × 4,26 = 34,1 ...	1/12
12 өлеш = 12 × 4,26 = 51,19 г ...	1/8
24 өлеш = 24 × 4,26 = 102,75 г ...	1/4
48 өлеш = 48 × 4,26 = 204,75 г ...	1/2
96 өлеш = 96 × 4,46 = 409,5 г ...	1

Акчаларның авырлыгын тикшерү өчен махсус герләр кулланылуын Болгар шәһәрлегендә табылган шундый герләр яхшы сурәтли. Мәсәлән, 40,7 г һәм 40 г лы шундый ике бронза гер билгеле.

40,7 һәм 40 г лы герләрнең авырлыгы 40,95 г лы нократ мыскалына, ягъни 4,095 г лы 10 мыскалга туры килгән.

Герләрнең берсендә кабатлыкны күрсәтүче ноктлар бар һәм бу затлы металларны һәм акчаларны үлчәгәндә махсус исәп кулланылуын яхшы дәлилли. Башкача бу ноктларның мәгънәсен аңлатып булмый: гердәге кебек 5 нокта түгел, бәлки 10 нокта булырга тиеш иде, чөнки гер 10 мыскалдан торган. Биш нокта алтын системасында җиңел аңлатыла. Алты акча динар, яки алтын тәшкил иткән. Реформадан соңгы алты акчаның авырлыгы 8,19 г тәшкил итә (1,365×6=8,19), ягъни гердәге биш нокта ул биш алтыннан тора дигән сүз (8,19×5=40,95). Алтын системасының гамәлдә булганлыгы Болгарда табылган тагы бер гер белән раслана.

Пирамида рәвешендә итеп, аның очына тотка куеп тимердән ясалган бу матур гер 8,19 г, ягъни 1 алтын (8,19 г) тарта.

Шул ук җыелмадагы бронза куб рәвешендәге гернең авырлыгы 4,1 г, ягъни 0,5 алтын (1365×3=4,095 г) яки 1 мыскал.

Практикада акча әйләнешендәге эрерәк сәүдә операцияләре вакытында акчаны алтын системасы буенча — авырлыгына карап кабул иткән булырга тиешләр, ә аны санап вакыт әрәм итмәгәннәр, чөнки, әйтик 50 алтынга (1 кадак) төгәл 300 акча туры килә.

Реформадан соңгы акчаларның алтын системасы түбәндәге берәмлекләр белән күрсәтелергә тиеш булган:

1 алтын = 1,365 × 6 = 8,192 (2 мыскал, яки 6 ярмак);
2 алтын = 8,19 × 2 = 16,38 г (4 мыскал, яки 12 ярмак);
3 алтын = 8,19 × 3 = 24,57 г (6 мыскал, яки 18 ярмак);
5 алтын = 8,19 × 5 = 40,95 г (10 мыскал, яки 30 ярмак);
10 алтын = 8,19 × 10 = 81,9 г (20 мыскал, яки 60 ярмак);
15 алтын = 8,19 × 15 = 122,85 г (30 мыскал, яки 90 ярмак);
20 алтын = 8,19 × 20 = 163,8 г (40 мыскал, яки 120 ярмак);
25 алтын = 8,19 × 25 = 204,75 г (50 мыскал, яки 150 ярмак);
50 алтын = 8,19 × 50 = 409,5 г (100 мыскал, яки 300 ярмак).

Күпсанлы татар язма чыганаклары алтын системасының XIV гасырның акча әйләнешендә дә кулланылып килүе турында сөйли.

Реформа бакыр акчалар чыгаруга да исәпләнгән булган. Насир лид-динның XIII гасыр урталарында Мункә штемпеле өстәп сугылган акчалардан тыш, бакыр акчалар, ихтимал, XIII гасырның 90 нчы елларына кадәр чыгарылмагандыр. XIII гасырның 60 нчы елларында Ариг Буга каан исеменнән вак көмеш номиналлар сугылган. Ариг Бугадан башка хан исеменнән сугылган вак көмеш тәңкәләр мәгълүм түгел. XIII гасырга караган акчалар арасында кемнеке икәнлеген билгеләү кыен булган вак көмеш тәңкәләр очрый.

Реформадан соң бакыр акча чикләнгән күләмдә генә чыгарылганга охшый. Алар гадәттән тыш сирәк һәм монголларга кадәрге чорда Насир лид-дин исеменнән сугылган акчалар белән һич тә чагыштырырлык түгел. Бакыр акчаларның аз очравы аларның кулда бик чикләнгән санда йөрүен күрсәтә дип уйларга мөмкин.

Насир лид-дин алла исеме белән чыгарылган бакыр акчаларны реформадан соңгы чорга кертергә мөмкин.

Андый тәңкәләрнең алгы ягында гали тамга бар, аның әйләнәсенә «Насир лид-дин аллаһе» дип язылган. Арткы якта сугылу урыны Болгар шәһәре дип күрсәтелгән. Бу типтагы акчаларның датасы билгесез, ләкин алар Насир лид-дин алла исеме белән һиҗри 692 елда (1293) сугылган көмеш тәңкәләрне кабатлыйлар. Бу дата Тукта хан хакимлек иткән чорга караганлыктан, мондый язу Тукта ханның ләкабын (мөселман исемен) күрсәтә дип кенә аңлатырга мөмкин. Дөрес, XIV гасыр башына караган Тукта акчаларында ул Гиасетдин дип исемләнә, ләкин бу кушамат исемнәр бер-берсенә каршы килмиләр. Мәсәлән, Туктамыш ханның (1379—1395) акчалары арасында да Насир лид-дин һәм Гиасетдин исемнәре очрый.

Туктаның Насир лид-дин исеме куелган акчалары белән монголларга кадәрге чорга караган Насир лид-дин хәлиф акчалары арасында һичбер уртаклык юк. Монголларга кадәрге чор акчаларында Насир лид-дин исеменә «әмир әл-мөэмин» (мөселманнар әмире, хәлиф) сүзләре өстәлгән, моны инде А. Ф. Лихачев та күрсәткән иде. Моңардан тыш, Тукта акчаларының датасы куелган, аларда безгә яхшы таныш гали тамга бар. Димәк, Тукта ханның титулы яки мөселманча исеме Насир лид-дин күптән үлгән хәлифнең исеме була алмый һәм, А. Ф. Лихачев фараз иткәнчә, «аңлаешсыз анахронизм» да түгел.

Алтынчы бүлек

XIV ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА АКЧА-АВЫРЛЫК СИСТЕМАСЫ

«Сарай шәһәре — җир йөзендәге иң яңа шәһәрләрнең берсе, ул гадәттән тыш зурайган, халык белән тулы, матур-матур базарлары һәм киң урамнары күп... Сәүдәгәрләр һәм һәр ике Иракнан, Мисырдан, Сүриядән һәм башка җирләрдән килгән кешеләр исә аерым бер урында яшиләр, анда сәүдәгәрләрнең мөлкәтен диварлар саклый...»

Ибн Батута, сәяхәтче

1310—1311 ЕЛЛАРДАГЫ АКЧА-АВЫРЛЫК РЕФОРМАСЫ

1310—1311 еллардагы акча-авырлык реформасын үткәрү чоры экономик һәм политик үзәкнең Болгардан Түбән Идел буена күчү вакытына туры килә.

Мондый көчеш Тукта ханның феодаль сугышлар вакытында какшаган политик властьны үзәкләштерүенә бәйле. XIV гасыр башындагы бу мөһим вакыйгалар Түбән Идел буенда күпләп акча сугылуда чагылыш таба. Түбән Идел буе, хазар чорындагы кебек үк, дәүләтнең үзәгенә әйләнә. Кыпчак олысының экономик яктан алга киткән өлкәләре — Болгар, Хәрәзм һәм Кырым үзәктән бер чама ераклыкта һәм бердәй бәйле хәлдә калалар. Хан Болгар, Хәрәзм яки Кырым феодалларының йогынтысыннан чыга. 1310—1311 елгы акча-авырлык реформасы Сарай әл-Мәхрусада күпләп акча сугылудан башлана. Моңа кадәр чуалыш елларында әлеге өлкәләрдә аноним акчалар сугылса, тәхеткә Тукта хан утыргач (1291—1312), алар үз акчаларына аның исемен куйдыра башлыйлар.

1310—1311 елгы акча-авырлык реформасы бөтен дәүләтнең акча системасын унификацияләргә тиеш була.

Реформадан соң күмелгән хәзинәләрдә «иң өлкән» акчалар — Тукта ханның һиҗри 710 елда (1310/1311) сугылган акчасы. Туктадан соң хакимлек иткән Үзбәк яки Җанибәк ханнарның акчасы белән чагыштырганда Тукта акчаларының типлары аз санлы. Шуңа күрә реформадан соңгы беренче елларда акча сугу һәм акча әйләнеше, ягъни акча реформасының барышы безгә бик үк ачык түгел. Реформаны Тукта хан әзерли һәм беренче акчаларны да ул суктыра. Ләкин акча типлары күбрәк булырга тиеш иде, чөнки иске акчаларны тыйганнан соң, кыска гына вакыт эчендә, яңа акчаларны әйләнешкә кертеп җибәрергә кирәк, югыйсә иске акчаны тыюның мәгънәсе калмас иде. Әмма, инде әйткәнебезчә, акча типлары аз булган һәм ул акчалар тышкы яклары белән дә, авырлыклары белән дә реформага кадәр чорда аның исеменнән чыгарылган акчадан кискен аерылмыйлар. Тәҗрибәсез кеше яңа сугылган дирһәмнәрне ансат кына аера да алмаслык булгач, аның үзенең иске акчаларын нигә тыюы аңлашылмый.

Реформаның баштагы чорында акча сугуны түбәндәгечә аңлатырга мөмкин.

1310—1311 елгы бу реформа гадәттән тыш шартларда үткәрелә, Тукта заманында акча сугу сарае һәм бөтен административ аппарат Болгардан Сарай әл-Мәхрусага күчерелә һәм Тукта хан иске акчаларны, шул исәптән үз исеме белән сугылганнарын да, тыю өчен

тулы мөмкинлек ала. Реформадан соң беренче акчалар Сарай әл-Мәхрусада чыгарыла. Кама буеның утрак тормышлы төбәкләре белән чагыштырганда, Түбән Иделдә товар-акча мөнәсәбәтләре азрак үскән булган һәм, ихтимал, шуның аркасында реформадан соң чыгарылган азсанлы акчалар да канәгатьләндергәндер. Тукта ханның үлүе (һиҗри 710 ел) реформаны ахырынача җиткерергә комачаулый. Реформа Үзбәк хан заманында дәвам иттерелә, аның исеменнән акча инде күп кенә шәһәрләрдә сугыла, өстәвенә әйләнешкә күпсанлы бакыр акчалар да кертеп җибәрелә. Шуның белән бергә, авырлык ягыннан да, исәп ягыннан да акча системасының тагы да унификацияләнүе күзәтелә.

Идел буенда XIV гасырның беренче яртысына караган акча хәзинәләре күп табылган. Акча суктырган ханнар һәм шәһәрләр исеме буенча алар стандарт диярлек. Реформадан соң сугылган акчаларның авырлык нормасын билгеләү өчен ике хәзинәне күздән кичерик.

232 данә татар акчасыннан торган беренче хәзинә Болгарда 1965 елда табылды.

Хәзинәдә Тукта хан (1291—1312) акчалары иң борынгылары, ә Җанибәк хан (1342—1357) акчалары иң соңгылары. 2 нче таблицада хәзинәдәге акчаларның хан исемнәре һәм сугылган шәһәрләр буенча бүленеше китерелә.

2 нче таблица

Ханнар	Акчада күрсәтелгән сугу үзәкләре				Билгесезләр	Гомуми саны
	Сарай әл-Мәхруса	Сарай	Сарай әл-Җәдид	Болгар әл-Мәхруса		
Тукта (1291—1312)	15 (һиҗри 710)	—	—	—	—	15
Үзбәк (1312—1342)	6 (һиҗри 722)	41 (731, 734, 740)	—	139 (723, 731, 732—733)	—	186
Җанибәк (1342—1357)	—	—	30 (743, 744, 745, 746, 747, 748, 750)	—	—	30
Хулагуидлар	—	—	—	—	1	1

XIV гасырга караган татар көмеш тәңкәләреннән торган хәзинә дә Болгар шәһәрлегендә табыла. Ул хәзер Татарстан Дәүләт музеенда 34423 инвентарь номеры белән саклана. Хәзинәдә 382 көмеш тәңкә бар, алар, беренче хәзинәдәге кебек үк, Идел буенда 1310—1311 елларда үткәрелгән акча реформасыннан соңгы беренче чорга карыйлар.

Хәзинәдәге акчаларның хан исемнәре һәм шәһәрләр буенча бүленеше 3 нче таблицада күрсәтелгән.

Таблицалардан күренгәнчә, Идел буенда Тукта ханның реформадан соңгы акчалары Сарай әл-Мәхрусада гына сугылган. Үзбәк хан заманында, Сарай әл-Мәхрусадан башка, акча Сарайда, Болгар әл-Мәхрусада һәм Мукшыда да чыгарыла. Бу исә реформага кадәрге акча тыелгач, әйләнешкә яңаларын тизрәк кертү өчен аларны күпләп сугарга кирәк булуы белән аңлатыла. Акча товар-акча мөнәсәбәтләре яхшы үскән һәм халкы акча белән яхшы таныш булган шәһәрләрдә сугылган дип уйларга кирәк.

Сарай әл-Мәхрусада сугылган акча белән чагыштырганда, Сарай һәм Болгар акчасының күбрәк булуы бу чордагы ниндидер политик каршылыклар турында сөйли. Билгеле булганча, Үзбәк тәхеткә Хәрәзм феодаллары ярдәме белән утырган. Ул хан булгач, Хәрәзм юлы өстендә урнашкан башкала Сарай әл-Мәхрусада сугылган акчаның күбәюен көтәргә мөмкин иде. Идел буйлап югарыдарак урнашкан икенче Сарайда сугылган акчаның күбрәк булуына карагандa, моның киресе күзәтелә. Күрәсең, Үзбәк, Сарай әл-Мәхруса яки Хәрәзм феодалларының басым ясавыннан шикләнеп, башкаланы Сарайга күчергәндер. Аның мондый карарга килүе Сарай һәм Болгар феодаллары йогынтысында булырга да мөмкин. Болгар феодалларының көче һәм тоткан урыннары турында Болгар акча сугу сараенда чыгарылган акчалар саны гына түгел, бәлки, табылган хәзинәләргә карап фикер йөрткәндә, Сарайда чыккан акчаларның шактый өлеше Урта Иделнең утрак тормышлырак төбәкләренә китүе дә сөйли. Хәрәзм яки Кырым белән чагыштырганда, Идел буендагы барлык шәһәрләр өчен акча сугуда бердәм авырлык нормасы булуы да алар арасында тыгыз экономик элемтәләр яшәвен күрсәтә.

Болгарда бу чорда чыккан акчаларга «имин», «иминлеге тәэмин ителгән» мәгънәсендәге «әл-Мәхруса» эпитеты куела башлый.

34423 номерлы хәзинәдәге акчаларның ханнар һәм шәһәрләр буенча бүленеше

Ханнар	Акчада күрсәтелгән сугу үрнәкләре									
	Сарай әл-Мәхруса	Срай	Сарай әл-Җәдид	Гөлстан	Гөлстан шәһәре	Болгар әл-Мәхруса	Мукшы	Хәрәзм	Билгесез	Барысы
Тукта (1291—1312)	48 (һиҗри 710)	—	—	—	—	—	—	—	—	48
Үзбәк (1312—1342)	15 (һиҗри 722)	81 (һиҗри 716—739)	—	—	—	94 (һиҗри 723—732)	1 (һиҗри 724)	—	5	196
Җанибәк (1342—1357)	5 (һиҗри 749)	—	120 (һиҗри 742—752)	7	—	—	—	1 елы?	—	133
Бирдебәк (1357—1359)	—	—	—	—	1 (һиҗри 759)	—	—	—	—	1
Хызыр (1362)	—	—	—	—	1 елы?	—	—	—	—	1
Би[illegible]	—	—	—	—	—	—	—	—	—	3

«Әл-Җәдид» — «яңа» эпитеты Сарай акчаларында беренче тапкыр Җанибәк ханлык иткән вакытта күренә. Гөлстанда сугылган акчалар арасында да шундый ук нәрсә күзәтелә. Әгәр Җанибәк заманында ул Гөлстан дип кенә билгеле булса, Бирдебәк һәм Хызыр вакытында «Гөлстан шәһәре» дип күрсәтелә. Үзбәк ханның акча суккан урыны Сарай әл-Җәдид дип күрсәтелгән дирһәмнәре сирәк очрый һәм алар, бик ихтимал, анахронизм гына булыр. Ләкин Үзбәкнең акча сугу урыны Сарай әл-Җәдид дип күрсәтелгән бакыр акчалары да бар, алары турында без бераз соңрак сөйләрбез.

Хәзинәләрдәге акчалар, башлыча, өч ханга: Туктага, Үзбәккә һәм Җанибәккә туры килә.

Үзбәк һәм Җанибәк дирһәмнәренең авырлык диаграммалары Үзбәк дирһәмнәре өчен 1,47—1,49 г, ә Җанибәк дирһәмнәре өчен 1,52—1,55 г лы сугылу нормасын күрсәтәләр.

Тукта хан акчаларын өйрәнгәндә аларның кулданкулга 50 елдан артык йөреп кыршылуын, авырлыгы кимүен күз алдында тотарга туры килә. Үзбәк һәм Җанибәк акчалары белән эш башка. Мәсәлән, Үзбәк ханның (34423 номерлы хәзинә өчен) датасы яхшы билгеләнгән һәм һиҗри 734 елга караган 12 данә акчасы түбәндәге авырлыкта: 1,16 г — 1; 1,27 г — 1; 1,45 г — 1; 1,49 г — 3; 1,50 г — 1; 1,52 г — 1; 1,53 г — 2; 1,54 г — 1; 1,57 г — 1, ә Җанибәкнең һиҗри 742 елда сугылган 12 акчасы (данәләр санының туры килүе очраклы гына) түбәндәге авырлыкта: 1,52 г — 2; 1,53 г — 4; 1,54 г — 2; 1,55 г — 2; 1,57 г — 1; 1,58 г — 1. Бу акчаларның әйләнештә йөрүе арасындагы аерма сигез ел гына, хәлбуки аларның авырлыкларындагы аерма күзгә ташланып тора: Җанибәк акчасы авыррак.

Тукта хан акчаларының тышкы күренешенә анализ ясау аларның хәзинәдәге башка акчалар белән бер дәрәҗәдә шомарганлыгын күрсәтә. Гадәттә акчаның язуы ашала. Тукта хан акчасында бу нәрсә күзәтелми, димәк, үлчәнгән акчаларның авырлык күрсәткечен арттыру өчен ныклы нигез юк. Туктаның һиҗри 710 елда Сарай әл-Мәхрусада сугылган 63 данә акчасын үлчәгәч, 1,40 — 1,50 г лы акчаларның иң күп (44 данә — 69%) булуы күренә, ә графиктагы пик 1,47 г лы 10 данә акчага туры килә.

Бу мәгълүматлар реформадан соң сугылган авырлык нормасын реконструкцияләргә мөмкинлек бирә-

ләр. Күрәсең, акча 4,464 г лы кануни мыскал исәбеннән сугылгандыр. 21 кануни мыскалның авырлыгы акча системасына Беркә хан керткән 4,68 г лы 20 Мисыр мыскалы авырлыгына туры килә.

Реформадан соңгы акчалар 446 г лы 100 мыскалдан 300 данә акча исәбеннән сугылганнар (446 : 300 = 1,486). Акчаларның теоретик һәм реаль авырлыгы арасында килеп чыккан аз гына аерма Тукта акчаларының күпме ашалып шомаруын күрсәтә (1,486—1,47 = 0,016).

Нумизматик әдәбиятта 1310—1311 елгы акча-авырлык реформасына зур әһәмият бирелә. Чыннан да, Тукта ханның эшчәнлеге дәүләтне үзәкләштерүдә генә түгел, бәлки акча системасын бердәйләштерүгә дә юнәлтелгән була. XIII гасырның 90 нчы елларында ук ул үткәргән акча-авырлык реформасы Кыпчакның башка өлкәләренә кагыла. Хәрәзм, Болгар һәм Кырым акчаларында бер ханның исеме куела башлый. Шунысы игътибарга лаек, 1290 елгы реформа акча системасын бердәйләштереп кенә калмый, бәлки әйләнешкә ваграк номиналлар — бакыр акчалар да кертә. Бу исә XIII гасыр ахырына Идел буе шәһәрләренә монгол яулары китергән зыяннан соң аларның кабат аякка басуларын һәм биредә ваклап сату эшенең үсеш алуын күрсәтә. Ләкин халык күнекмәгән бакыр акчалар киң тарала алмаганнар, аларның аз очравы шул турыда сөйли. 1310—1311 елгы реформа нык уйлап эшләнгән һәм бакыр акча чыгаруны да күздә тоткан булырга тиеш. Тик реформа елында ханның үлеп китүе реформа барышына комачаулый. Шул сәбәпле 4,46 г лы мыскал системасы киң таралып китә алмый. Ләкин XIV гасыр башындагы акча-авырлык реформасы акча-авырлык системасының алга таба үсеше өчен җирлек хәзерли.

Акча-авырлык системасының алга таба үсеше Үзбәк хан (1312—1342) исеме белән бәйле. Аның заманында акча инде башка авырлык нормасы буенча сугыла һәм күпсанлы бакыр акчалар — пуллар чыгарыла башлый.

ҮЗБӘК ХАН ЧОРЫНДА (1312—1342) АКЧА-АВЫРЛЫК СИСТЕМАСЫ

Кыпчак илендә товар-акча мөнәсәбәтләренең чәчәк атуы һәм шәһәрләрнең гөрләп үсүе Үзбәк ханлык иткән чорга туры килә. Ул 30 ел буена властьны үз ку-

5 нче рәсем. Яңа Сарайда казу эшләре.

лында тота һәм дәүләт идарәсен тагы да үзәкләштерә, урыннарда власть органнарын һәм, димәк, халыктан ясак җыюны да тәртипкә сала [1].

Иртыш ярларыннан алып Уралга кадәр бөтен Көнбатыш Себерне, аның гаять зур ресурсларын Кыпчак иленә кушу зур әһәмияткә ия була. Элегрәк — XIII гасырда да, соңрак — XIV гасыр азагында яки XV гасырда да Идел буе, XIV гасырның беренче яртысындагы кебек, көмеш тәңкәләр һәм бакыр акчаларның мондый муллыгын белми.

Политик үзәкнең Урта Иделдән Түбән Иделгә күчүе бу төбәкнең экономик яктан ныгуына булышлык итә.

[1] Сафаргалиев М. Г. Күрсәтелгән хезмәт, 68—69 битләр.

XIV гасырның беренче яртысында биредә Сарайчык, Хаҗитархан, Барчин, Үкәк, Самар кебек татар шәһәрләре һәм Сарай әл-Мәхруса һәм Сарай әл-Җәдид кебек Көнчыгыш Европада иң зур шәһәрләр калкып чыга. Соңгысы венецияле Фроа Мауро картасында Бөек (грандо) Сарай һәм Сарай дип билгеләнгән. Дөньяның күп кенә шәһәрләрендә булган һәм Үзбәк хан заманында 1333 елда Кыпчакның башкаласына килеп чыккан гарәп сәяхәтчесе Ибн-Батута аны түбәндәгечә тасвир итә: «Сарай шәһәре — җир йөзендәге иң яңа шәһәрләрнең берсе, ул гадәттән тыш зурайган, халык белән тулы, матур-матур базарлары һәм киң урамнары күп...»

Үзбәк чорында феодаль аристократия зур политик йогынты белән файдалана һәм дәүләт эшләрендә катнаша. Аерым алпавытларның урта бер җирендә колонналы сарайдан, бакчадагы ябык верандадан, бассейннан һәм үзләренә бәйле хәлдәге кешеләрнең йортларыннан торган бай утарлары аларның иҗтимагый хәлен ачык сурәтли. XIV гасырда яшәгән татар шагыйре Хисам Кятибның «Дастан Җөмҗөмә» дигән поэмасында аның каһарманы башкала мөгаззәмдә төзегән сарайларның берсе түбәндәгечә тасвир ителә:

Янә бер сарай итмеш ирдем анда мән
Тулы күләме ун мең ирде, и хәкәм.
Тышыннан күргәннәр «һәйбәт!» дир иде,
Эченә кергәннәр «җәннәт!» дир иде.
Өстенә менгән бөгелер иде мөгәр,
Юхса, торса башы болытка тигәр.

XIV гасырга инде монгол яулары турында күңелсез хатирәләр генә калган. Хисам Кятиб шул ук поэмасында Чыңгыз, бу дөньяның башка кайбер бөек кешеләре кебек үк, канлы былчырак эчендә ята, дип белдерә. Ханга хезмәт иткән монгол чиновникларын халык өнәмәгән. Икенче бер Котб дигән шагыйрь Үзбәк ханның улы Тинибәккә багышланган «Хөсрәү һәм Ширин» поэмасында яман кешене монгол чиновнигы белән чагыштыра:

Мунгал тик, өй бирер булсаң, теләр бал,
Күңел бирсәң, җан алмакка килер ул.

Шәһәрләр тирәсендә көтүлекләр генә түгел, бакчалар, сугару системалары һәм иген басулары да булган. Шагыйрь Сәйфи Сараи бодай өлгергән җәйге чорның хозурлыгы турында яза. Бу чордагы кыпчак те-

ленең сүзлек фондында тимер сабан гына түгел, сабанцы, сабан сөрмәк, сабан ери (уҗым басуы) кебек «сабан» сүзеннән ясалган сүзләр дә киң кулланыла. Төрле игеннәрнең исемнәре (богдай, тары, арпа, борцак, орлык-җитен), тегермән һәм тегермәнце сүзләре, шулай ук кәрпиц, калай кебек төзү материалларының атамалары һ. б. очрый.

Урта Идел буе да үзенең әһәмиятен югалтмый. Урта Идел буеның, шул исәптән Болгарның да шәһәр культурасы чәчәк аткан чор XIV гасырның беренче яртысына туры килә. Урта Идел буе, Кырым һәм Хәрәзм белән беррәттән, дәүләтнең экономик яктан алга киткән көчле үзәкләреннән берсе була. Ул Түбән Иделне икмәк, бал, затлы җәнлек тиреләре, агач материалы белән тәэмин итә. Риваятьләргә караганда, Җанибәк һәм аның улы Бирдебәк хан заманнарында салчылар салларын Әстерханга кадәр озата барганнар. Яхшы сыйфатлы йомшак күн — юфтьнең монгол, тибет, венгр, румын һ. б. телләрдә «болгари» дип аталуы Болгарның тышкы сәүдә бәйләнешләре турында сөйли. Түбән Идел буенда сугылган акчаларның байтак өлеше Урта Идел буенда табылу да очраклы гына түгел.

Аерым алпавытларның еллык килере шактый сумага — 100 меңнән алып 200 мең динарга җиткән (1 динар 6 көмеш тәңкәдән торган!). Киң тышкы сәүдә элементләре акчасыз исәп-хисап һәм сәүдә ширкәтләре («уртаклыклар») килеп чыгуга булышлык иткән. XIV гасыр кыпчак сүзлегендә күчмә мирасны залогка алып акча биреп торучы оешманы белдергән итальян сүзе «ломбард» та очрый.

Акча сугу сарае чыгарган акчаларның төп массасына сәүдәгәрләр заказ биргән. Акча сугу ирекле булган. XIV гасырның беренче яртысында Флоренция финансисты Франческо Пеголоттиның хәбәр итүенә караганда, коелма хәлендәге көмеше булган һәркем сарайда акча суктыра алган. Яңа сугылган акчаның билгеле бер өлеше акча сугу сарае файдасына калган һәм эш өчен түләүгә киткән. Пеголоттиның сөйләгәннәре Азак (Азов) шәһәрендәге акча әйләнешенә кагыла, ләкин бөтен Кыпчак илендә шушындый ук хәл булган дип уйларга кирәк. Көмеш коелмаларны Пеголотти «соммо» дип атый, бу исә итальян теленә кергән татар сүзе «сом» («сум»). Бу сүз борынгы төрки телендә теркәлгән.

Идел буенда «сом» сүзе ике мәгънәдә: коелма (алтын, көмеш яки бронза) һәм билгеле бер суммадагы акча мәгънәсендә кулланылган, ягъни сом акча һәм исәп берәмлеге булган. Пеголотти язмасыннан күренгәнчә, ул «сом» атамасын кулланганда, сүзнең нәрсә турында баруына карап, коелманы яки акча суммасын күздә тота. Шуның белән бергә, Пеголотти сом коелмасының авырлыгына һәм мыскалның күләменә карата мөһим мәгълүматлар китерә, һәм болар Үзбәк хан заманындагы акча-авырлык системасы турындагы белемнәребезне тулыландырырга мөмкинлек бирәләр.

Югарыда без Үзбәк хан акчасының Тукта акчасына караганда авыррак, ләкин Җанибәк акчасыннан җиңелрәк булуын әйткән идек инде. 1965 елгы Болгар хәзинәсендәге Үзбәк ханның 1,40 г нан җиңелрәк булган тулы авырлыктагы акчалары 5% чамасы, ә 1,50 г нан авырраклары 62% тәшкил итә. 34423 номерлы хәзинәдә Җанибәкнең 1,40 г нан җиңелрәк булган тулы авырлыктагы акчалары 3% кына, ә 1,50 г нан авырраклары 84% ка җитә. Үзбәк хан акчаларының яртысы (89 данәсе) 1,50 — 1,54 г нар арасында тирбәлә, димәк акча сугуның авырлык нормасы да шушы чикләр эчендә булырга тиеш.

Үзбәк хан акчалары сугылган мыскал исәбенең зурлыгын безгә Пеголотти хәбәре төгәлрәк белергә ярдәм итә. Аның сүзләренә караганда, соммо коелмасы — көмеш сом 45 мыскалга (саджо) тигез. Пеголотти мәгълүматларын чагыштырып, Г. А. Федоров-Давыдов соммоның авырлыгы 204,75 г га тигез дип таба. Бу — Идел буенда 1310—1311 еллардагы реформага кадәр яшәп килгән 409,5 г лы кадакның яртысы. Мондый авырлыктагы коелмалар булганлыгын табылдыклар да раслый. Татарстан Дәүләт музеендагы көймә рәвешле 11 данә көмеш сомнарның авырлыгы 192,82; 195,3 г; 197 г; 198,5 г; 200,15 г; 201,4 г; 202,15 г; 203,4 г; 203,82 г; 206,1 г; 206,1 г.

Бу очракта Үзбәк чорындагы мыскал 4,55 г тәшкил итәчәк (204,75 : 45=4,55). Әгәр тулы авырлыктагы 3 татар акчасының авырлыгы һәрвакыт мыскалга тигез булуын искә алсак, Үзбәк хан акчаларының авырлык нормасы 1,52 г чамасы булачак (4,55 : 3=1,52). Бу 1965 елгы болгар хәзинәсендәге акчаларның авырлыгына туры килә.

Теоретик күзлектән караганда, акча авырлыгының нигезен 0,19 г лы кират тәшкил иткән булырга тиеш.

4 кират 0,76 г лы дәник тәшкил иткән, 2 дәник 1,52 г лы тәңкә, ә 3 тәңкә 4,56 г лы мыскал тәшкил иткән.

1 ярмак ... 0,76 × 2 = 1,52 г
3 ярмак ... 1,52 × 3 = 4,56 г (мыскал)
6 ярмак ... 1,52 × 6 = 9,12 г (алтын, динар)
120 ярмак ... 1,52 × 120 = 182,4 г (исәп сомы)
120 ярмак = көмеш сом (204, 75 г)
300 ярмак ... 1,52 × 300 = 456 г(кадак)

Мондый акча-авырлык системасының гамәлдә булганлыгын табылган герләр дә раслый. Мәсәлән, Сарай әл-Җәдид хәрабәләрендә 455,6 г авырлыктагы сигез кырлы бакыр гер табылды. Сарай әл-Җәдидтән 37,4 г лы гер дә билгеле (теоретик яктан 38 г лы, ягъни 456 г лы кадакның 1/12 өлеше).

Бу системада иң кечкенә авырлык фракциясе — 0,19 г лы кират. 24 киратның авырлыгы 4,56 г лы мыскалны тәшкил итә. Тагын бер берәмлек — 4,75 г лы өлеш тә булган, аның нигезендә дә шул ук кират ята, ләкин ул 25 тапкыр алына (0,19×25=4,75 г). Өлеш 1/96 кадакка тигез (456 : 96=4,75 г). 4,75 г лы 100 өлешнең авырлыгы мөстәкыйль фракция — 475 г лы ритлны тәшкил итә. Азактагы ритлны (руотоли) башка илләрдәге авырлык берәмлекләре белән чагыштырганда, Пеголотти нәкъ шушы зурлыкны күздә тота. Пеголотти Азактагы акча әйләнешенең кайбер детальләрен дә хәбәр итә: «Танада (Азакта) сомнар һәм көмеш аспрлар кулда йөри һәм сомга 45 Тана саджосы керә һәм эретмәдә 11 унция һәм 17 динар авырлыктагы саф көмеш бар. Һәм берәрсе Танадагы акча сугу сараена көмеш китерсә, әйтелгән сомнарның һәркайсысыннан сарайда 202 аспр ясалса да, кешегә 190 аспр гына бирелә, ә калдыгы эш өчен һәм акча сугу сараеның файдасына китә. Шул рәвешле 190 аспр бәясе буенча Тана сомына тиңләштерелә».

Димәк, коелма сомга тиңләштерелгән шушы 190 аспр исәп сомын тәшкил итә. Азакның сакланган акчаларының авырлыгы 1,1 г чамасы. Күрәсең, аларны сугуда авырлык нормасы 0,96 г булган. 190 аспрның авырлыгы 182,4 г, ягъни исәп сомы авырлыгын тәшкил итә (190×0,96=182,4 г), ул исә башка чыганаклардан билгеле булган Идел буе сомына бәрабәр.

Үзбәк ханның замандашы фарсы тарихчысы Вассаф түбәндәгеләрне яза: «Аннары ул (Үзбәк) мәчет әһелләренә саф көмештән 50 коелма бүләк итте, сом

6 нчы рәсем. Яңа Сарай кирпечләреннән төзелгән хәзерге заман йорты.

дип атала торган коелмаларның ике ягында да колаклар бар. Һәр сом кулда йөри торган 20 динар акчага тигез». Вассафның «колаклы сомнары» баш-башлары очлаеп килгән көймә рәвешле коелмалар булырга охшый. Вассаф коелмаларның авырлыгы хакында берни әйтмәсә дә, аларның кулда йөри торган акча исәбендәге бәһасенә карата кызыклы мәгълүмат бирә. Вассаф сүзләренә караганда, сом кулда йөри торган 20 динар акчага тиң. Әгәр аның авырлыгын Үзбәк ярмаклары буенча алсак, теоретик яктан, исәп сомының авырлыгы $20 \times 9,12 = 182,4$ г була. Моннан 1 сомның 120 акчага тигез булуы ($1,52 \times 120 = 182,4$ г) һәм аның авырлыгы, тулаем алганда, Азакта да, Идел буенда да даими булуы килеп чыга.

Үзбәк хан бүләк иткән 50 сом коелманың кулда йөри торган акчалата исәбе 1000 динар тәшкил итә (20×50=1000). Түгәрәк кенә сума, чын мәгънәсендә падишаһ бүләге бу!

Борынгы татар әдәбияты әсәрләре акча исәбе системасын һәм гамәлдәге терминнарны күз алдына китерергә мөмкинлек бирәләр. Түбәндә без Мәхмүд бин Гали ас-Сараи әл-Болгариның 1358 елда язылган һәм безгә 1361 елгы күчермәсе килеп җиткән «Нәхҗ әл-Фарадис» китабыннан «Шәех белән казый» хикәясенең өзеген китерәбез:

«Андин соң (шәех) әйде:

— И казый! Сән бу хәлаек (халык) арасында кем, хөкем кылырсың һич дөньяви нәрсә алурмусән? — тиде ирсә,

7 нче рәсем. Иске Сарайда остаханә урынын казу вакыты.

Казый әйде:

— Ришвәт алмасмын. Вәликин ике хәсым (дәгъвачы) арасында хөкемне катыг кылсам, араларында бер хат бетермен кем: «бу көндин соң бере береңезнең һич дәгъваңыз, тәкый хосүмәтеңез (дәгъвалашуыгыз) булмасын тип әйде ирсә,

Шәех әйде:

— Бер хатка нә кадәр нәрсә бирерләр? — тиде ирсә,

Казый әйде:

— Мөнгыйм (юмарт) кем ирсәләр булсалар, ун алтын алырмын, я тәкый биш алтын алырмын. Азрак бирсәләр, ике алтын бирер,— тиде ирсә,

Шәех әйде:

— Үнгин кем ирсәләр ул микъдар нәрсә бетмәк өчен ни микъдар өҗрә (эш хакы) алгайлар ирде?

Казый әйде:

— Бер ярмак, я тәкый хабба (пул) алгай ирделәр,— тиде ирсә,

Шәех әйде:

— Син халән (хәзер генә) әйдең, ришвәт алмасмын тип, бу ришвәт булмасмы кем, бер ярмак тикнәз йирдә ун алтын алсаң? Нәтәк кем мондаг харамны үзеңә рәва күрерсән, монча гыйлем хасил кылганның файдасы нә торыр кем, аның белән гамәл кылмас булгач? — тип вәгаз-нәсыйхәт кылды ирсә, шәех сүзе казыйга олуг әсәр кылды. Күзендин катрат вә габрәт (тамчы-тамчы) яшьләр актырды. Тәкый тәүбә кылды».

Биредә барлык акча терминнары һәм акча исәбе санап чыгыла диярлек (хабба — пул, ярмак — көмеш тәңкә, 1,2, 5 һәм 10 алтын). Шәех нәсихәтеннән соң казый чыннан да изге юлга баскандырмы-юктырмы, без бу мәсьәләгә кагылып тормабыз, ләкин шәехнең ачуын аңларга мөмкин. Төрле документлар төзегән өчен, казый клиентларыннан 10 алтын кадәр, ягъни 60 көмеш тәңкә алган. 60 ярмакның бәһасе зур. Ибн Батута (1304—1377): Идел буенда «...менә дигән атның бәясе шундагы 50 яки 60 дирһәм...» — дип яза.

КӨМЕШ ТӘҢКӘЛӘРНЕҢ АВЫРЛЫГЫН АРТТЫРУ

Тукта хан 1310—1311 елларда үткәргән акча реформасыннан соң чыгарылган акчаларның авырлыгы элеккеләренә караганда арттырыла. Үзбәк заманында авырлык тагы да арта төшә. Безнең карашка, мондый күренеш хөкүмәтнең дәүләт күләмендә товар алмашын

яхшыртырга һәм чуалыш елларында Кыпчакның тыныч сәүдә багланышларын ныгытырга омтылуы белән аңлатыла.

Идел буе шәһәрләрендә акча бердәм авырлык нормасы буенча сугылган. Табылган хәзинәләргә карап фикер йөрткәндә, бер шәһәр акчасының икенче шәһәргә үтеп керүе, тулаем алганда, ике яклы булган. Ләкин Хәрәзм яки Азак кебек читтәге шәһәрләрдә акча башка авырлык нормасы буенча сугылган. Ә Үзбәк ханның бу шәһәрләргә дә хуҗа булганлыгы яхшы билгеле. Һәм акча сугудагы мондый мөстәкыйльлек хөкемдарны борчымаган, чөнки акча-авырлык системасы шул ук Идел буе дәнигенә, мыскалга яки сомга нигезләнгән булган.

Хөкүмәтне башка нәрсә, атап әйткәндә, илнең төрле өлкәләрендә һәм төрле дәүләтләрдә затлы металларның бәясендә аерма булу аркасында, сәүдәгәрләрнең акчаны товарга әйләндерә алулары борчый. Күрәсең, акчаны, Идел буе һәм Төньяк Кавказ шәһәрләреннән тыш, бүтән шәһәрләргә чыгару фәрман белән тыелган. Һәрхәлдә, Идел буенда сугылган акча хәзинәләре Идел бассейныннан көнбатышта да, көнчыгышта да чагыштырмача сирәк табыла. Акчаны читкә чыгару нормаль товар әйләнешен бозарга мөмкин булган. Рәшид әд-дин, Иранда нәкъ менә шундый ситуацияне күздә тотып, түбәндәгеләрне язган: «Сәүдәгәрләр товарны азрак сатып ала башладылар, чөнки акчаны бер җирдән икенче җиргә күчергәндә артыклык килеп чыга һәм, авырлыкта аерма булу аркасында гына да, алар җиңел табыш алалар. Кайбер өлкәләрдә товарга сорау юк, ә кайберләрендә аны табып булмый».

Закон көмеш сомнарның әйләнештә йөрүен тыймаган, шуңа күрә һәркем көмеш акчасын сомнар итеп эретеп коя алган. Ләкин дәүләт штемпеле сугылган акча эчке сәүдәдә, гади коелмага караганда, кайбер өстенлекләргә ия булган. Шуңа күрә әйләнештәге акчалар сомы, җиңелрәк булса да, бәясе белән коелма сомга тиңләштерелгән. Әгәр көмеш тәңкәләр курсы төшә калса, коелма сомга караганда артык очсызланган көмеш тәңкәләрне әйләнештән алып, сомнар итеп койганнар. Ләкин коелмадагы көмешнең курсы көмеш кытлыгы вакытында күтәрелергә дә мөмкин булган.

Акча-авырлык өлкәсендә хөкүмәт керткән үзгәрешләр чыгарыла торган акчаның авырлыгын арттыруда

чагылган һәм акчаны бозуга каршы торуны максат итеп куйган. Кулындагы тәңкәләрне сом итеп койганга кадәр сәүдәгәр тәңкәләрнең өстенлегеннән коры калмам микән? дип уйларга тиеш булган, чөнки коелма сомның авырлыгы даими калган. Мәсәлән, реформага кадәр 163,5 г авырлыктагы тәңкәләр сомы 204,75 г лы коелма сомга бәрабәр исәпләнгән. Тукта хан 1310—1311 елларда үткәргән акча-авырлык реформасыннан соң, 120 данә тәңкә санындагы сомның авырлыгы 178,3 г га кадәр, ә Үзбәк хан чорында 182,4 г га кадәр арта. Ләкин, Пеголотти хәбәр иткәнчә, коелмалар тиешледән җиңелрәк булган очракта, өстәп акча түләгәннәр.

Шулай итеп, акча сугуның авырлык нормасы аз үзгәртелгән, ул иске акчаларны әйләнештән чыгаруга (тыюга) бәйләнмәгән һәм, димәк, исәпләү сомының курсын күтәрү акчаның эретеп көмеш коелмалар рәвешендә кеше кулында тезаврацияләнүенә каршы торырга тиеш булган.

Тәңкәләрнең авырлыгын арттырып сугу акчаны әйләнештән алып чит илгә чыгаруны кисәтү ягыннан да әһәмиятле булган. Андый куркынычны тышкы сәүдә багланышлары тудырган. Күрше илләрдә алтын исәбендә арзанрак бәяләнгән көмеш коелма сомнар рәвешендә чит илгә киткән. Үзбәк хан заманындагы тышкы политик шартлар тышкы сәүдә элемтәләренең үсешенә булышлык иткәннәр. Дөрес, 1329 елда Рим папасы Көнбатыш Европа хөкүмәтләренә татарларга каршы «тәре походы» оештырырга чакырып, махсус хат белән мөрәҗәгать итә. Ләкин тәре походы оешмыйча кала.

Үзбәк хан Мисыр белән генә түгел, Италия белән дә яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыра. «Акылы, күркәм кыяфәте һәм сыны белән аерылып торган» [1] бу хан башка дәүләтләр белән дипломатик никах элемтәләре урнаштыру юлын да тота. Гарәп һәм Византия сәүдәгәрләре һәм сәяхәтчеләре әлеге дәүләтләр белән ныклы сәүдә багланышлары булуын хәбәр итәләр.

Урта Азия, Кытай һәм Һиндстан шәһәрләре белән зур күләмле сәүдә операцияләре башкарылган. Ибн Батута сүзләренә караганда, Болгардан Һиндстанга, Кытайга һәм Иранга ул илләрдә бик кыйбат йөргән зат-

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, I том, 206 бит.

лы җәнлек тиреләре, икмәк, шәрап, тукымалар, келәмнәр, көмеш, атлар һәм мөгезле эре терлек озатылган.

XIV гасыр урталарына Идел буе шәһәрләре зур үсешкә ирешәләр. Алардан авыл хуҗалыгы продуктлары гына түгел, шәһәр һөнәрчеләре җитештергән товарлар да чыгарылган булырга тиеш.

Археологик казу эшләре күрсәткәнчә, шәһәрләрнең үзәк районнарын күпсанлы һөнәрчелек мәхәлләләре әйләндереп алган була. Анда тукучылар, ювелирлар, тимерчеләр, корал ясау осталары, кирпеч сугучылар, савыт-саба ясаучылар яшәгән. Хезмәт бүленеше дә шактый үсеш алган. Әйтик, бер кирпечче кызыл кирпеч суккан, икенчесе аны эре комлы ак балчыктан җитештергән. Мондый кирпечкә махсус мичтә зәңгәр, ак, сары, яшел, бирүзә, көрән һ. б. төсләрдәге эретелгән крәч йөгерткәннәр. Алардан төрле бизәкләр яки аршын буе хәрефләр җыеп, зур биналарның стеналарын бизәгәннәр. Археологик казулар вакытында хәзерге домналар системасын хәтерләткән һәм урта гасырлар өчен шактый үсеш күрсәткече булырлык чуен кою мичләре дә очрый.

Татар осталарының товарлары чит илдә югары бәяләнгән. Мәсәлән, Үзбәк хан Мисыр солтанына, башка бүләкләр белән бергә, көбә күлмәк (кольчуга), булат шлем һәм кылыч җибәргән. «Элек бер генә патшаның да мондый яхшы нәрсәләр җибәргәне юк иде»,— дип яза Ибн Дукмак [1].

Ләкин Үзбәк хан тәхеткә утырган вакыттан алып диярлек Тимер Капка һәм Азәрбайҗан өчен Иран белән бәрелешләр булып торган. «Болар (хулагуидлар) синең һәм безнең дошманыбыз һәм без (барлык бу) җирләр бер җир булсын өчен, бу дошманны үзебезнең арадан куарга ниятлибез»,— дип яза ул Мисыр солтанына. Иран Үзбәк хан биләмәләренә көньяктан турыдан-туры куркыныч тудырган.

Бу көрәш яу чабулар төсендә генә булмыйча, экономик характерда да булган, күрәсең. Югарыда татар товарлары арасында көмеш тә санап кителгән иде. Аның читкә чыгуын хөкүмәт хупламаган булырга тиеш. Тукта, Үзбәк һәм шулай ук Җанибәк заманнарында финанс эшләрен идарә итүче дәүләт чиновникларының эшчәнлеге бу кыйммәтле металлны дәүләт

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, I том, 298 бит.

эчендә калдыруга юнәлтелгән булган. Идел буенда XIV гасыр буена диярлек акча әйләнешенең тотрыклы булуы аларның нигездә моңа ирешкәнлекләрен күрсәтә. Үзендә чимал базасы булмаган һәм һәрвакыт көмеш дефициты кичергән Иран бу яктан алганда аеруча куркынычлы күрше исәпләнгән.

XIV гасырның 20 нче елларында Кыпчак шәһәре Азакта алтын белән көмеш бәяләренең нисбәте 1 : 11,4 яки 1 : 11,6 булган. Идел буенда Сарай әл-Җәдидтә табылган үлчәү тәлинкәләрендәге язуда ун кабатлы «көмеш мыскал» турында әйтелә. Шуңа күрә алтын һәм көмеш арасындагы 1 : 10 нисбәте тотрыклы булган дип уйларга мөмкин. Ягъни 1 г алтынга 10 г көмеш алып булган.

XIV гасырның 30 нче елларында Хәрәзмдә бу нисбәт 1 : 8,65 була, ягъни анда комеш Сарайда булганга караганда шактый кыйммәтрәк йөри. Шуңа күрә Идел буе тәңкәләре әйләнештән алынып, көмеш коелма рәвешендә читкә чыгарылган да.

Күрәсең, көмеш Урта Азиягә, Кытайга һәм хулагуидлар Иранына Хәрәзм аша китә торган булгандыр (XIV гасырның 20 нче елларында анда алтын белән көмешнең нисбәте 1 : 8,36 була, ягъни көмеш Хәрәзмдәгегә караганда да югарырак бәяләнә). Гәрчә Хәрәзм Кыпчакның бер төбәге булса да, кыйммәтле металларның бәясендәге нисбәтне даими күзәтеп барган Идел буе белән чагыштырганда, анда көмешкә ихтыяҗ зуррак була, шунлыктан көмешнең курсы да югарырак йөри. Сәүдәгәрләр моны яхшы беләләр. Мәсәлән, Пеголотти сәүдәгәрләргә Хәрәзмнең баш шәһәре Үргәнечтә көмеш сатып алырга киңәш итә, чөнки анда көмеш чагыштырмача кыйммәтрәк йөрсә дә, Кытай яки Ирандагыдан арзанрак була. «Генуядан яки Византиядән бу тирәләргә һәм Кытайга сәяхәт итәргә ниятләгән кеше үзе белән тукымалар алсын, Үргәнечкә барсын, ә Үргәнечтә аңа көмеш сатып алсын да юлын дәвам итсен»,— дип яза Пеголотти.

Урта гасырларда көнчыгыш базары затлы металларның бәясе үзгәрүгә шактый сизгер җавап биргән. Моңа хөкүмәтләр һәм сәүдәгәрләр генә түгел, тарихчылар һәм сәяхәтчеләр дә игътибар итәләр. Фарсы тарихчысы Рәшид әд-дин алтынның Һиндстанга чыгарылуын хәбәр итә (анда ул көмеш исәбендә кыйммәтрәк бәяләнгән). XIV гасыр урталарына Иранда көмеш дефициты көчәйгәнлектән, дирһәмнең авырлыгы экрен-

ләп кими. Күрәсең, бу — Иранга үзендәге җитәр-җитмәс көмеш белән чикләнергә һәм кыйммәтле металлны ил эчендә саклауга гына түгел, бәлки алтынның көмеш исәбендәге бәясен арттырып күрсәтергә дә мөмкинлек биргән. Ләкин фактта алтын Иранда арзанрак бәяләнә (1 : 8,36), чит илгә, хосусан Һиндстанга китә, ә аннан, акча рәвешендә, Идел буена — алтынның көмеш исәбендәге бәясе югарырак (1 : 10) булган җирләргә китә.

Ибн Батута Кыпчак белән Һиндстан арасында сәүдә мөнәсәбәтләренең шактый тыгыз булуы турында яза. Идел буенда Дәһли солтаннары чыгарган акча күмелгән хәзинәләр табылды. Алтын муллыгы аркасында Һиндстанда һиҗри 725 елда (1324/1325) акча реформасы үткәрелә. Хөкүмәт, кыйммәтле металлны ил эчендә калдырырга омтылып, алтын Һиндстан тәңкәсенең авырлыгын арттыра.

Безнең фикеребезчә, Тукта ханның акча-авырлык реформасыннан соң, аннары Үзбәк хан чорында һәм, соңрак, Җанибәк хан тәхеттә утырганда да Кыпчак акча системасында шундый ук күренешләр күзәтелгән. Акча сугуда авырлык нормасы арта барган: Тукта заманында 1,486 г, Үзбәк һәм Җанибәк чорларында 1,52 һәм 1,56 г булган.

БАКЫР АКЧА

Реформадан соң баштарак көмеш тәңкәләр генә чыгарыла. Ләкин XIV гасырның беренче яртысында шәһәрләрнең бик тиз үсүе, ваклап һәм данәләп сатуның киңәюе әйләнешкә ваграк номиналлы акчалар кертүне таләп итә. Шуңа күрә, 20 нче елларга, ягъни реформа булып беркадәр вакыт үткәч, бакыр акча сугыла башлый. Бакыр акча әйләнешкә бик саклык белән, әкренләп кенә кертелгәнгә охшый, чөнки XIV гасыр башы акча системасында бакыр әйләнеше әле гадәти хәл булмый. Шулай итеп, шәһәр базарларында бакыр акчалар күренә башлый һәм бу бөтен Идел буеның социаль-экономик үсешенең, монгол яуларыннан соң шәһәрләрнең торгызылуы һәм алга таба үсүенең, шулай ук товар-акча мөнәсәбәтләренең табигый камилләшүенең нәтиҗәсе була.

Башкала Сарайдан кала, бакыр акча Болгар, Мукшы, Үкәк, Хаҗитархан, Хәрәзм, Азак һ. б. кебек про-

винциаль шәһәрләрдә дә сугыла һәм ул, нигездә, җирле әһәмияткә ия була.

Сарай акчасы башка шәһәрләрдә чыккан акчалардан үзенең бизәкләнеше һәм сугуның техник камиллеге белән аерылган, чөнки башкалада акча сугу эшенә ныграк игътибар бирелә, Сарай акчасының штемпелен ясаучы осталар да тәҗрибәлерәк була. XIII гасырның икенче яртысына, реформага кадәр, акча нигездә Болгар шәһәрендә генә сугылган чорга караган Болгар акчаларында да шул ук нәрсә күзәтелә.

Яңа бакыр акчага рәсми рәвештә «пул» исеме бирелә. Кайбер акчаларда, мәсәлән, «Болгар пулы» дигән язу бар. Бу сүз — латинчадагы «фоллис», Византиядәге «фоллери», гарәп һәм фарсы телләрендәге «фельс»-ның үзе. Ахырында «с» авазының булмавы аны турыдан-туры Византиядән килеп кергән сүз дип уйларга мөмкинлек бирә. Кайбер типтагы акчаларда «пул» сүзенә болгар-татар теленә хас булмаган «у» (о?) кушымчасы ялгана («пулу Болгар»), ә арткы якта уртасына «гали тамга» куелган биш канатлы йолдыз тора.

Сарайда һиҗри 721 елда сугылган акчаларның бер ягын биш канатлы йолдыз бизи, ә икенче якта бакыр акчаның рәсми курсы күрсәтелгән. «Уналты пул — дәник» дигән язу көмеш һәм бакыр номиналларның нисбәтен бирә. Дәникне без беләбез. Ул 0,76 г. Үзбәк ханның 1,52 г авырлыктагы акчасы ике дәниктән торган, димәк бер көмеш тәңкә 32 бакыр акчага алмаштырылган. Өч көмеш тәңкәнең авырлыгы 4,56 г лы мыскал тәшкил иткән, аның 1/96 өлешле иң кечкенә фракциясе — «хабба». Пулның бәясе 0,0475 г авырлыктагы көмеш «хабба»га (гарәпчә «орлык») яки татарча арпага бәрабәр булган.

Бакыр акчаның арзан йөрүе Пеголотти сүзләреннән күренә: «Һәм Танада көмеш кушмыйча, гел бакырдан гына койган акчалар йөри,— дип яза ул,— аларны фоллери дип атыйлар, 16 фоллери бер аспрга тиң; һәм бу фоллерилар зур күләмле сәүдә эшләрендә кабул ителми һәм түләү итеп бирелми, ләкин яшелчә базарында әйләнештә йөри һәм җирле вак алыш-бирешләрдә файдаланыла».

Бу чорга караган татар акчаларының бер үзенчәлеге аларның бизәкләп, төрле сурәтләр төшереп чыгарылуында. Дөрес, матур орнаментлар һәм кайбер хайван һәм кош сурәтләре Болгарда XIII гасырда сугылган көмеш тәңкәләрдә дә бар. Ләкин сюжетларның ис-

киткеч төрлелеге, балык, кош, төрле җанвар һәм көнкүреш әйбере сурәтләренең бик җентекләп бирелеше фәкать XIV гасыр акчасына гына хас шикелле.

Һиҗри 726 елда Сарайда сугылган Үзбәк хан пулының бер ягына лачын сурәте төшкән һәм анда «16 пул — дәник. Патша хөкеме» дигән язу бар. Мондый язу халык күнекмәгән бакыр акчаны әйләнешкә закон тәртибендә кертү һәм регламентация турында сөйли. Ихтимал, мондый язу халыкның көмеш урынына бакыр алырга теләмәве белән бәйледер. Хәтта соңгырак чорларда да әйләнешкә бакыр акча кертү кыенлык белән генә тормышка ашырылган. Рус тарихында Алексей Михайлович патшалык иткәндә әйләнешкә мәҗбүри тәртиптә бакыр керткән вакытта кузгалган «бакыр фетнәсе» билгеле.

Бакыр пуллар үзләре ниндидер кыйммәткә ия булмаганнар. Алар хәтта көмеш тәңкәләрдән дә җиңелрәк булган. Ләкин соңрак Җанибәк һәм аңардан соң тәхеткә утырган ханнар вакытында, бакыр акчага зур өмет баглап, пулның авырлыгы арттырыла. Әгәр көмеш тәңкәләрнең авырлыгын арттырып сугу тәңкәләрне бозуны һәм чит илгә чыгаруны кисәтергә тиеш булса, бакыр акча ил эчендә акчаны хәзинә итеп күпләп яшерүне кисәтергә яки, һич югында, моңа комачау итәргә тиеш булган. Акча әйләнешендә пулга шактый мөһим роль бирелгән. Алар көмеш тәңкәләрне күзгә күренмәс җепләр ярдәмендә базар белән бәйләргә, акча әйләнешенең көчәюенә булышырга тиеш булганнар. «Патша хөкеме» дигән кыскарак язулы, ә арткы ягына арыслан һәм кояш сурәте төшерелгән пуллар шактый зур группаны тәшкил итәләр. Аларның кайберләрендә һиҗри 737 ел датасы бар. Арыслан яки барс сурәте монда датаны билгеләү сыйфатына ия түгел. 12 еллык цикллы төрки календарьда 737 ел тычкан елына туры килә.

Бакыр акчаны сурәтләр белән бизәү нигездә игелек теләү йөзеннән эшләнгән. XIV гасырга караган бакыр акчаларда, мәсәлән, сурәтләрдән тыш, «Котлы булсын яңы пул!» кебек язулар да бар. Лачын, арыслан яки барс сурәте — татар фольклорында ирдарлык, батырлык һәм муллык символлары. Игелек теләгән язуларның һәм хайван, кош, балык сурәтләренең савытларда да очравын әйтергә кирәк. Мәсәлән, Сарайда табылган кәрәч йөгертелгән касәдә алгы аягын күтәргән арыслан сурәтен күрәбез.

Акчалардагы арыслан сурәтенең аналогларын күп

кенә халыклар сәнгатендә табарга була. Безнең уебызча, бу очракта рәсемнең тышкы формасы түгел, бәлки рәссам-останың кулланучының зәвыгын һәм карашларын белеп эш итүе мөһим. Арыслан сурәте төшкән акчаны кеше бик теләп кабул итәргә тиеш, чөнки аның рухи дөньясында арыслан символ буларак әһәмиятле. Арыслан һәм кояш сурәтләре астраль мәгънәгә ия булганнар. Ләкин бу сюжетның киң таралган булуы (ул беренче тапкыр XIII гасырга караган көмеш Болгар тәңкәләрендә күренә) аның халык күңеленә якын һәм аңлаешлы булуын күрсәтә дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Арыслан төрки халыкларның рухи дөньясында борынгы заманнардан ук мөһим урын тоткан. Мәсәлән, хазар көмеш савытында төрле сурәтләр арасында баһадирның арыслан белән көрәшүе зур урын били. Ул шушы сынау аша узганнан соң гына максатына ирешә (сөйгәне белән кавыша). «Кутадгу билиг»тә гаскәр башының зарури сыйфатлары турында: «Сугышта ул арыслан йөрәкле булсын, һөҗүм иткәндә кулы барс тәпиедәй (җитез) булсын»,— диелә. Идел буенда борынгы төрки әдәбиятны яхшы белгәннәр. Мәсәлән, Сарайчык хәрабәләрендә «Кутадгу билиг»тән алынган икеюллыклар язылган чүлмәк табылды.

Савытлардагы ал аягын күтәргән арыслан сурәтенең мәгънәсе ачык — ул хуҗа кешегә уңыш теләүне белдерә. Акчаларда чабып баручы арыслан нур чәчеп торган кояш фонында урнаштырылган. Савытларда исә кояш сурәте юк, ләкин нурлар бар. Борынгы төрки мәкаль: «Көмешне көнгә (кояшка) куйсаң, алтын аягы белән килер»,— ди һәм теге яки бу формада мондый мәкаль барлык төрки халыкларда да бар.

Шулай итеп, бакыр акчаның алгы ягындагы «Патша хөкеме» 32 пул белән бер көмеш тәңкәнең закон каршында тигез кыйммәтле булуын игълан итә. Арткы яктагы арыслан һәм кояш сурәтләрен исә әйләнешкә кергән акча гына (игелекле эш) уңыш китерә дип аңларга мөмкин.

Үзбәк ханның ике башлы бөркет сурәте төшкән бакыр акчалары шактый зур группа тәшкил итә. Сарай әл-Җәдидтә чыгарылган бу акчаларда сугылу датасы юк. Арткы якта сугылу урыны һәм бакырның нисбәте күрсәтелгән: «Уналты — дәник». Ике башлы бөркет сурәте (шулай ук арыслан һәм бөркет сурәте) төшкән акчалар соңрак та сугылган, ләкин Җанибәк хан за-

маннарындагы даталы пулларда, реформадан соңгы чорга хас булганча, бакыр һәм көмеш нисбәтен күрсәткән язу юк.

Мондый акчаларның сугылу вакытын метрологик анализ бирә. Үзбәк хан пуллары 319,2 г лы 100 авырлык дирһәменә 240 данә исәбеннән, уртача 1,33 г авырлыкта итеп сугылганнар. «Патша хөкеме» дигән язулы һиҗри 727 елгы 82 бакыр акча арасында аларның төп массасы (51 данәсе) 1,10—1,50 г чикләрендә, 16 данәсе генә 1,50 г нан авыррак. Җанибәк хан пуллары исә уртача 1,95 г авырлыкта итеп сугылганнар. Һиҗри 752 елда сугылган 125 бакыр акча арасында 10 данәсе генә 1,50 г нан җиңел, калганнары исә авыррак. «16 пул — дәник» дигән язулы һәм ике башлы бөркет сурәте төшкән пуллар авырлыклары ягыннан беренче группага керәләр. Димәк, алар Үзбәк хан чорында сугылган. Алар тышкы күренешләре белән дә арыслан һәм кояш сурәтләре төшкән Үзбәк хан акчасыннан аерылмый.

Җанибәк тәхеткә утыргач, аның исеме куелган көмеш тәңкәләр Үзбәк хан дирһәмнәреннән үзгә авырлык нормасы буенча сугылганнар. Көмеш тәңкәләр башка норма буенча сугылып та, пуллар Үзбәк хан заманындагы пул авырлыгында сугылган дип уйларга нигез юк. Җанибәк заманында акча сугуда авырлык нормасын арттыру билгеле бер максатларны күздә тоткан, ул авырлык нигезен үзгәртү нәтиҗәсе булган.

Акчалардагы ике башлы кош сурәтенең трактовкасы Византия гербындагы шундый ук мотивларга якын. Анда канатларын җәйгән ике башлы бөркет төп урынны алып тора. Әгәр Кыпчакның Византия белән киң элемтәләре булганлыгын һәм Үзбәк ханның Византия императоры кызына өйләнүен искә алсак, татар пулларын Византиянең ике башлы бөркете белән бизәү ихтималы да бар. Ләкин Византиянекенә охшаш ике башлы бөркетнең калку сурәтләре бакыр акчаларның бик аз өлешендә генә очрый. Акчаларның күпчелегенә ике башлы бөркетнең стильләштерелгән шартлы сурәте, ягъни монголларга кадәрге чорда ук Идел буе халкы арасында киң таралган һәм аңа аңлаешлы булган сурәт төшерелгән.

Канатларын җәйгән схематик кош мотивы хазар сәнгатенә үк хас булган. Ике башлы схематик кош сурәте X—XI гасырларга караган Түбән Идел бәҗәнәк — огуз истәлекләрендә еш очрый.

Идел буе халыклары сәнгатендә канатларын җәйгән кош сурәте, тотрыклы сакланып, буыннан-буынга күчә килгән. XIII гасырга караган көмеш болгар тәңкәләрендә һәм кабер ташлары орнаментында да шундый ук мотив очрый.

Акчадагы ике башлы бөркетнең татарча исеме — сәмруг, бу хыялый кош күп кенә фольклор әсәрләрдә катнаша. Мондый сурәт кайбер борынгы халыкларда, шул исәптән кыпчакларда һәм көнчыгыш славяннарда илаһи көчкә ия булган сәмругка яки «семаргол кошка» барып тоташа дип уйларга кирәк.

Ике башлы кош сурәтенең баш (илаһи) хөкемдар мәгънәсен белдерүе әлеге бакыр акчаларның арткы ягындагы язуда ачыла («Сарай әл-Җәдидтә сугылды. Уналты — дәник»). Билгеле булганча, Үзбәк заманында башкала Сарай әл-Мәхрусадан Сарай әл-Җәдидкә күчерелә. Үзбәк ханның бакыр акчасына төшерелгән ике башлы кош сурәте һәм акчаның Сарай әл-Җәдидтә сугылуы турындагы күрсәтмә, безнең фикеребезчә, бу мәгълүматның әһәмиятен арттыра. Шул ук вакытта югары власть исеменнән 16 пулның бер дәник көмешкә бәрабәр булуы регламентлаштырыла.

Сурәт һәм язуларның игелек теләү характерында булуы бакыр акчаның әйләнешкә ныклап кереп урнашуы өчен зур әһәмияткә ия булган. Бакыр акча көмешнең тизрәк әйләнүенә булышлык иткән, чөнки билгеле бер сандагы бакыр акча көмеш тәңкәгә бәрабәр булган һәм алыш-биреш вакытында халык бакыр акча белән генә чикләнә алмаган.

Көмеш тәңкәләр белән тигез хокуклы булсын өчен, бакыр акчаларның үзкыйммәте үзләре тиңләштерелгән көмеш микъдарына туры килергә тиеш. Югыйсә, әйләнештә бакырны санга сукмаулары, бакыр һәм көмеш акчаларның регламентлаштырылган нисбәте стихиячел төстә бозылуы мөмкин. Бакыр акчада уналты пулның көмеш дәниккә тигез булуын кабат күрсәтә башлау әйләнештә пулның хәле тотрыксыз булуы турында сөйли. Ләкин экономика кануннары фәрманнарга буйсынмый. Моны сарайныкыларга кадәр Болгар акча сугучылары аңлап ала.

Мәсәлән, һиҗри 734 елгы Болгар пуллары авыррак итеп сугылган, аларның уртача авырлыгы көмеш тәңкәләрне сугу нормасына (1,52 г) туры килә (1 кадак бакырга 300 данә вак акча). 43 Болгар пулын үлчәгәч,

аларның 23 данәсе, ягъни 50% тан артыгы 1,30 — 1,60 г чикләрендә урнаша, ә Сарай акчаларының күпчелеге 1,10—1,50 г авырлыкта.

Гәрчә Болгар пуллары башка авырлыкта сугылган булсалар да, аларның авырлыгы Үзбәк хан фәрман белән билгеләгән авырлык системасы чикләреннән чыкмый.

XIV ГАСЫРНЫҢ 40—50 НЧЕ ЕЛЛАРЫНДА АКЧА-АВЫРЛЫК СИСТЕМАСЫ

XIV гасырның 40 нчы елларында феодаль низаглар башланып, Туктамыш хан тәхеткә утырганчы дәвам итә.

XIV гасырның беренче яртысындагы уңайлы шартларда көчәйгән феодаль аристократия дәүләтнең политик тормышында тагы да активрак роль уйный башлый. 1342 елда Үзбәк хан үлгәч, яшьтән үк аның варисы сыйфатында тәрбияләнгән Тинибәк үзәк властьның көчәюеннән курыккан бер төркем феодаллар тарафыннан үтерелә.

Идел буенда власть өчен феодаль бәрелешләр элек тә, XIII гасырның икенче яртысында да булган. Ләкин XIV гасыр урталарындагы көрәшнең характеры башкачарак. Аксөяк нәселдән булулары һәм үзләренең мал-туар саны белән генә мактана алган күчмә тормышлы ярымпатриархаль аристократия белән беррәттән, сарайларга, бистәләрдә яхшы җирләргә, коллар гына түгел, ялчылар да эшләгән күпсанлы остаханәләргә хуҗа булган шәһәр феодаллары катлавының да көчәюе күзәтелә.

Шәһәрләрнең һәм шәһәр тормышының гөрләп үсүенә алар тирәсендә стеналар, ныгытмалар булмавы да булышлык итә. Һөнәр бистәләре исәбенә шәһәрләр бик зураялар. Ныгытмаларның булмавы шәһәр төбәкләрендә товар-акча мөнәсәбәтләренең, шулай ук шәһәрара элемтәләрнең дә үсүенә булыша. Күп кенә шәһәрләрдә акча сугу сарайлары эшли, алар, шәһәрнең әһәмиятенә карап, көмеш яки бакыр акча чыгаралар. Ләкин шәһәрләрнең ныгытылмаган булуы еш кына һәлакәт белән тәмамлана. Шәһәрләр, бигрәк тә Түбән Иделдә урнашканнары, иксез-чиксез далалар белән янәшә булу аркасында, бай калаларга мут күз белән караган күчмә феодалларның һөҗүменә дучар булганнар.

Башкалада дүрт олысның — күрәсең, Хәрәзмнең, Болгарның, Түбән Иделнең һәм Кырымның — вәкилләре (олыс әмирләре) дәүләт эшләрен хәл итү эше белән шөгыльләнгәннәр һәм үзара дошман төркемнәрнең интереслары шушында кисешкән.

Үзбәк хан заманында Сарайда, Сарай әл-Мәхрусада һәм Болгарда эре аристократия шактый зур уңышка ирешә. Болгар акчаларында хәтта Тукта чорындагы Сарай акчаларына гына хас булган «әл-Мәхруса» эпитеты күренә башлый.

Акча ярдәмендә тәхеттәге ханны да үз якларына аударырга сәләтле шәһәр аристократиясенең көчәюе күчмә тормышлы аристократия вәкилләренә ошамаган. Үзбәк хан үләр алдыннан, тәхет варисы Тинибәкнең Шәрык белән сәүдә итүдә мөһим пункт һәм күчмә тормышлы көнчыгыш феодалларының (Күк Урданың) форпосты исәпләнгән Сыгнакка яу чабуында күчмә феодаллар шәһәр интересын яклауны күргәннәр.

Икенче яктан исә, Үзбәк үлгәч шәһәр кешеләре үзләренең һәм, димәк, яңа хан Тинибәкнең дә хәле тотрыксыз булуын күрми кала алмаганнар. Котбның безнең көннәргәчә килеп җиткән «Хөсрәү һәм Ширин» поэмасы юкка гына Тинибәккә һәм аның хатыны, Ирак патшасы кызына багышланмаган булыр.

Мәликә, Тинибәк шаһ булсын!
Һәркайчан сакчысы тәңре булсын! —

дигән юлларда, ихтимал, шәһәр кешеләренең теләге һәм чынбарлыктагы хәл чагыла торгандыр.

Тинибәк тәхеттә бик аз утырып кала. Аның исеме белән акча сугылган булса да, ул акча Тинибәк үтерелгәнче акча сугу сараеннан да чыгып өлгермәгән булырга охшый.

Тинибәк үтерелеп, тәхеткә Үзбәкнең икенче улы Җанибәк утыргач (1342—1357), шәһәр даирәләренең позициясе какшый. Кайбер шәһәрләрдә акча сугуның кискен кимүе, ә Болгардагы акча сугу сараеның эштән туктавы моны ачык күрсәтә. Дөрес, Идел һәм Дон буенда 1345—1350 елларда котырынган чума авыруы да товар-акча мөнәсәбәтләренең зәгыйфьләнүенә сәбәп булган. Тик шулай да Кыпчак иленең әкренләп көчсезләнүе Җанибәк хан тәхеттә утырган чорга туры килә. Җанибәк хан вакытында да халыкара сәүдә элемтәләрен торгызырга һәм акча әйләнешен җанландырырга

омтылышлар була булуын. Мәсәлән, Венеция белән Кыпчак арасындагы ике якка да файдалы сәүдә операцияләре яңартыла. 1347 елда Гөлстанда төзелеп, венециялеләр һәм дүрт олыс әмире кул куйган килешүдә: «Император Җанибәк безнең белән алыш-бирешкә кергән товарларына привилегия ала. Бу товарларга 5% тан артык салым салынмый. Безнең корабларда, галераларда китерелгән барлык Сарай товарлары таможня салымыннан азат ителә»,— диелгән.

XIV гасыр урталарындагы политик һәм экономик вакыйгалар акча сугуда бик үзенчәлекле төстә чагылалар. Үзбәк заманында акча эше һәм реформа мәсьәләләре белән, күрәсең, эре аристократлардан торган диван һәм акча чыгару өчен турыдан-туры җаваплы чиновник шөгыльләнгәндер.

Җанибәк идарә итә башлагач, көмеш һәм бакыр акчаларның авырлыгын тагын да арттырып чыгару күзәтелә. Акчаның элекке чорга караганда авыррак итеп чыгарылуы затлы металлар бәясенең бозылуы турында сөйли һәм акча әйләнешендә ниндидер уңайсыз күренешләр булуына ишарәли. Бу чорда сарай низаглары көмешнең сыйфаты начарлануда һәм сугыла торган тәңкәләрнең авырлыгы кимүдә чагылмый әле. Татар акча сугу сарайларының бакыр акчаның авырлыгын шактый арттыруы моңа каршы тора.

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, Идел буенда акча сугу өчен кулланылган кыйммәтле металл көмеш була. Бакыр акча көмеш дирһәмнең бер өлешен тәшкил итә.

Акча сугучылар көмешнең тезаврацияләнүенә юл куймаска һәм акча әйләнешен тергезеп җибәрергә омтылганнар. XIV гасырның башыннан алып 70 нче елларга кадәр, урта гасырларда сирәк хәл буларак, тулы авырлыктагы тәңкәләрне даими чыгарып тору күзәтелә. Көмешнең бәясе ничек кенә тотрыклы тоелмасын, моннан Идел буе көмеше сәүдә дөньясында урнашкан алтын һәм көмеш рациосы[1] тәэсир итмәгән дип уйларга кирәкми. Акча чыгаручылар әйләнештәге тәңкәләрнең курсын бакыр һәм көмеш акчаның авырлыгын үзгәртеп сугу юлы белән көйләгәннәр. Алтын һәм көмеш рациосының тирбәлешләре турында читләтә генә фикер йөртә алабыз, чөнки Идел буенда алтын акча

[1] Рацио — затлы металларның үзара нисбәте.

сукмаганнар. Мәсәлән, Идел буе базарларына Дәһли солтанының алтын акчалары килү (алар анда көмешләтә кыйммәтрәк бәяләнгән) бу нисбәтнең үзгәрүе турында сөйли.

Җанибәк вакытында чыгарылган акчаларның авырлыгы тагы да арту һәм акча-авырлык реформасы үткәрелү турында без акча сугудагы авырлык нормасына карап фикер йөртәбез. Җанибәк дирһәмнәренең авырлык диаграммасы сугу нормасының 1,52—1,55 г булуын күрсәтә. Теоретик яктан, Җанибәк тәңкәләре 1,56 г авырлыкта булырга, ягъни тәңкә 0,195 г лы 8 кират яки 0,78 г лы 2 дәник көмештән торырга тиеш. Мондый кират 4,68 г лы мыскалның 1/24 өлешен тәшкил итә. Нигезенә 4,68 г лы мыскал салынган мондый авырлык системасы Идел буенда XIII гасырның икенче яртысы башланганда, Беркә хан тәхеттә утырган чорда яхшы билгеле була.

XIV гасырның беренче яртысында акча-авырлык системасында ниндидер үзгәрешләр булуы турында, герләрдән башка, Яңа Сарайда табылган башка истәлекләр дә сөйли. Мәсәлән, узган гасыр уртасында табылган (хәзерге вакытка югалган) көмеш касәгә: «Биш сум тәкый йегерме нократ мыскал ярым» дип язылган («Биш сум һәм егерме ярым мыскал көмеш» дип тәрҗемә иткәннәр). Язуда акча-авырлык берәмлекләре турында сүз баруы шөбһәсез булса да, Идел буендагы акча-авырлык системаларының аз өйрәнелгән булуы аркасында, ул нумизматлар тарафыннан эшкә тартылмыйча килде. Аның тәрҗемәсе дә канәгатьләнерлек түгел иде.

Язуның тәрҗемәсе сүз савытның ниндидер сомнарда һәм көмеш мыскалларда күрсәтелгән авырлыгы турында бара дип фараз итә. Ләкин Идел буенда татар сомы яки сумы, авырлык берәмлеге буларак түгел, бәлки, XV гасырдагы рус берәмлеге «рубль» кебек, билгеле бер сандагы тәңкәләрне яки көмеш коелма авырлыгын исәпләү өчен кулланылган эре берәмлек буларак билгеле. Моннан тыш, язудагы «тәкый» теркәгеченең, «һәм» мәгънәсеннән башка, «шулай ук» мәгънәсе дә бар. Шушыларны исәпкә алсак, касәдәге язуны «Егерме ярым көмеш мыскал биш сум тәшкил итә» дип аңларга мөмкин.

Формасы белән бу касә табага охшый һәм, күрәсең, үлчәү тәлинкәсе булып хезмәт иткәндер. Бу язуда касәнең хуҗасына — сәүдәгәр яки акча алмашты-

ручы кешегә кирәкле мәгълүмат бирелә дип уйларга була.

Алдарак без бу язуда ун кабатлы көмеш «нократ мыскалы» турында юкка гына сөйләнми, чөнки 20,5 мыскал 5 сом акча авырлыгына тигез була алмый, ә гадәти мыскал, күрәсең, «алтын» булгандыр дип фараз иткән идек. Без Татарстан Дәүләт музее коллекциясендә 46,10 һәм 46,16 г лы герләр барлыгын, аларны 46,8 г лы «нократ мыскалы» дип уйларга мөмкин икәнлеген әйткән идек инде. Шундый 20,5 мыскалның авырлыгы чыннан да 5 сом тәңкәләр авырлыгына тигез булырга мөмкин. Мәсәлән, Җанибәкнең 5 исәпләү сомы төп-төгәл 20 нократ мыскалына туры килә ($5\times187,2=936$ г; $20\times46,8=936$).

Мондый нисбәт Җанибәк чорындагы акча-авырлык системасы өчен генә түгел, бәлки Идел буендагы барлык билгеле акча-авырлык системалары өчен дә характерлы булган. Димәк, касәдәге язу бик үк гадәти булмаган мәгълүматны бирә: ул 5 сом тәңкәләрнең авырлыгы гадәттәгечә 20 нократ мыскалына түгел, бәлки 20,5 мыскалга тигез булуын күрсәтә. Закончалы нисбәтнең бозылуы бер акча-авырлык системасыннан икенчесенә күчкәндә, көнкүрешкә яңа берәмлекләр кергән, ләкин әле искеләре дә гамәлдә йөргән вакытта гына булырга мөмкин. Андый күчеш чорлары берничә булган. Әлеге язу шуларның кайсысына карый?

Исәпләүләр моның Үзбәк акча-авырлык системасыннан Җанибәк заманындагы системага күчкәндә булу ихтималы зуррак икәнен күрсәтәләр. Җанибәк чорында 20,5 «нократ мыскалы» 5 яңа тәңкәләр сомына туры килгән диярлек ($5\times187,2=936$; $45,6\times\times20,5=934,8$).

Нигезенә 4,68 г лы мыскал салынган авырлык системасы башка өлкәләрдә дә гамәлдә булган. Мәсәлән, моны без һиҗри 760 елгы (1359/1360) аноним язмадан күрәбез. Җанибәк хан булган чорда Хәрәзмдәге акча-авырлык системасын шул язма буенча реконструкцияләргә мөмкин. Язмада: «Хәрәзмдәге һәрбер дирһәм $2^1/_2$ дәниккә тигез дип сөйлиләр»,— диелә. Хәрәзмдә бу чор тәңкәләре 1,85—1,90 г лы авырлык нормасы буенча сугылганнар. Димәк, теоретик яктан тәңкәләр $2^1/_2$ дәник — 1,95 г ($0,78\times2,5=1,95$ г) авырлыкта булган. Аннары язмада түбәндәгеләр әйтелә: «Хәрәзмдәге һәрбер динар 6 дирһәм, ягъни $2^1/_2$ мыскал авырлыкта. Һәм аның авырлыгы 15 дәниккә

тигез дип сөйлиләр». Хәрәзмдә исәпләү динары, Идел буендагы кебек үк, 6 дирһәмнән торган. Ләкин Хәрәзм дирһәмнәре авыррак итеп сугылганнар, шунлыктан 6 дирһәмнең — динарның авырлыгы Идел буендагы кебек 2 мыскал булмыйча 2 $^1/_2$ мыскал тәшкил иткән ($1,95\times6=11,70$ г; $4,68\times2,5=11,70$ г яки $0,78\times\times15=11,70$ г).

Аноним язмадан күренгәнчә, Кыпчак иленең һәр төбәгендә дәник яки мыскал стандарт авырлыкта булган. Исәпләү берәмлеге динарның яки алтынның, шулай ук сомның да авырлыгы аларны тәшкил итүче дирһәмнәр авырлыгына бәйле булган.

* * *

Җанибәк чорында чыгарылган пулларның авырлыгы арту үлчәп караганда бик яхшы күренә. Мәсәлән, Җанибәкнең Сарай әл-Җәдидтә сугылган һәм хәзер Татарстан Дәүләт музее коллекциясендә саклана торган 125 данә бакыр акчасы арасында 71 данәсе, ягъни 50% тан артыгы 1,50—2,15 г авырлыкларга туры килә. Бакыр акча 468 г лы кадак авырлыгына 240 данә пул исәбеннән сугылган. Әгәр Җанибәк пулларының уртача авырлыгын 1,95 г дип алсак ($468:240=1,95$ г), Җанибәкнең 1,56 г лы бер дирһәменә уртача 62,4 г бакыр ($1,95\times32=62,4$ г), ягъни Үзбәк чорындагыга караганда шактый күбрәк туры килә. Башка сүзләр белән әйткәндә, әгәр Үзбәк заманында көмеш мыскалының иң кечкенә фракциясе — 0,0475 г лы арпа — 1,33 г лы пулга бәрабәр исәпләнсә, Җанибәк чорында яңа мыскалның 0,04875 г лы иң кечкенә фракциясе (1/96) 1,95 г лы пулга тиңләштерелгән.

Җанибәкнең тулырак авырлыктагы бакыр акчалары чыгарылгач, ихтимал, Үзбәк хан пуллары тыелгандыр яки, бәяләре төшеп, кыйммәтен җуйгандыр. Идел буе шәһәрләрендә җыелган бакыр акчаларның процент нисбәтен өйрәнү Җанибәк хакимлек итә башлаганда бакыр пуллар күпләп чыгарылган һәм искеләре алмаштырылган дип фараз итәргә мөмкинлек бирә.

Алтын, көмеш һәм бакырның закон билгеләгән нисбәте даими була алмый, чөнки бу металларның базардагы чын нисбәте һәрвакыт үзгәреп торган. Шуңа күрә яңа хөкүмәтләргә еш кына илнең какшаган акча эшләрен төзәтергә туры килгән. Югарыда әйтелгәнчә,

XIV гасырның 30 нчы елларында Идел буенда көмешнең алтын исәбендәге бәясе Урта Азия һәм Ирандагыдан түбәнрәк булган, шунлыктан бу илләрнең базарларындагы ихтыяҗ көмешнең Идел буеннан шунда саркуына китергән.

Үзбәк хан тәхеттә вакытта көмешнең читкә чыгуына каршы көрәшеп караганнар. Бу максат белән бакыр акчага көмешнең закон билгеләгән бәясе куелган. Шулай да Идел буе базарлары әйләнештәге көмешне бөтен массасы белән тотып кала алсын өчен Җанибәкнең акча-авырлык системасын үзгәртүе хәлиткеч әһәмияткә ия була.

Үзбәк хан заманында алтын һәм көмеш рациосы якынча 1:10 булган. Идел буендагы акча әйләнешендә Һиндстанда XIV гасырның беренче яртысында сугылган алтын акчалар гына билгеле. Аларның норматив авырлыгы 11 г чамасы. Шулай булгач, бер алтын акчага 110 г көмеш яки Үзбәк хан тәңкәләре белән 72 дирһәм (1,52$\times$72=109,40 г) туры килгән. Мондый дирһәм исәбе, күрәсең, Җанибәк вакытында да калган, ләкин дирһәмнәр инде авыррак булган (1,56$\times$72=112,32 г), ягъни алтын көмеш тәңкәләр исәбендә кыйммәтрәк бәяләнгән. Мондый хәл читтән алтын керүгә сәбәп булырга тиеш. Алтын тәңкәләрнең Идел буе акча әйләнешенә керүе безгә инде хәзинәләрдән билгеле, ләкин арзан көмеш тә, коелма хәлендә, Иран, Һиндстан һәм Урта Азия базарларына китәргә тиеш булган. Әмма XIV гасырның 70 нче ел урталарына кадәр 1,56 г лы дирһәмнең авырлыгы үзгәреш-мазар кичермәгән, хәлбуки шул ук вакытта Иранда дирһәмнең авырлыгы туктаусыз кими барган.

Безнең фикеребезчә, 1,56 г лы дирһәм авырлыгының даими саклануын түбәндәгечә аңлатырга мөмкин: тәңкәләрнең курсы тирбәлүгә туры китереп, бакыр акчаларның авырлыгын тиешенчә үзгәртеп чыгарганнар, ягъни эчке базарда көмеш бәясе җитәрлек кадәр югары булган һәм ул әйләнештән китә алмаган. Мәсәлән, бу чорда Иранда бакыр акча күпләп сугылмаган. Нәтиҗәдә, көмеш дефициты аркасында, дирһәмнең авырлыгы өзлексез кимегән. Әгәр 1313—1317 елларда сугылган дирһәмнәр 1,95 г авырлыкта булса, 1339—1344 елгы дирһәмнәрнең авырлыгы 0,875 г га кадәр кимегән.

XIV гасырның беренче яртысында Идел буеның акча-авырлык системасы җитәрлек кадәр уйлап эш-

ләнмәгән һәм шактый катлаулы булган дип әйтергә нигез бар. Инде күреп үткәнебезчә, көмешнең курсын көйләү өчен Үзбәк ханның бакыр акчасында язу («Патша хөкеме») булган. Җанибәк чорында шул ук максат белән эрерәк бакыр акча сугылган. Хызыр (1359—1361) чыгарган бакыр акчалар исә Җанибәк пулларыннан да авыррак булганнар, хәлбуки бу ике хан хакимлек иткән чорда, ягъни 1342—1361 елларда, 1,56 г лы дирһәмнең авырлыгы үзгәрмәгән. Әгәр Үзбәкнең бакыр акчалары 1,33 г лы итеп, 319,2 г лы 100 авырлык дирһәменә 240 данә исәбеннән, ә Җанибәк пуллары уртача 1,95 г авырлыкта итеп — 468 г лы кадак авырлыгына 240 данә исәбеннән сугылган булсалар, Хызырның бакыр акчалары 468 г лы кадак авырлыгына 150 данә исәбеннән, уртача 3,12 г итеп сугылганнар. Хызыр Сарай әл-Җәдидтә һәм Гөлстанда суктырган һәм Татарстан Дәүләт музее коллекциясендә саклана торган 185 данә бакыр акчаның 97 данәсе (50% ы) 2,60—3,11 г авырлыкка туры килә.

Җанибәк үлгәч, хан сараенда берөзлексез низаглар һәм сугышлар башланып китә. Җанибәк үлгән 1357 елдан алып 1379 елда тәхеткә Туктамыш утырганчы Кыпчакта 20 дән артык хан алмашына. Шуңа күрә XIV гасырның 60 нчы еллары башына, ягъни Хызыр тәхеткә менгән вакытка, барлык мәгълүматлар буенча да көмешнең бәясе күтәрелгән.

Хызыр хан заманында, көмеш курсының күтәрелүенә юл куймас өчен, бакыр акча авыррак итеп сугылса да, бу чара гына акча әйләнешенең стабильләшүенә китермәгән, чөнки экономиканы җимерә торган төп сәбәпләр бетерелмәгән. Металлның бер үзәктә тупланауына комачау итә торган кан коюлы сугышлар һәм кайбер төбәкләрнең (мәсәлән, Уралның, Кырымның) аерыла башлавы шундый сәбәпләргә керә.

Җиденче бүлек

XIV ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА АКЧА-АВЫРЛЫК СИСТЕМАСЫ

Бу кара туфрак эчендә ничәләр,
Ятырлар ушбу төн, көндез кичәләр,
Кеме солтан, кеме кол, кеме әмир,
Кеме хуҗа, кеме бай, кеме фәкыйрь.

Хисам Кятиб. XIV гасыр татар шагыйре

60—70 НЧЕ ЕЛЛАРДА СУГЫЛГАН АКЧАЛАР

Бирдебәк үлгәннән соң Кыпчакта бөлдергеч сугышлар кабынып китә. Бу вакыйгалар турында К. Маркс: «1359 *Бирдедәк хан үлә...* Анархия, хыянәт, үтерешләр Кыпчак патшалыгын йончыталар.— Идел һәм Каспий татарлары арасындагы низаглар...»,— дип яза [1].

Бирдебәк заманында алтау булган олыслар аерыла башлыйлар. Ибн Халдун сүзләренә караганда, «Бирдебәк үлгәч һәм (югары) власть калмагач, провинцияләрдә әмирләр мөстәкыйль идарә итә башлыйлар». Хәрәзмдә әмир Нангудайның улы, Үзбәкнең кызы Сөембикәгә өйләнгән Ак Суфый идарә итә. Сугылган акчалар буенча фикер йөрткәндә, Хаҗитарханда Хаҗи Чиркәс, ә Кырымда Бирдебәкнең кызына өйләнгән Мамай мөстәкыйль хаким булалар. Башында Чимтай утырган Күк Урда һәм Көнбатыш Себер дә аерылып чыгалар.

Кыпчак башкаласы Сарай әл-Җәдидтә тәхеткә утыру өчен төрле ханнар арасында көрәш башлана. Рус князьләре ханнарның калейдоскоптагы кебек алмашынуын бик игътибар белән күзәтеп торалар, чөнки аларның политик интереслары һәм иминлеге татар феодалларының билгеле бер даирәләре һәм төркемнәре белән тыгыз үрелгән була. Династия көрәшенең бу чоры көнчыгыш чыганакларына караганда рус елъязмаларында яхшырак яктыртыла.

Шул чорга караган акчалар күрсәткәнчә, Сарай әл-Җәдид өчен көрәш 60 нчы еллар башында аеруча кискенләшә. Мәсәлән, 1359—1363 елларда — нибары 4 ел арасында — канлы бәрелешләр булып, 10 хан алмашына. Ханнар шулкадәр тиз алмашынган, хәтта

[1] Маркс һәм Энгельс архивы, 1946. VIII том, 150 бит.

кайберәүләрнең тәхеттә утыруын без сирәк акчаларга карап кына беләбез. Акча сугу эше сүлпәнләнә, акча азрак чыгарыла. XIV гасырның икенче яртысына караган 15 килограммлы Кече Әтрәс хәзинәсендәге акчалар арасында да 60—70 нче елларда хакимлек иткән күпсанлы ханнарның акчасы 5% кына тәшкил итә. Бу елларда олыслар аерылып, соңрак аларда мөстәкыйль ханлыклар оешканлыктан, сирәк очрый торган әлеге акчаларга һәм аларны суктырган хөкемдарларга җентекләбрәк тукталыйк. Алтын Урданың теге яки бу төбәкләре белән бәйләнгән феодаль төркемнәрнең көрәше акчалардагы хан исемнәренең алмашуында чагылыш таба.

60—70 нче елларда тәхеттә утырган ханнарның бу хәзинәдә очраган акчаларын тасвир итик.

1. **Күлна.** Аның акчасы, ихтимал, Бирдебәк үлү белән, һиҗри 760—761 елларда (1358—1361) Азак, Гөлстан һәм Сарай әл-Җәдидтә сугылган. Барысы 417 данә.

2. **Нәүруз.** Нәүруз хан акчасы һиҗри 760—761 елларда (1358—1361) Азакта, Гөлстанда һәм Сарай әл-Җәдидтә сугылган — барысы 1088 данә.

Тасвирламадан күренгәнчә, Күлна һәм Нәүруз ханнар икесе бер ел эчендә хакимлек итсәләр дә, аларның исеменнән сугылган акчаларны сирәк дип булмый. Акча чыгарылган шәһәрләр дә элгәрге ханнар акча суктырган шәһәрләрдән аерылмый, сугу ысуллары да традицион, Сарайныкы. Әмма бу елларда Сарайда феодаль төркемнәр арасында аяусыз көрәш баруы да билгеле, тик алар әле бу акчаларда чагылып өлгермәгән. Күлна белән Нәүруз, күрәсең, сәүдәхуҗалык интереслары Идел буе һәм Көнбатыш белән бәйләнгән шәһәр даирәләренең вәкилләре булгандыр. Күлнаның ике улы христиан динен тота, ә Нәүрузны Үзбәкнең тол хатыны Тайдула яклый. Рус елъязмалары аны «Болгар ханы», «Идел (Волга) патшасы» дип атыйлар [1]. Феодалларның бу төркеме, көнчыгышка йөз тоткан феодалларга караганда, экономик яктан көчлерәк була. Ләкин соңгылары кораллы көчләргә ия булган күчмә феодалларга таяна, ә алар теләсә кайчан эчке низагларга катнашып китә алганнар.

«Рогожа елъязмачы»сы: «Шул ук язны Идел пат-

---

[1] Татищев В. Н. История Российская. М.; Л., 1965, V том, 111 бит.

шалыгына көнчыгыштан, Җаек артыннан Хызыр исемле бер патша килде, килеп Урданы алды һәм Нәүруз патшаны да, Тайдула патшабикәне дә үтерде...» — дип язып калдыра [1].

Нәүрузны һәм аның яраннарын (шул җөмләдән Тайдуланы да) үтергәч, көнчыгыш тарафдарларының йогынтысы көчәя.

3. Хызыр. Хызыр хан исеменнән акча һиҗри 760—762 елларда (1358—1361) Сарай әл-Җәдид, Гөлстан һәм Азак шәһәрләрендә сугылган — барысы 727 данә.

Хызыр — Кыпчак олысы Күк Урда (үзәге Сыгнак) ханы Чимтайның туганы. Күрәсең, ул үзәге Сырдәрьяда урнашкан Шайбан урдасының башында торгандыр («Җаек арты патшасы»). XIV гасырның 70 нче елларында күмелгән хәзинәләрдә Хызыр хан исеменнән сугылган акча шактый күп табыла. Көмеш тәңкәләрне тулы кыйммәтле итеп, ә бакыр акча элгәрге ханнарның пулларына караганда эрерәк итеп сугылган. Гәрчә Хызыр, Габдулла яки Бүләк ханнар белән чагыштырганда, азрак вакыт тәхеттә утырса да, аның исеменнән сугылган акчаның күп булуы бу чорда казна нигездә Уралда көмеш һәм бакыр чыгару исәбенә тулыландырып торылган дип фараз итәргә мөмкинлек бирә.

4. Тимерхуҗа. Бу ханның акчасы һиҗри 761 елда (1359/1361) Сарай әл-Җәдид шәһәрендә сугылган. Хәзинәдә алар нибары 18 данә генә. Рус елъязмалары хәбәр итүенә караганда, Хызырны үтереп Сарай тәхетенә менгән Тимерхуҗа үзе дә анда озак утырмаган, «Идел аръягына качкан һәм шунда үтерелгән». Ул барлы-юклы ике атна гына хан булып торган.

Тимерхуҗа хан булган вакытта олыс әмирләре тәхет варислыгы мәсьәләләренә ачыктан-ачык катнаша башлаганнар, варислыкка дәгъва итүчеләр дә күбәйгән, ә олыслар тагы да ныграк читләшкәннәр. Шул ук елъязмачы Хызыр үлгәннән соң: «Урда князе Мамай Иделнең икенче ягыннан килеп өстен чыкты, аның патшасы Габдулла (Абдулай) исемле...» — дип хәбәр итә. Шул ук чыганаклар хан тәхетенә дәгъва кылган Урдумәлик, Килдебәк һәм Мөрит исемнәрен телгә алалар. Тимерхуҗадан башлап Хәрәзмдә акчага тәхеттәге хан исемен куймыйлар.

---

[1] Полное собрание русских летописей (ПСРЛ), М., 1965, XV том, I чыгарылыш, 69 бит.



8 нче рәсем. Болгар-татар акчалары һәм хәзинәләре табылган урыннар.

5. Урдумәлик. Урдумәликнең 54 данә акчасыннан 14 данәсе Сарай әл-Җәдидтә һәм 40 данәсе Азакта һиҗри 762 елда (1360/1361) сугылган.

Тимерхуҗа үтерелгәннән соң, фактта хакимлек Урдумәлик кулына күчә. Урдумәлик тә, Хызыр һәм аның улы Тимерхуҗа кебек үк, Урта-Ичен нәселеннән, ягъни Күк Урдадан чыккан була. Ләкин Күк Урда солтаны токымының Ак Урда патшалары тәхетендә утыруы әмирләрнең ачуын кузгаткан һәм аларның берсе «төн уртасында пычак белән чәнчеп, аның эшен бетергән» [1].

6. Килдебәк. Хәзинәдә Килдебәкнең һиҗри 762—763 елларда (1360—1362) Сарай әл-Җәдидтә сугылган 50 данә һәм Азакта сугылган 77 данә акчасы бар. Азак акчаларында ханның исеме солтан титулы кур-

---

[1] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде, II том, 130 бит.

сәтелмичә: «Хан Килдебәк әлгадел» рәвешендә бирелгән.

Үзбәкнең оныгы, Җанибәкнең никахсыз туган улы Килдебәк тәхеткә утыргач, ул эре феодалларга карата каты чаралар күрә һәм үзара низаг-бәрелешләрне туктатырга омтылыш ясый. Аның акчалары, Сарай белән Азактан тыш, Мукшыда да сугылган.

Килдебәк үзара бәрелешләрнең төп сәбәбен эре әмирләрнең үз белдекләре белән эш итүендә күргән һәм аяусыз террор кулланган. Ләкин Килдебәкнең каты куллылыгы һәм илне берләштерүдәге аерым уңышлары «үз» олысы вәкилен хан итәргә тырышкан феодалларның үзләрен үк канәгатьләндерми. Чираттагы үтерештән соң, Хызырның туганы Мөрит — күрәсең, Күк Урда яки Шайбан урдасы вәкиле хан булып утыра.

7. Мөрит. Хәзинәдә аның исеме белән сугылган акчалар байтак — 348 данә. Алар һиҗри 762, 763 һәм 764 елларда (1360—1363) Гөлстан шәһәрендә сугылган. Һиҗри 762 елга караган акчалар дүртәү генә, 763 һәм 764 елгылар исә — 117 һәм 135 данә. Моннан Мөритнең һиҗри 762 елның иң ахырында гына хакимлек итә башлавы килеп чыга. Мөрит акчаларына Гөлстан тәңкәләренә хас булган квадрат куфи язуы басылган.

Мөрит тәхеттә вакытта Кыпчакның яки, рус елъязмачылары атаганча әйтсәк, «Идел патшалыгының» тагы да көчсезләнүе күзәтелә. 1362 елга караган елъязмалар: «Урдада ыгы-зыгы купты... Иделнең бер ягында Мөрит (Мурут), ә икенче ягында Килдебәк, һәм алар арасында сугыш булды һәм Килдебәкне үтерделәр, ә Мамай үзе белән патша улын алып килде дә Идел буенда Мамай белән Мөрит арасында сугыш булды»,— дип хәбәр итәләр [1].

Мөрит исеменнән акча Сарай әл-Җәдидтә һәм Гөлстанда гына чыгарыла. Азакта исә акчаны Габдулла исеме белән сугалар. Димәк, Кырым олысы инде тәмам аерылып чыккан була. Рус олысының да Сарай кулы астыннан чыгу куркынычы булганга, Мөрит, кайбер ташламалар хисабына, бу олыс өстеннән хакимлеген ныгытырга тырышып карый. 1362 елны ул, Дмитрий Иванович (соңыннан — Донской) һәм Дмит-

---

[1] ПСРЛ, XV том, I чыгарылыш, 73 бит.

рий Константинович Суздальский илчеләрен кабул итеп, бөек князь исемен Дмитрий Ивановичка бирергә карар итә һәм, бөек Князьлек ярлыгы элегрәк Нәүруз хан тарафыннан Дмитрий Константиновичка бирелгән булса да, Мөрит хан Дмитрий Ивановичка ярлык белән үзенең илчесен җибәрә.

1363 елда бөек князьлеккә рөхсәт биргән шундый ук ярлыкны Дмитрий Ивановичка Габдулла хан исеменнән Мамай урдасы илчесе дә китерә. Бөек князь илчене хөрмәт белән каршылый һәм бүләкли.

Моны ишетеп ачуы кабарган Мөрит хан бөек князьлекне Дмитрий Константиновичка тапшырырга ниятли, ләкин нияте барып чыкмый. Бөек князьлеккә Габдулла исеменнән ярлыгы булган князь Дмитрий Иванович Дмитрий Константиновичка каршы яу белән китә һәм аны бөек князьлектән ваз кичәргә мәҗбүр итә.

Чираттагы сарай бәрелешендә Мөрит һәлак була.

8. **Габдулла.** Габдулланың 127 данә акчасы төрле елларда сугылган. Кече Әтрәс хәзинәсендәге аның исеме белән башкала Сарай әл-Җәдидтә сугылган иң беренче акча һиҗри 761 елга карый.

Хан тәхете өчен көрәштә Габдулланы Нугай олысы әмире Мамай яклый. Ибн Хәлдун сүзләренә караганда, әмир Мамай «Үзбәк балаларыннан Габдулла исемле бер угылны хан итеп куя һәм аның белән Сарайга юл тота».

Габдуллага да тәхеттә озак утырырга насыйп булмый. Аның 127 данә акчасының 7 се генә Сарайда сугылган (һиҗри 762 ел — 1360/1361). Шул ук Ибн Халдун хан тәхетен Габдулладан бер әмирнең дә дәгъвалавын хәбәр итә. Ихтимал, Габдулланың Сарайда аз гына утыруы шуның белән аңлатыла торгандыр.

Ә бәлки Габдулла башкала Сарайны кулга төшерә алмагандыр. Аның исеме белән сугылган аз санлы Сарай акчалары Мамай әмир сул як Идел буена бәреп кергән арада чыгарылган булырга да мөмкин.

Хәзинәдә Габдулла исеменнән Азакта һиҗри 764—765 елларда сугылган 21 данә акчаның алгы ягында хан исеме «Габдулла хан» рәвешендә, «солтан әлгадел» дигән гадәти титулатурадан башка гына бирелгән. Ике тәңкәсе Яңа шәһәр Мәхрусада һәм берсе Мәхруса шәһәр әл-Җәдидтә сугылган. Акчаларның күпчелеге (96 данәсе) һиҗри 767, 770, 771 елларда Урдуда, ягъни Габдулла хан станында чыгарылган.

9. Мирбулат. Хәзинәдә бу ханның 6 данә генә акчасы бар, алар һиҗри 764 елда (1362/1363) Сарай әл-Җәдид шәһәрендә сугылганнар.

Нумизматик әдәбиятта ханның исеме ике төрле: Хәербулат һәм Мирбулат рәвешләрендә очрый. Кече Әтрәс хәзинәсе тәңкәләрендә исемнең башында бик үк анык булмаган «м» хәрефеннән соң «р» хәрефе тора, ягъни алар арасында «и» хәрефе юк. Димәк, исемне Мирбулат дип укырга кирәк.

Мирбулат акчаларының хәзинәдә аз булуы аның да бик кыска вакыт кына ханлык итүе турында сөйли. Көнчыгыш язма чыганакларында Мирбулат исеме теркәлергә дә өлгерми калган. Рус елъязмалары исә бу чорда, әһәмиятен югалткан Сарайдан бигрәк, Мамай урдасындагы хәлләр белән ныграк кызыксынганнар.

10. Дәүлиулла Хуҗа. Кече Әтрәс хәзинәсендә бу ханның 7 данә акчасы очрый, алар һиҗри 766 елда (1364/1365) сугылганнар. Дәүлиулла Хуҗаның исеме язма чыганакларда билгесез. Аны нумизматик әдәбият та белми. Х. М. Френ Мирбулат хан акчаларыннан соң, исеме Булат Хуҗа рәвешендә бирелгән хан акчаларын тасвир итә.

Кече Әтрәс хәзинәсе акчаларында бу ханның исеменең башында «дад» хәрефенең бик ачык булуын күрәбез һәм ул, дөрес язу кагыйдәләренә туры китереп, үзеннән соңгы «вав» хәрефе белән тоташмаган. Ә өченче «лям» хәрефеннән соң «әлиф» һәм «дад» юк, хәлбуки «Булад» исемендә алар булырга тиеш иде. Бу хан акчаларындагы башка сүзләр аермачык укыла һәм штемпель ясаучыны шапшаклыкта гаепләргә урын калдырмый.

Дәүлиулла Хуҗа акчасы Гөлстан әл-Җәдидтә генә сугылган һәм алар сирәк очрый.

11. Газизшәех. Газизшәех исеменнән сугылган акчалар хәзинәдә 101 данә. Шуларның 42 данәсе һиҗри 766—767 елларда (1364—1366) Гөлстанда, 6 данәсе һиҗри 767 елда Сарай әл-Җәдидтә, 50 данәсе Гөлстан әл-Мәхрусада һәм 3 данәсе Гөлстан әл-Җәдидтә сугылган (боларының сугылу датасы кыршылган).

Хәзинәдә Сарай акчаларының аз, ә Гөлстанда сугылганнарының, киресенчә, күп булуы һәм Гөлстан акчаларының иң алдан сугылган булуы Газизшәехне Гөлстанда тәхеттә утырган дип фараз итәргә мөмкинлек бирә. Ә Гөлстан, белгәнебезчә, Болгар йортында

урнашкан акча сарае булган. Димәк, Газизшәех, Нәүруз кебек үк, Болгар вәкиле булган һәм, Мамай утырткан ханнар кебек үк, Сарай тәхетенә дәгъва иткән дип уйларга мөмкин. Газизшәехнең Сарай әл-Җәдидтә тәхеткә менүен аның исеме белән башкалада сугылган акчалар күрсәтә. Хан булып алгач, ул Мамай претендентларына каршы хәрәкәт итә башлый. Рус елъязмаларына караганда, Газизшәех үзенең илчесе Урысмулланы (Урусмалда) Дмитрий Константиновичка бөек князьлеккә ярлык белән җибәрә. Ләкин Дмитрий Константинович бөек князьлектән Мәскәүдәге Дмитрий Иванович файдасына баш тарта.

Газизшәех чираттагы заговор нәтиҗәсендә үтерелә. Ихтимал, бу вакыйгаларда Мамай тарафдарлары шактый роль уйнаганнардыр. Мәсәлән, Габдулланың Сарай әл-Җәдидтә һиҗри 768 елда (1366/1367) сугылган акчалары билгеле.

12. Булаттимер. Булаттимер акчалары сирәк очрый. Хәзинәдә алар 17 данә генә. Аларның кайбер типлары һиҗри 768 елга (1366/1367) карый. Күбесендә сугу урыны күрсәтелмәгән. Акчаларның бер ягында «Мәрхүм солтан Җанибәк ханның патшалыгын алла сакласын» дигән кызыклы язу, ә икенче ягында «Төклә би улы Булаттимер. 768 ел» дигән язу бар. Акчаларның бер данәсендә генә аны суктырган хөкемдар исеме урынында акча сугылган урын — Гөлстан күрсәтелгән.

Акчаларда «солтан» яки «хан» кебек титулның булмавы күзгә ташлана. Алар урынына Булаттимернең атасының исеме куелган. Аның исемен нумизмат П. С. Савельев «Нуган» дип укыган иде. Кече Әтрәс хәзинәсендә Булаттимер акчалары арасында җиде типтагы акчалар бар, аларны чагыштыру юлы белән Булаттимернең атасының исемен ачыкларга мөмкин. Безнең фикеребезчә, исемне Төкләби дип укырга кирәк.

Акчага күптән үлгән Җанибәк хан исемен (анда «мәрхүм» сүзе аермачык укыла) һәм акчаны суктыручы хөкемдарның атасының исемен кую (татар акчаларына бу хас түгел) Булаттимер, ихтимал, Җанибәк заманындагы зур дәрәҗәле, рус чыганакларында Тоглуби яки Тавлиби дип аталган түрәнең улы булгандыр дигән уйга китерә. Бу исем безгә, рус елъязмаларыннан тыш, Кәнчыгыш чыганаклары буенча да мәгълүм.

Булаттимернең хан нэселеннән булмавы, шуңа күрә акчаны мәрхүм солтан Җанибәк исеменнән суктыруы турындагы гипотеза XIX гасырда ук тәкъдим ителгән иде. Ләкин тарихи шәхес буларак, Булаттимер язма чыганакларда иртәрәк тә телгә алына. 1361 елгы Мәскәү елъязмасында «Урда князе Булат (Булак) Тимер Болгарны һәм Идел буендагы барлык шәһәр һәм олысларны яулады һәм бөтен Идел юлын тартып алды»,— диелә.

1361 елда Гөлстанда акча Мөрит хан исеменнән сугылган. Димәк, Булаттимер Болгарда хан наместнигы булырга тиеш һәм аның эшчәнлеге Габдулла хан исеменнән хәрәкәт итүче Мамайга каршы юнәлдерелгән була. Елъязмачы хәбәрендә сизелгән беркадәр дошманлык бөек князьнең Габдулла хан ярлыгы буенча идарә итүеннән килә дип уйларга кирәк, ә Мөрит, соңрак Газизшәех хан һәм Болгар наместнигы Булаттимер Габдулланың һәм Мамайның дошманнары булганнар.

Һиҗри 768 елда (1366/1367) Сарай әл-Җәдидтә Габдулла исеменнән сугылган акчалар Мамайның Идел буен дәгъва итүе турында сөйли. Габдулла беркадәр вакытка Газизшәехтән тәхетне тартып алуга ирешә.

Булаттимер соңгы тапкыр 1367 елга караган елъязмада, князь Дмитрий Константинович биләмәсе Нижний Новгородка яу чапты дип телгә алына. Бу яу Газизшәех ханның үч алуы кебегрәк тәэсир калдыра. Газизшәех 1365 елда ук инде үзенең илчесе Бәйрәмхуҗаны Нижний Новгородта князьлек итүгә ярлык белән Борис Константиновичка, ә Урысмулланы, инде әйтеп киткәнебезчә, Владимирда бөек князьлек итүгә ярлык белән Дмитрий Константиновичка җибәргән була. Сарайның зәгыйфьлеген үзенең ачы тәҗрибәсеннән белгән хәлдә, Дмитрий Константинович, Мәскәүдәге Дмитрий Ивановичка юл сабып, бөек князьлектән баш тарта. Ә Дмитрий Иванович бөек князьлеккә Габдулладан ярлык алган һәм аңардан Борис Константиновичка каршы ярдәм сораган була. Елъязмачы: «Һәм князь Дмитрий Константинович үзе Нижний Новгородта князьлеккә утырды»,— дип хәбәр итә. Дмитрий Константинович белән аның туганнары, шул исәптән Борис Константинович та Булаттимер гаскәренә каршы чыгалар һәм Пьяна елгасы буенда аны җиңәләр. Елъязмачы әйтмешли, «Князь

Булаттимер исә, кечкенә генә гаскәре белән, Урдага качып кайта һәм шунда Газиз (Озиз) хан тарафыннан үтерелә».

Сарай әл-Җәдидтән Габдулла тарафыннан куылган Газизшәех, күрәсең, күпмедер ара үз урдасында хакимлек итә. Ләкин Сарай әл-Җәдидне һәм аның тирәсендәге өлкәләрне генә түгел, Болгарны да югалткач, Газизшәех жучидлар нәселеннән булган һәм тәхетен югалткан башка ханзадәләр кебек үк, көндәшләре тарафыннан үтерелә.

Булаттимердән соң сугылу урыны «Гөлстан» дип күрсәтелгән башка көмеш тәңкәләр билгеле түгел. Бу чорга караган болгар-татар нумизматикасы аеруча буталчык. Булаттимер үтерелгәннән соң да Мамай Болгарны яулап ала алмаган дип уйларга кирәк. Һәрхәлдә аның уенчыгы булган Габдулла хан акчалары арасында бу чорда Гөлстанда сугылганнары юк.

Күрәсең, Газизшәех Мамай тарафыннан, ә Булаттимер руслардан җиңелгәч, Сарайның власте тәмам какшагандыр. Бу елларда «Идел патшалыгы» елъязмаларда бүтән телгә алынмый. Болгар да бөтенләй көчсезләнә. Гөлстанда акча сугуның озак вакытларга тукталуын искә алсак, әлеге вакыйгаларның нәтиҗәсе һәлакәт төсендә булган дияргә кирәк. Әлегә Сарайда тәхет дәгъвалаучылар тарафыннан вакыт-вакыт акча сугылгалап торса да, инде ул акча Урта Идел буена килеп җитми. Хәтта Кече Әтрәстәге бай хәзинәдә дә Гали һәм Гарәпшаһ ханнарның акчалары очрамый.

1370 елда Дмитрий Константинович Суздальский, Мамайның Ачы Хуҗа җитәкчелегендәге илчеләре белән берлектә, Болгарга басып керә. Болгар әмире Хәсән Мамай тәхеткә утырткан кече яшьтәге Мөхәммәт Бүләкнең хакимлеген танырга мәҗбүр була.

Галинең һәм Күк Урдадан Идел буена бәреп кергән Гарәпшаһның акчаларыннан башка, бу елларда Сарайда Тулунбикә ханым исеменнән дә акча сугыла. Аның акчасына һиҗри 773 ел (1371/1372) датасы куелган.

13. Урыс Мөхәммәт. Күк Урда хакиме Чимтайның улы Мөхәммәт Урыс үзара сугышлар вакытында Мамайның Идел буена һәм Аксак Тимернең кыпчак биләмәләренә һөҗүмен уңышлы төстә кире кайтарган куәтле ханнарның берсе була. Урыс Мөхәммәт әле атасы исән вакытта ук аны Ак Урданы буйсындырыр-

га өнди. Хан булып алгач, беренче корылтайда ук ул Сарай тәхетен алырга ниятләвен игълан итә һәм берничә көнгә сузылган сый мәҗлесеннән соң, «шул якка юл тота». Ләкин, акчаларга карап фикер йөрткәндә, Урыс хан солтанлыкка тиз генә ирешә алмый әле.

Урыс акчаларын билгеләүнең кыенлыгы шунда: бу чор акчалары Габдулланы алмаштырган һәм Мамай урдасының ханы булган Мөхәммәт Бүләк исеменнән сугылганнар. Бу чорга караган Урыс һәм Бүләк акчаларында мөселманча «Мөхәммәт» исеме генә бар. Шуңа күрә нумизматлар аларны билгеләүдә икеләнеп калалар. «Мөхәммәт» исеме белән сугылган күпчелек акчаларны нумизматлар, П. С. Савельевтан башлап ук, Бүләкнеке дип санийлар. Хәлбуки Урыс XIV гасырның 70 нче елларындагы эчке низаглар чорында иң куәтле ханнарның берсе булган һәм, Мамай сүзеннән чыга алмаган Бүләктән аермалы буларак, властьны үз кулында нык тоткан. «Гиас әд-дин вә әд-дөнья» дигән купшы титулны Урысныкы дип уйлау дөресрәк булыр. Хикмәт мондый титулны йөртү өчен Бүләкнең артык яшь булуында гына да түгел (аңа әле 10 яшь тә тулмаган була). Бу акчалардагы язу стиленең Мамай урдасында чыккан акчалардагы язу белән һичбер уртаклыгы юк. Габдулла һәм Бүләк акчаларындагы язу нәсех стилендә башкарылган һәм аерым сүзләр язылышында үзенчәлеккә һәм охшашлыкка ия. Әлеге титул куелган акчалардагы язу исә Хәрәзм, Сарай һәм Гөлстан акча сугу сарайларына хас булган чәчәкле квадрат куфи стилендә.

Мөхәммәт Урысның Кече Әтрәс хәзинәсендә табылган 187 данә акчасы Сыгнакта (1 данә) һәм Әл-Урдуда (185 данә) сугылганнар. Иң беренче акчалар һиҗри 772 елда (1370/1371) Сыгнакта һәм Әл-Урдуда (12 данә) чыгарылган. Сыгнак акчасында «Солтан әл-гадел» дигән сүзләрдән соң «Урыс» исеменең башын укырга була. Башка акчаларда исә — «Мөхәммәт» кенә.

Акчаларның күпчелеге Әл-Урдуда сугылган. Әл-Урдуның иң соңгы акчасы һиҗри 871 елга карый (781?). Монда сугылган акчаларның күп булуы Урысның, нигездә, үз урдасында утыруын күрсәтә.

Көнчыгышта Аксак Тимер һәм аның ягына ауган Туктамыш белән сугышта кулы бәйләнгән Урысның рус олысы эшләре белән шөгыльләнергә җае булма-

ган. Шуңа күрә рус елъязмаларында Урыс хан турында бертөрле дә мәгълүмат очрамый.

Мамай, Урыс ханның рус олысына карата пассивлыгыннан файдаланып, Тверь князе Михаил Александровичны һәм Мәскәү князе Дмитрий Ивановичны үзенең һәм курчак ханы Мөхәммәт Бүләкнең вассаллары итеп танырга мәҗбүр итә. Дмитрий Константиновичның Болгарга 1370 елгы явы Мамай күрсәтмәсе буенча оештырыла.

Мамайның көчәюе Сарай әл-Җәдидтә каты бәрелешләргә китергән булса кирәк. Башкалада XIV гасырның 70 нче елларында сугылган Гарәпшаһ һәм Каганбәк акчалары шул хакта сөйли.

14. Каганбәк. Хәзинәдә бу ханның акчалары 3 данә генә... Аларның икесе һиҗри 777 елда (1375/1376) Сарай әл-Җәдидтә, берсе һиҗри 777 елда (1375/1376) райчыкта сугылган.

15. Мөхәммәт Бүләк. Хәзинәдә Бүләк ханның 17 акчасы бар, алар Урдуда сугылганнар. Акчалар нигездә һиҗри 772 елда (1370/1371) чыгарылган, ә 3 данәсе һиҗри 777 елда (1375/1376) сугылган. Ханның исеме «Әл-гадел солтан Мөхәммәт хан» рәвешендә бирелә. Елъязмалар аны «Мәмәт солтан» дип тә атый.

Акчалардагы язу гадәти нәсех стилендә. Кайбер акчаларда 70 һәм 2 саннары сүз белән язылган.

Урдуда сугылган акчаларның кайбер типларында «хан» сүзенең язылышында үзенчәлек бар, бу аларны Мамай урдасында Мөхәммәт Бүләккә кадәр тәхеттә утырган Габдулла акчалары белән берләштерә. Бу ханнарның акчасы өчен штемпельләрне Мамай урдасындагы бер үк оста ясаган дип фараз итәргә мөмкин.

Һиҗри 772 елгы акчалар иң беренчеләре һәм алар Мөхәммәт Бүләк тәхеттә утырган чорга карыйлар. Рус елъязмалары 1370 елда «Мамай үз урдасында икенче патшаны — Мәмәт солтанны (тәхеткә) утыртты» дип хәбәр итәләр.

1379 елда Урыс һәм аның уллары үлгәннән соң, көнчыгыш олысларга Туктамыш хан була, аны Аксак Тимер дә яклый. Елъязмачы сүзләренә караганда, Мамай «Олы Урда ханы Туктамышка буйсынмый». Ләкин Мамай урдасының үзендә дә тыныч булмый. 1370 елда Мамай чуалышлардан соң 18 яшьлек Мөхәммәт Бүләк ханны һәм аның яраннарын үтертә. Аның урынына хан итеп Түләкбәк чакырыла.

16. Тўләкбәк. Кече Әтрәс хәзинәсендә Түләкбәкнең 16 данә акчасы очрый. Алар һиҗри 782 елда (1380/1381) сугылганнар. Сугу урыны күрсәтелмәгән. Акчаның арткы ягында матур гына нәсех стилендә башкарылган иман символы тора.

Диакритик ноктапар куелмаганлыктан, ханның исемен Бүләк дип тә укырга мөмкин. Мондый язулы акчаларны Х. М. Френ һәм П. С. Савельев Бүләкнеке дип санаганнар. Бездәге данәләрдә хан исеменнән аста «бәк» сүзе аермачык укыла. Димәк, бу акчалар Түләкбәк исеменнән сугылганнар.

Дон буенда Куликово сугышыннан соң Мамай, үз хәленең мөшкеллеген аңлаган хәлдә, кан дошманы Туктамышка каршы гаскәр җыя башлый. Ләкин Калка елгасы буенда хәлиткеч мизгелдә әмирләр аны ташлап, Туктамыш ягына чыгалар һәм хан әмере белән Мамай үтерелә [1].

Мамайны җиңгәч, Туктамыш рус кнәзьләренә илчеләрен җибәреп, үзенең һәм аларның дошманы Мамайны җиңүе һәм Идел патшалыгына утыруы турында хәбәр итә [2].

17. Туктамыш. Тәхеткә Туктамыш утыргач (1379—1395), 20 ел дәвам иткән феодаль сугыш туктый. Акча барлык үзәкләрдә бер хан исеменнән чыгарыла башлый.

Язучыларның стиленә караганда, Урыс ханның әл-Урдасында да, Мамай урдасында да акчаны Туктамыш исеменнән суга башлыйлар. Алар урынына хан акчасы сугылган яңа урын — Урду әл-Мөгаззәм, ягъни «Бөек урда» күрсәтелә. Бу өч күчмә станнан башка, акча Сарай әл-Җәдидтә, Сарай әл-Мәхрусада, Сарайчыкта, Кырымда, Азакта, Хәрәзмдә, Сыгнакта, Хаҗитарханда һ. б. шәһәрләрдә сугыла.

Туктамыш чоры җитәрлек кадәр өйрәнелгән, ә ул үткәргән акча-авырлык реформасы турында сүз алдарак булыр.

18. Бирдебәк. Кече Әтрәс хәзинәсендә Бирдебәкнең Гөлстан әл-Җәдидтә һәм Кермшәйдә (?) сугылган 18 данә акчасы бар. Гөлстан әл-Җәдид акчаларында дата юк, ләкин Кермшәй акчаларының датасы тәгаен билгеле. Кайбер акчаларда дата цифрлары уңнан сулга таба — ягъни 789 урынына 987 рәвешендә, ә кай-

---

[1] ПСРЛ, XV том, I чыгарылыш, 141 бит.
[2] Шунда ук.

берләрендә сулдан уңга таба — 789 (1387/1388) рәвешендә язылган.

Бирдебәкнең кем булуын тәгаен әйтү кыен, ләкин «әл-гадел солтан Бирдебәк хан» дигән титулы аның хан нәселеннән булуы һәм, Туктамыш куәткә ирешкән чорда да үз исеменнән акча суктыруына караганда, оппозициядә торуы турында сөйли.

Бирдебәк акчаларының Гөлстан әл-Җәдидтә сугылуы игътибарны җәлеп итә. Табигый, Гөлстан Сарай шәһәренең бистәсе булгандыр һәм Бирдебәк акчасы Сарайда сугылгандыр дип фараз итү мөмкин түгел. Туктамыш властьны кулында нык тоткан һәм аның акчалары, күргәнебезчә, күп кенә шәһәрләрдә, шул исәптән һиҗри 789 елда (1387/1388) башкала Сарайда да сугылган. Ләкин аның исеме белән Болгарда яки Гөлстанда сугылган акчалар очрамый. Без алдагы бүлектә «Гөлстан» дип билгеләнгән акча сугу урынының Болгар йортында булуы мөмкин дип фараз иткән идек. Туктамыш тәхеттә вакытта акчаның хәтта икенче дәрәҗәле Сарайчык һәм Хаҗитархан кебек шәһәрләрдә сугылып та, Туктамыш акчалары арасында Болгар яки Гөлстанда сугылганнары булмау, безнең фикеребезчә, XIV гасырның 80 нче елларында инде Болгарның әһәмиятен югалтуы, төшенкелек чоры кичерүе турында сөйли.

Ә Бирдебәкнең Гөлстан әл-Җәдид дигән акча сугу урынына килгәндә, ул ераграк урнашкан Казанны белдерергә дә мөмкин, чөнки Болгар йортының Кама һәм Идел буендагы төп җирләре Туктамышка буйсынган.

19. Бикбулат. Хәзинәдә Бикбулат исеменнән Урдуда һиҗри 793 елда (1391/1392) сугылган 2 данә акча табылды. Акчаларда Бикбулатның «әл-гадел солтан» титулын укып була. Бикбулат — билгеле шәхес. Ул — 1385 елда Туктамыш Азәрбайҗанга, бу төбәкне кулга төшереп татар шәһәрләренең сәүдәсенә зыян китерергә омтылган Аксак Тимергә каршы җибәргән зур гаскәр башлыкларыннан берсе. Аннан соң Бикбулат 1393 елда Туктамышның Ягайлога җибәргән ярлыгында ханга каршы заговор оештыручыларның берсе итеп күрсәтелә [1].

Бикбулат акчалары 1391 елның 18 июнендә Тук-

---

[1] Березин Н. И. Ханские ярлыки. 1 нче чыгарылыш, Казан, 1850, 21 бит.

тамышны Кондырча елгасы буенда Аксак Тимер тар-мар китергәннән соң сугылган. Шул ук ярлыгында Туктамыш бу җиңелүендә Бикбулатны гаепли.

Туктамыш җиңелгәннән соң, Бикбулат Сарайны ала һәм үз исеменнән акча суктыра башлый. Ләкин тиздән ул Туктамыш тарафыннан тар-мар ителә һәм җәзалап үтерелә.

1380 ЕЛГЫ АКЧА-АВЫРЛЫК РЕФОРМАСЫ

Югарыда әйтелгәнчә, XIV гасырның 60 нчы еллары азагына, үзара туктаусыз сугышлар бару аркасында, аерым шәһәр һәм олысларның экономик яктан бәйсезлеге арта һәм нәтиҗәдә акча системасы какшый. Әлбәттә, экономик аерымлану, ә тулаем алганда, экономиканың көчсезләнүе, хәзинә рәвешендә юкка чыга торган акча урынына, базар ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, тулы авырлыктагы дирһәмнәр чыгаруда кыенлыклар тудырырга тиеш булган. Дирһәмнәр чыгаруның акрынаюы һәм аннары аларның авырлыгы киметелү, әйләнештә йөргән тәңкәләрне кисү, күрәсең, шушы сәбәпләрдән киләдер.

Менә шуңа күрә Кече Әтрәстәге 10 мең данә акча күмелгән зур хәзинәдә дә 70 нче елларда сугылган акчалар 5% кына. Идел буе шәһәрлекләрендә табылган көмеш тәңкәләр арасында да шундый ук хәл күзәтелә, ә шул ук елларда сугылган бакыр акчалар бөтен бакырның шактый зуррак процентын тәшкил итәләр. Феодаль низаглар һәм сугышлар — әйләнештәге акчаның массакүләм төстә хәзинә итеп җиргә күмелүенә китерүче төп сәбәп. 1310—1311 һәм 1380 елларда үткәрелгән реформалар арасында күмелгән акча хәзинәләренең 70% тан артыгы 60—70 нче елларга туры килә.

1370 елларда Идел буе базарларына яңа сугылган акчаның гадәттән тыш аз керүе көмешнең тезаврацияләнү ихтималын арттыра, шул ук вакытта халык тыгыз утырган Кама буенда сәүдә мөнәсәбәтләре үсү нәтиҗәсендә акчага булган ихтыяҗ арта. Шуңа күрә, бу кыенлыктан чыгу өчен, Кама буенда үзенчәлекле чара күрелә: иске акчаларны кисәләр һәм яңадан әйләнешкә җибәрәләр.

Бу күренештә, Болгар әмирләренең политик омтылышлары белән беррәттән, кайбер экономик фактор-

лар да чагылыш таба (көмешнең кыйммәтләнүе, акча әйләнешенең нормаль барышы бозылу һ. б.).

Көмешнең кыйммәтләнүе һәм алтын белән көмеш арасында элек урнашкан рационың бозылуы Болгарга гына хас булмаган. Бу күренеш һәркайда күзәтелгән дип уйларга кирәк. Шул сәбәпле бу чорда, атап әйткәндә XIV гасырның 80 нче елларында акчаларны Хәрәзмдә дә кисеп җиңеләйткәннәр.

Шунысы игътибарга лаек, XV гасыр башында Болгар (Казан) үз акчасын суга башлагач, 0,78 г лы авырлык, ягъни 1/6 мыскал — дәник норматив итеп алына һәм ул Сарай акчасы белән 1:1,5 (2:3) нисбәтен саклый. Казан һәм Сарай дирһәмнәренең бу нисбәтен базар һәм бердәм авырлык системасы таләп итә. Казан дирһәменең авырлыгы 0,6825 г га, аннары 0,585 г га кадәр кимегәч тә, шушы ук нисбәтне саклыйлар. Болгар һәм Сарай акчалары нисбәтендәге мондый даимилекне исәпкә алсак, Болгарда акчаны кискәләү Сарайда җиңелрәк акча чыгару һәм иске дирһәмнәрне кисү белән бер үк вакытта булган дип уйларга мөмкин. Сарайда акчаны җиңеләйтеп сугу XIV гасырның 70 нче елларына — чуалышлар һәм мөстәкыйль әмирлекләр барлыкка килү чорына карый. Тәхеткә менгән һәрбер яңа хан үз исеменнән акча сугарга тырышкан. Бу үз исемеңне акчада мәңгеләштерү йөзеннән эшләнмәгән, бәлки акча регалиясеннән мөмкин кадәр күбрәк файда алырга тырышканнар. Гаскәр тоту, даими сугышлар алып бару өчен байтак акча кирәк булган. Көмеш исә җитмәгән. Үзара сугышлар һәм аерым өлкәләрнең дәүләттән аерылып чыгуы нәтиҗәсендә казна бушап калган, тыныч заманнардагы кебек ясак түләүдән мул керемнәр тәмам онытылган. Көмеш чыганаклары булган Көнбатыш Себер һәм Уралның аерылуы шактый авырлык китергән.

Акча сугу сарае элекке кебек акча әйләнешен җайга сала алмаган, тулы авырлыктагы акчаларны регуляр чыгармаган, базарда көмеш бәясенең тирбәлешләренә ияреәгә һәм җиңелрәк акчалар чыгарырга мәҗбүр булган. Бу вакытта базарда бер иске дирһәмне 32 пулга алмаштырып булмаган, күбрәк бирергә туры килгән. Шуңа күрә акча сугу сарае көмеш тәңкә авырлыгын 32 бакыр акча бәрабәр булырлык итеп киметкән. Дирһәм авырлыгының тирбәлүен һәм иске акчаларның шушы авырлыкка туры ките-

реп киселүен без иң элек Сарайда һиҗри 762—772 елларда сугылган Габдулла акчаларында күрәбез.

Аның акчаларының күпчелеге 1,32—1,364 г лы.

XIV гасырның 60 нчы елларында бакыр акчаларга Габдулла, Газизшәех һәм Каганбәк исемен, көмеш тәңкәләргә «гадел» пунсоны өстәп басу бу чорда акча авырлыгында ниндидер үзгәрешләр булуы турында сөйли. Шул рәвешле, көмеш һәм бакыр акчаларның нисбәтен кат-кат җайга салырга тырышып караганнар.

Ләкин көмеш кыйммәтләнә барган. Күрәсең, базарда дирһәмне бакырга алмаштыру файдалы булмаган. Түбән бәяләнгән дирһәмне әйләнештән алганнар һәм ул хосусый кулларда тупланган, рибачылык (ростовщиклык) тамыр җәйгән. XIV гасыр татар шагыйре Хисам Кятибның һиҗри 770 елда язылган «Җөмҗөмә солтан» дигән әсәрендә поэманың каһарманы якты дөньяда артык зур процент алып баеган рибачыларны тәмугта ут йотарга мәҗбүр итүләрен күрә.

Көмешнең тезаврацияләнүенә юл куймау өчен, 70 нче елларда үзенчәлекле чара күрелә: дирһәмнең авырлыгы 1,365 г га кадәр киметелә, һәм моның стихиячел төстә киселгән акча түгеллеген, бәлки рәсми авырлык икәнен күрсәтү өчен «гадел», «законлы» дигән келәймә сугыла. Бер үк вакытта иске бакыр акчаларга да өстәмә штемпель басыла. Көмеш тәңкәләр кебек үк, алар да инде яңа курс буенча йөриләр. Мәсәлән, әгәр Хызыр чорында, 1,56 г лы дирһәм авырлыгына уртача 3,12 г лы 32 пул киткән булса, өстәмә штемпель басылгач, пуллар элекке авырлыкта калганнар, ләкин дирһәм инде җиңелрәк булган. Димәк, көмеш бакыр белән чагыштырганда тагы да югарырак бәяләнгән. Г. А. Федоров-Давыдов билгеләп үткәнчә, яңадан әйләнешкә кертеп җибәрелгән акчаларның курсын болай үзгәртү акча әйләнешен савыктыруны, көмешнең тезаврацияләнүен тыюны күздә тоткан. Акча әйләнешен шушы тәртиптә җайга салырга омтылышлар Урта Иделдә, Хәрәзмдә һәм дәүләтнең башка өлкәләрендә дә күзәтелгән. Алар арасында кыйммәтле металлны үз өлкәләреннән чыгармау өчен ниндидер ярыш барган булуы да ихтимал.

Габдулла ханның һиҗри 762—772 елларда сугылган көмеш тәңкәләре арасында иң күбесе 1,364 г лы (теоретик авырлыгы 1,365 г). 1,365 г авырлык элгәр-

ге ханнар чыгарган акчаның 1,56 г лы норматив авырлыгыннан бер киратка ким (1,560 г — 0,19 г=1,365 г). 1,365 г лы авырлык нормасы буенча сугылган акча системасы, ягъни 4,68 г лы мыскал системасыннан соң 4,095 г лы мыскал системасына күчү закончалы күренеш булган, ә чыгарыла торган акчаларның авырлыгын 1,56 г нан 1,365 г га кадәр киметү, күрәсең, очраклы хәл түгел. Туктаусыз үзара сугышлар, көмешнең кыйммәтләнүе һәм акча әйләнешенең нормаль барышы бозылу шушындый нәтиҗәгә китерергә тиеш булган да. Без инде сугыла торган акчаның норматив авырлыгы 1,56 г нан 1,365 г га кадәр кимүне XIII гасырның икенче яртысында да күзәткән идек. Ул да шушындый үзара сугышлар вакытына, акча металлы аерым кулларда тупланган һәм тулы авырлыктагы акчаны даими чыгарып тору өчен специфик кыенлыклар булган заманга туры килә.

Шуңа игътибар итәргә кирәк, Сарай акчаларының авырлыгындагы мондый үзгәреш XIV гасырның 60 нчы еллар азагында — 70 нче еллар башында, ягъни иске традицион авырлык системалары гамәлдә йөргән төбәкләр экономик яктан аерыла башлаган чорда күзәтелә. Шуңа күрә, инде әйтеп киткәнебезчә, акчаның 1,365 г лы норматив авырлыгы дәүләтнең барлык төбәкләре өчен гомуми булып китә алмаган.

Туктамыш тәхеткә утыргач, акча-авырлык системасын унификацияләү өчен чаралар күрелә. 1380 елда ул Кыпчакның төп өлкәләрен берләштерүгә һәм акча системасын унификацияләү максаты белән акча реформасы үткәрүгә ирешә. Туктамыш керткән яңа акчаларның авырлык нормасы Идел буеның традицион авырлык нормалары чигеннән чыкмый. Мәсәлән, Туктамышның Сарай әл-Җәдидтә һәм Сарай әл-Мәхрусада сугылган һәм Екатеринослав хәзинәсендә табылган 139 данә акчасының күбрәге (67 данәсе) 1,364 г га, ягъни безгә инде Габдулла акчаларыннан билгеле булган теоретик 1,365 г га туры килә.

Шулай итеп, тәхеткә Туктамыш утыргач, бөтен дәүләт күләмендә акча-авырлык системасын унификацияләү чаралары күрелә һәм 4,095 г лы мыскал системасы Туктамыш берләштергән барлык провинцияләрдә гамәлгә кертелергә тиеш була.

XIV—XV гасырлардагы акча әйләнешендә алтын исәбе гамәлдә була. Эре сәүдә операцияләре вакытын-

да, акчаны сәгатьләр, ә кайчагында көн буе санап утырганчы, ансат кына үлчәүдә үлчи алганнар. 5 һәм 10 алтынлы герләр аеруча еш очрый. Алтын системасы акчаның данәләп әйләнешенә дә комачаулаган. Алты көмеш тәңкә исәп буенча да, авырлыгы буенча да бер алтынга бәрабәр. Дөрес, фактта акчалар бертигез авырлыкта булмаган, ләкин моның артык әһәмияте юк. Теләсә кайсы 60 акчаны (10 алтын) үлчәп караганда алар теоретик авырлыкларыннан җиңелрәк чыксалар да, аерманың бер көмеш тәңкә авырлыгыннан да артмавын күрәбез. Бу аерма бик кечкенә. Тагы да эрерәк (20—25 алтынлык) акча операцияләре вакытында башка исәп-авырлык берәмлеге — сом кулланылган.

Билгеле булганча, хакимлек итүенең баштагы чорында Туктамыш Аксак Тимернең ярдәме һәм химаясеннән файдалана. Туктамышны Урта Азиядән һәм көнчыгыш олыслардан чыккан яраннары әйләндереп алган була. Көмеш һәм бакыр акчаларны сугудагы авырлык нормасы 1380 елда Туктамыш үткәргән акча-авырлык реформасының уйлап җиткерелмәгән булуын күрсәтә. Хәтта XIV гасыр татар акча сугучыларының казанышлары да исәпкә алынмый. Үзбәк һәм Җанибәк заманнарындагы реформалар белән чагыштырганда, Туктамышның акча-авырлык реформасы акча әйләнешенә бернинди дә яңалык кертми, бәлки аның бозылуын рәсмиләштергән кебек кенә була. Исәп сомы (163 г лы 120 данә акча) 204,75 г лы көмеш коелма белән чагыштырганда артык түбән бәяләнә. Нәтиҗәдә тәңкәләрне әйләнештән алып кисә башлыйлар һәм ун меңләгән акча кыйпылчыклары азмы-күпме даими курска ия булган яңа коелмалар ясауга китә. Шулай булгач, яңа сугылган акчалар көмеш коелмалар әйләнешен чикли дә, тулы кыйммәтле акча әйләнешен торгыза да алмаган.

Урта Идел буендагы товар-акча мөнәсәбәтләре үскән һәм бәя тирбәлешенә сизгеррәк булган акча әйләнешен өйрәнү дә бу фикерне раслый.

Туктамыш акчасы Болгар базарларына аз үтеп керә. Урта Иделдәге XIV гасыр азагына караган дирһәм хәзинәләре башлыча Туктамышка кадәр сугылган иске акчалардан тора.

Димәк, яңа сугылган акчалар әйләнештә йөргән иске акчаларның бөтен массасын алмаштыра алмаган. Урта Идел буена килеп эләккән акчалар, шул

исэптэн яңа сугылганнары да, әүвәлгечә билгеле бер авырлыкта итеп киселгәннәр. XIV гасырның 80 нче елларында Болгар акчаларын кисү өчен реформага кадәрге 0,78 г лы дәник норматив авырлык булып хезмәт иткән. Ул исәп сомының һәм коелманың курсына төгәлрәк туры килгән (240 дәник — 187,2 г лы сом — 204,75 г лы коелма сомга тиңләштерелгән).

XIV гасырның 80 нче елларында Туктамыш суктырган бакыр акча авырлыгын өйрәнү дә шуны ук күрсәтә. Дәүләт Тарих музее коллекциясендәге 19 пулның авырлыгы — 1,30—2,42 г нар арасында тирбәлә. Әгәр моннан алдагы чор акчалары, әйтик, уртача 3,12 г авырлыкта итеп сугылган Хызыр пуллары арасында 2,40 г лы данәләр гомумән сирәк очраган булса, реформадан соң сугылган пулларның авырлыгы киму ачык күренә. Моңа кадәр XIV гасырның 70 нче елларына кадәр сугылган пуллар арасында без бакыр акча авырлыгының артуын гына күзәткән идек. Исәп-хисапта көмеш тәңкәләрнең билгеле бер өлешенә бәрабәр булган бакыр акча көмеш тәңкәнең күтәрелгән курсын саклап тотарга булышкан. 1380 елгы реформадан соң чыгарылган пулларның авырлыгы сизелерлек кими. Бу күренешне нәрсә китереп чыгарган? Әгәр реформадан соң көмеш тәңкәләр авырлыгы кимүне Идел буе тарихында бу катлаулы һәм тынгысыз чорда көмеш кытлыгы белән аңлатып булса, бакыр пул авырлыгының 2 тапкыр диярлек кимүен фәкать реформаның төптән уйлап җиткерелмәгән булуы белән генә аңлатырга мөмкин. Пулның авырлыгы 1,70 г га исәпләнгән булган дип уйларга кирәк (3 пул 1,72 г авырлыкта), ягъни 240 пул, Җанибәк хан вакытындагы кебек үк, бер кадакка тигез булган (409,5 : 240 = 1,70 г).

1380 елгы реформадан соң сугылган пуллар, күрәсең, мәҗбүри курс белән генә йөри алганнар. Шунысы кызык, Туктамыш заманындагы бакыр пуллар арасында XIV гасырның 70 нче елларына караган акча белән чагыштырганда башка типтагы штемпель белән «гадел» сүзе өстәп сугылганнары очрый. Моннан исә мәҗбүри курсның мөмкинлекләре төкәнгәч тә көмеш бәясенең үзгәрүен җайга салырга омтылып караганнар дигән нәтиҗә чыга.

Туктамыш хан булгач, акча-авырлык системасын унификацияләү буенча чаралар күрелсә дә, экономиканы җимергән төп сәбәпләр бетерелмәгән, киресен-

чә, туктаусыз сугышлар нәтиҗәсендә алар тагы да көчәйгән, тирәнәйгән. Үзенең хакимлеген ныгытырга теләп, Туктамыш 1387 һәм 1388 елларда Урта Азиягә, Аксак Тимер биләмәләренә яу чаба, ләкин ике юлы да уңышсызлыкка очрый. Ниһаять, 1391 елның 18 июнендә Болгардан ерак та түгел Кондырча елгасы буенда ике яктан да 200 әр мең кеше катнашкан сугышта ул Аксак Тимер тарафыннан тар-мар ителә.

Идел буе шәһәрләре һәм шәһәр культурасы өчен Аксак Тимер яулары монгол яуларына караганда фаҗигалерәк булып тәмамлана. Әгәр монголлардан соң Идел буеның барлык шәһәрләре дә диярлек торгызылган булса, Аксак Тимер басып кергәч Идел буе шәһәрләре җир белән тигезләнә, күчмә станнар туздырыла. Шәһәр халкы кырып бетерелә, исән калганнарны кол итеп куып алып китәләр. Бу чордагы шәһәр хәрабәләрен археолог Ф. В. Баллод Везувий вулканы харап иткән Помпей шәһәре белән чагыштыра... Археологик казу эшләре күрсәткәнчә, Патша шәһәрлегендәге калкурак җирне казып карау белән торак йортка тап буласың. Хәрабәләр арасында үтерелгән хатын-кыз, балалар һәм картларның скелетлары яки ир кешеләрнең баш сөякләре өелеп ята [1].

Бу фаҗигале хәлләрдән соң Мисырга барып чыккан татар шагыйре Сәйф Сараи, Аксак Тимер яуларыннан нәфрәтләнеп:

Кузутты җәң белән галәмдә туфан,
Акытты су тикин йир үзрә күп кан.
Игенче эүләрә ягылды утка.
Бодай саурылды, туфрак булды ботка,—

дип яза.

[1] Вайнер И. С., Мухамадиев А. Г., Федоров-Давыдов Г. А. Археологические исследования Царевского городища (Новый Сарай) в 1959—1966 гг.— «Поволжье в средние века» китабында, М., 1970.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш

Беренче бүлек: **VIII—XIV гасырларда Идел буенда акча сугу үзәкләре** 14

Икенче бүлек. **Идел буенда һәм Урал якларында хазарларга кадәр акча әйләнеше** 33

Өченче бүлек. **Хазар акчалары** 45
Хазар каганлыгы оешыр алдыннан Идел һәм Урал буе 45
Төрки мирас 50
Хазар тәңкәләре 52

Дүртенче бүлек. **Идел буенда X—XII гасырларда товар-акча мөнәсәбәтләре** 64
Хазарлар мирасы 64
X гасырда сугылган болгар акчалары 72
Акча сугылмаган чорда товар-акча мөнәсәбәтләре . 82
Пыяла герләр һәм затлы металлар 85
Акча сугу эшенең торгызылуы 86
Кризистан чыгу 90
Болгарда акча терминологиясе һәм акча исәбе . . 93

Бишенче бүлек. **XIII гасырның уртасында һәм икенче яртысында Идел буенда акча һәм акча-үлчәү системасы** 97
Кыпчак олысы барлыкка килү 97
Болгарда акча сугу эшенең торгызылуы . . . 103
Олысның аерылуы. Гали (югары) тамга . . . 107
XIII гасырның 60—80 нче елларында акча-авырлык системасы 110
XIII гасырның 90 нчы елларында акча әйләнеше . 116

Алтынчы бүлек. **XIV гасырның беренче яртысында акча-авырлык системасы** 122
1310—1311 еллардагы акча-авырлык реформасы . 122
Үзбәк хан чорында (1312—1342) акча-авырлык системасы 128
Көмеш тәңкәләрнең авырлыгын арттыру . . . 136
Бакыр акча 141
XIV гасырның 40—50 нче елларында акча-авырлык системасы 147

Җиденче бүлек. **XIV гасырның икенче яртысында акча-авырлык системасы** 155
60—70 нче елларда сугылган акчалар . . . 155
1380 елгы акча-авырлык реформасы 169



I таблица. Җиз герләр.

II таблица. Акча урынына йөргән көмеш савыт (Хәрәзм патшасы Сакассак сунарда).

III таблица. Акча урынына йөргән көмеш савыт.

IV таблица. Акча урынына йөргән көмеш савыт.



V таблица. Үлчәү тәлинкәләре (1) һәм пыяла герләр (2—10).



VI таблица. Хазар тәңкәләре (VIII—IX гасырлар).



VII таблица. Имәнкискә хәзинәсе көмешләре (XII гасыр).



VIII таблица. Болгар акчалары:

1 — 4 — Насир лид-дин таңкаләре (1180 — 1225); *5,6* — Насир лид-дин исеменнән сугылган бакыр акчалар; *7,8* — Мунка каән таңкаләре (1251 — 1257); *9* — кабатлап сугылган Мунка — Насир лид-дин бакыр акчасы; *10* — „Тамга-и гали“ язулы таңкә; *11* — Берка хантаңкасе (1257 — 1266); *12 — 15* — Ариг Буга исеменнән сугылган Беркә таңкаләре.



IX таблица. Болгар акчалары (XIII гасырның икенче яртысы):

1,2 — Мәңге Тимер акчалары (1266 — 1282); *3,4* — Туда Мәнге акчалары (1282 — 1287); *6* — Биләр таңкасе; 7 — Насыр лид-дин (Тукта, 1291 — 1312) таңкасе; *5.8 — 10* — аноним таңкалар.



X таблица. XIII гасыр азагы Болгар акчалары:

1 — 12 — аноним таңкәләр; *13 — 15* — бакыр акчалар.



XI таблица. XIII гасыр болгар акчалары легендасы:

1 — 3 — Насир лид-дин; *4* — Насир лид-дин — Мункэ (бакыр); *5* — Мункэ; *6* — Ариг Буга; *7* — Мәңге Тимер; *8* — язусыз таңкә.

XII таблица. XIII—XIV гасыр Болгар һәм Сарай акчалары:

1 — „Котлы булсын“ дигән язулы, һиҗри 683 елда сугылган Болгар тәңкәсе; *2* — Насир лид-дин (Тукта) тәңкәсе; *3* — *4* — „Болгар пулы“ дигән язулы бакыр акчалар; *5* — *6* „Уналты пул — дәник“ дигән язулы бакыр акчалар; *7* — „Хөкма һомаюн“ („Патша хөкеме“) дигән язулы бакыр; *8* — „Уналты — дәник“ дигән язулы бакыр; *9* — „Котлыг булсын яңы пул!“ дигән язулы бакыр.

XIII таблица. XIV гасыр тәңкәләре:

1 — Тукта, Сарай әл-Мәхруса; *2* — Үзбәк (1312 — 1342), Сарай; *3* — Үзбәк, Болгар; *4* — Үзбәк, Сарай әл-Мәхруса; *5* — *7* — Җанибак (1342 — 1357), Сарай әл-Җадид; *8* — *10* — Җанибак, Гөлстан.



XIV таблица. XIV гасыр тәңкәләре:

1 — Бирдебәк (1357 — 1359), Гөлстан; *2* — Хызыр (1359 — 1361), Гөлстан; *3* — Бирдебәк, Сарай әл-Җәдид; *4* — Хызыр, Сарай әл-Җәдид; *5* — *7* — чулпы тәңкәләре; *8* — *19* — кискән тәңкәләр.

XV таблица. XIV гасырның икенче яртысына караган акчаларның легендасы:

1 — Дәүлнулла Хуҗа, Гөлстан әл-Җәдид; *2,3* — „Солтан мәрхүм Җанибәк хан" исеменнән сугылган Булаттимер бин Төклеби тәңкәләре, Гөлстан; *4* — Урыс Мөхәммәт хан, әл-Урду; *5* — Мөхәммәт Бүләк, Урду; *6* — Түләкбәк, символ; *7* — Бикбулат, Урду; *7* — *9* — Бирдебәк, Гөлстан әл-Җәдид.



XVI таблица. XIV гасыр пуллары

1 — 3 — Үзбәк, Сарай; *4 — 6* — Үзбәк, Сарай әл-Җәдид; *7* — Җанибәк, Сарай әл-Җәдид; *10 — 11* — Хызыр, Гөлстан.

35 тиен·